PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН



2016 МАЙ № 5

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

БАЛА БЕЛӘН ҺӨНӘР САЙЛЫЙБЫЗ
психологлар фикере

ФРАНЦИЯ
татар кызы җиде ят арасында да югалмас

РАМИЛ ЗАКИРОВ СЫЙЛЫЙ:
ризотто әзерлибез

Алеся ЗАРИПОВА:

– ЯРАТАМ, ШУҢА БӘХЕТЛЕ!



PRESSA.RU



БЕРГӘ ЧАКТА... Бу мизгелләр күп тә түгелдер, бәлки — атналарны тыгызлаган бетмәс-төкәнмәс эш, мәшәкать ыгы-зыгысында гаилә белән үткәргән бәхетле минутлар һаман сирәгәя, кыскара барадыр. Әмма аларның һәрберсе кадерле, һәркайсы безгә тормышның ямен-тәмен тоеп яшәрлек көч, җан җылысы бирәдер. Бу тансык вакытны һәркем үзенчә үткәрә – алар мәгънәле, күңелле, онытылмас якты булсын өчен әллә ни кирәкми дә кебек...





УТЫЗ ЕЛЛЫК РОМАНТИКА

Салиховлар гаиләсе

Түбән Кама

Сплав! Май, кояш, менә-менә ачылырга торган бөреләр романтик җаннарны тагын Мари урманнарына ашкындыра! Ел буе көтәләр ул көнне! Һәм алар утызынчы язларын шулай каршылый инде! Ә бу күңел бәйрәменең матур традициясе узган гасырның 80 нче елларына ук барып тоташа. Университет кызларының – «Ассоль», КАИ егетләренең «Импульс-56» студентлар төзү отрядлары әгъзалары көннәрдән бер көнне Мари Иле тайгаларын ерып ага торган ярсу елгалар буйлап көймәдә йөзәргә килешәләр... Инде ул егет-кызлар өйләнешкән, балалары үсеп беткән. Кечкенәдән үк поход биштәрләре, палаткалар шәһәрчеге, учак төтене, таңгача гитара җырлары белән сихерләнгән ул балалар да көймәле сәяхәтне түземсезлек белән көтә. Бу күңелле вакыйга май бәйрәмнәренә туры килгәнгә күрә «маевка» атрибутлары да саклана: демонстрация, парад, бергәләп хәрби җырлар җырлау... Күмәк уеннарда бала-чагага, зурларга бүленеш юк: һәркайсы тигез хокуклы. Елгада көймәләрдә йөзү табигать кочагында ял итү генә түгел. Анда яңа дуслар табасың, искеләре белән җанны яңартасың, шәһәр ыгы-зыгысыннан котылып торасың, ел буена җитәрлек рәхәтлек аласың. Гомернең менә шундый рәхәт бер мизгеле ул!..
Лариса белән Илшат Түбән Камада республика энергетика системасында эшлиләр. Кызлары Талия – КФУда кече фәнни хезмәткәр, Кария – 10 нчы сыйныф укучысы.















Ә сез БЕРГӘ ЧАКТА ниләр эшлисез, сезнең гаиләне нинди эш-гамәлләр, үзенчәлекле бәйрәмнәр, берәүдә дә кабатланмый торган, әмма башкаларга да үрнәк булырдай матур йолалар берләштерә? Яңа фотопроектыбыз шундый мизгелләрне яктыртуга багышланган.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



©«Сөембикә» 2016

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Директор-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Директор урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррире:
Сөмбел Гаффарова

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Алеся Зарипова
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Учредитель:
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»



ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 10.05.2016 ел.
Заказ М-1202.
Тираж 6291.



PRESSA.RU













Асия ЮНЫСОВА

Европада Сабантуйлар

Кояшлы көн иде кырык бердә,
Сабантуйлар иде илемдә.
Сабантуйны өзеп, яуга китте
Татар егетләре ил белән.

Сталинград! Каты булды орыш,
Канлы иде анда мәйданнар.
Идел буендагы бил алыштан
Европага үтте малайлар.

Танкларны бәреп танкларга,
Бил алышлар булды Дугада.
«Сабантуен» ясап күрсәттеләр
Безнекеләр Дуга явында.

Бәйрәменнән алда сүзе барды,
Рухы гына түгел, дәһшәте!
Сабантуйны Европага илтте
Татар егетенең гайрәте.

Җитез генә менде Рейхстагка,
Үрмәләгән кебек колгага.
Сөйгәненең вәгъдә бүләген –
Бәйләп куйды – менә шул гына!.

Җилфердәде шунда кызыл комач!
Күрде аны бөтен Европа –
Үкенечкә калган Сабантуйның
Ал сөлгесен – Җиңү байрагын!

Сабантуйдан киткән егетләрнең
Туган йортта калды уйлары.
Алар илткән иде бәйге-туйны –
Европада Сабантуйлары!

Европага Сабантуйдан китте,
Сабан туен илтте егетләр.
Бәйрәмнәре бүтән өзелмәсен,
Киселмәсен бүтән өметләр!



PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





8
ЗУР КОРАБКА — ЗУР СУ ЮЛЫ
М. Авзалова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





12
СӨЙКЕМЛЕ СӨЯК
А. Юнысова

24
УҢГА КИТСӘҢ – УҢАСЫҢ, Ә СУЛГА КИТСӘҢ?..
Л. Гәрәева





16
КАЙДА СОҢ УЛ СОҢГЫ ЧИК?
М. Кашапова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ




28
ОКОПТА ТАТАР ҖЫРЫ
Х. Гарипова

32
ҖИДЕ ЯТ АРАСЫНДА...
Г. Сафиуллина

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ

40 МИЛӘШ КАГЫ
Р. Мулланурова

ЯШӘЕШ




48 ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ
Ф. Тарханова



52 РӘХМӘТ, БОЛГАРИЯ!
А. Дәүләтшина

ШУЛАЙ УК:


20 АЧЫ ДАРУ
Г. Хәсәншина

46 БӨРЕДӘ КАЛГАН МӘХӘББӘТ
Р. Камалетдинова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ




60 БӘЛӘКӘЙ КЫЗЛАРГА

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА:


БАЛА БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

ХЫЯЛ ИЛЕ – КЫТАЙ.

САБАНТУЙГА ЯҢА МУЕНСА.

ЗӨЛФӘТ ЗИННУРОВТАН – ПАРЛАМА.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Әтием Исмәгыйль Хаҗиәхмәт улы Әхмәдиев 1908 елны Шөгер (хәзерге Лениногорский) районы Түбән Чыршылы авылында туган. 4 ел авыл мәдрәсәсендә укыган. Колхозлашу елларында авыл советында эшләгән, халыктан акча һәм икмәк салымы җыюда катнашкан.

Башлангыч сыйныфлар өчен укытучылар курсы ачылганын белгәч, әтидә бик нык уку теләге уяна. Бөгелмә педучилищесын тәмамлап, Шөгер районының Урдалы авылында укыта. Икенче Бөтендөнья сугышы башлангач, аны да фронтка алалар. Әнием Саимә өч баласы белән дүртенчегә авырлы килеш кала. Бер баласы да ачтан үлми, исән-имин үсеп җитә. Әти сугышка киткәндә: «Өйне сатсаң сат, сыерны сата күрмә», – дип әйтеп калдыра.

Әти 1941–45 елларда Заполярьеда хезмәт итә. Сугыштан кайткач, үзен кабат укытучы итеп куюларын сорый. «Бер хатын-кызны алып, аның урынына сине куярбыз», – дигәч, кешене иписез калдырырга ризалашмый. Ике ел Югары Чыршылыда укыта. Әти табигатьне, кешеләрне бик ярата иде. Авылдаш ир-егетләр аңа чәч алдырырга килә иделәр. Киңәшкә килүчеләр дә була, гариза язып бирүен дә сорыйлар (бигрәк тә ирләре сугышта ятып калган хатын-кызлар)... Һәрберебезнең хәтерендә әти үзенчә саклана. Олы апам Фәния: «Әти кайтканда мин инде мәктәп яшендә булсам да, өскә кияргә булмагач, укырга йөри алмадым. Әти мине укырга, мисаллар чишәргә өйрәтте», – дип искә ала. Икенче апам Фиданиянең исендә калганнар: «Урамга чыксам, капка төбендә таныш түгел бер абый белән бер апа утыра. Өйләре янып, авылдан авылга, кешедән кешегә йөриләр икән. Апа шуны әтигә кереп әйткән дә, әти аларны беразга бездә яшәргә чакырган».

Әти сугыштан кайткач, әни тагын биш бала тапкан. Алар безне ачуланып, тиргәп үстермәде. Бик ачуы килгәндә әтинең әйтә торган сүзе бар иде: «Сыбызгы». Ул эштән кайтуга өйдә тынлык. Җыйнаулашып «Пионер почмагы» дигән стена газетасы чыгарабыз. Өйдә, мәктәптә булган хәлләрне язабыз. Менә шундый бәхетле гаиләдә үстек без. Әти-әнигә тормыш итү авыр булса да, без аны сизмәдек, су кереп, җиләк җыеп үстек. Кызганыч, үсеп җиткәч, беребез дә авылда калмады. Ул чорларда авылларда эшкечелек дигән нәрсә бар, бөтен эш эчүгә бәйләнгән иде. Әтинең моңа бик тә эче пошып, «Социалистик Татарстан» газетасына язып та чыкканы булды. Хәтерлим әле, килеп тикшерделәр дә, дөрес түгел дип киттеләр. Әти ялганчы булып калды. Без әти-әни янына еш кайтып йөрдек. Кичләрен түгәрәкләнеп утырабыз да, әти сөйләгәннәрне тыңлыйбыз. Ул сугыш турында сөйләргә яратмый иде. Күбрәк элеккеге тормыш, үзенең 25 елга патша армиясенә хезмәткә алынган Әхмәди бабасы турында сөйли иде. Пенсиягә чыккач, аның турында зур күләмле кулъязма язып калдырды. Шигырьләр дә яза иде. Әти вафат булып, 24 ел узгач, без балалары, әтинең ул кулъязмаларын 2012 елда китап итеп бастырып чыгардык. Чыршылы авылы клубында һәм мәктәптә аның буенча фикер алышулар узды. Россиянең мәгариф отличнигы, озак еллар мәктәп директоры булган Рузалия Сафина: «Безнең Түбән Чыршылы авылы да тарихка кереп калды», – дигән иде. Язарга сәләте булса да, әти күп яза алмады – тормыш авыр иде. Хәзер уйлыйм әле, ул чорда кешеләр бер-берсенә бик ярдәмчел булганнар икән. Күрше Һөмәйрә әби безгә бик арзанга гына матур күлмәкләр тегеп кидерә иде. Тагын бер күршебез – Нурдидә әби – халык табибы, кендек әбисе иде. Берәр җирең сынса яки чыкса, берәрсенең бәби табар вакыты җитсә, бөтен эшен ташлап йөгерә торган иде. Йортыбыз янгач, барлык туганнар бердәм булып, безгә йорт салып керергә ярдәм иттеләр. Шуны да әйтеп үтәсем килә: әтинең сугыштан исән-имин кайтуы да безнең өчен олы бәхет иде. Күпләр «әти» сүзен әйтергә тилмереп үсте. «Бер сыерга бер әти алмашып булмый микән», – дип сораучылар да булган, имеш. Әтидән истәлек булып шигырьләре һәм бабасы турында язган китабы калды да безгә әйткән васыяте калды: «Дөньяны оҗмах та, тәмуг та ясап була. Дөньяны гаепләмәгез. Барысы да үзегездән тора, тормышыгыздан оҗмах ясагыз». Кабер ташына да истәлек итеп үзенең бер шигыреннән өзек яздырдык: «Әгәр калса бу җиһанда хезмәтемнән бер өлеш. Шатмын диеп әйтер идем каберемдә яткан килеш». Әтиемнең китабын укырга теләүчеләр булса, адресым «Сөембикә» журналы редакциясендә.

Флюра ӘХМӘДИЕВА-ӘҺЛИУЛЛИНА.
Бөгелмә.



Әтине беренче көннәрдән үк сугышка алалар. ***Иртәгәсен аның исеменә бронь килә. Авылның беренче һәм бердәнбер трактористы булганга, аңа сугышка бару кичектерелгән икән.***

Әни шул бронь кәгазен тотып, Казанга чыгып чаба. Кайбер урынны җәяүләп, кайсын юлаучы атларга утырып, Казанга килеп җиткәнче, таң ата. Әти тукталган частька килеп җиткәндә, сугышка китүче солдатлар төялгән состав Казаннан чыгып киткән була. Әни, бу хәбәрне ишеткәч, баганаңы кочаклап, үкси-үкси, әрни-әрни елый. Гомер азагында да: «Шул мизгелдән дә кыенрак чак булмады тормышта», – дип әрнеп сөйли иде.

Әнием Хәлимә көчле кеше булды. Сугышның иң авыр елларында да сыер асрады. Мин, әти сугышка китеп, 4 ай узгач, көз көне туганмын. Әни мине беренче көннәрдән үк әнисенә калдырып, колхоз эшенә чыккан. Ул кул эшенә дә бик оста иде: бәйли, күлмәкләр тегә, итек баса. Мин үзем тормышка чыкканчы, әни баскан итекләрне кидем. Шул итекләрне киеп, клубка чыгып, «Зәлилә» биеп, итекнең баш бармак туры тишелеп чыга иде.

Әниемнең үлгәнчегә кадәр телендә бер җыр булды:

Агыйделгә төшкән чакта
Тотмадың беләгемнән.
Тамыр җәйгән гөлләр кебек
Китмисең йөрәгемнән.
Сандугачым басып сайрап
Сындырды гөлләремне.
Сынган гөлләргә охшатам
Аерылган көннәремне.

Бу җырның мәгънәсен мин еллар узгач кына аңладым. ...Кешене өмет яшәтә, ди. Ләкин әнигә анысы да насыйп булмаган. Сугышның беренче елында ук аңа кара кәгазь килгән. Ул кара елларны өзелгән өметләр белән ничек үтте икән әни?! Әтинең кабере әле дә билгесез.

Авылдашыбыз Хәйрулла бабай сугышларны исән-сау кичеп кайткач, әнигә сөйләгән: «Хәбибулла белән сугышка бергә кердек. Чыккач, кычкырып, бер-беребезне табарбыз дип вәгъдәләштек. Сугыш бик куркыныч булды. Снарядлар берсе артыннан берсе яуды. Сугыш тынгач, мин бик каты кычкырдым, кешеләр арасыннан эзләдем. Ләкин җавап бирүче булмады».

Без әтинең нинди булганын белмәдек. «Әти» дигән сүз дә сәер тоела иде безгә. Үзем генә калганда, пышылдап: «Әти» дип әйтеп карый идем. Иң кыены сугыштан әтиләр кайта башлагач булды. Әтиләре кайткан кешеләр бәхетле, ә без алар янында ким булып үстек. «Әти нинди була икән ул?» – дип, әтиле кешеләрнең ишегалдына капка ярыгыннан карый идек.

Әни безне ач итмәс өчен Казанга еш йөрде. Сарык суеп, берничә хатын-кыз базарга ит сатарга баралар иде. Әни сөйләгәннәрнең кайберләре әле дә исемдә. «Казаннан кирәк-яраклар алып, кечкенә чаналарны тартып кайтып килә. Шунда каршыма бер адәм килеп чыкты. Ә чанамда үземнең әйберләр арасында күрше карчыгының ит саткан акчасы да бар. Теге килә башлауга, ачыргаланып, башыма килгән беренче рус исемен әйтеп кычкырдым. Шуннан теге адәм ут капкандай чабып китте». Тагын бер вакыйга: «Өч хатын чана тартып кайтып киләбез. Төн уртасы җитте. Күзгә төртсәң дә күренми. Шул вакытта чаналарыбыз туктап калды. Өчәү җигелеп, бер чананы кузгатып карыйбыз, ләкин чана селкенми. Моңарчы әкрен генә кайткан чана кинәт туктап калсын әле! Бик озак азапландык. Бервакытны еракта әтәч кычкырган тавыш ишетелде, шул ук вакытта чана да шуып китте. Авылга кайткач, әбиләр, сез җенле урыннан үткәнсез, алар сезнең чаналарыгызга менеп утырганнар, ә таң әтәченнән алар куркалар, дип аңлаттылар», – дип сөйли иде. Мин әнинең тормыштан, кешеләрдән зарланганын хәтерләмим. Ул кешеләр арасында чәчрәп тормаса да, күңеле белән матур иде: һәр очракка үз мәзәге булыр иде.

Әни ач елларда, җәйнең эссе көннәрендә, кырда иген сукканда да уразасын калдырмады. Гомере буе биш вакыт намазын укып, өй тутырып, әбиләр җыеп, Коръән укытып яшәде. Бик тәвәккәл кеше булды: Казанга, Мәскәүгә баруны бернигә дә санамады. Үләр алдыннан төш күрде. «Хәбибулла алдыма намазлык җәя», – диде ул. Хәл белергә кергән күрше Вәгыйзә апа: «Терелергә, Хәлимә, Алла боерса», – дип, төшен яхшыга юрады. Ул чыгып киткәч, әни мине чакырды да: «Юк, кызым, әтиең мине үз янына чакыра, юл хәзерли. Мин аның янына китәм», – диде. Ике көннән соң әни 73 яшендә дөнья белән хушлашты. Иренә тырнак очы кадәр дә хыянәт итмәгән әни мәңгелек мәхәббәте булган әти белән очрашкандыр дигән уй күңелне азрак тынычландыра.

Әни китте. Мин ялгызым калдым. Сугыш мине тугансыз калдырды. Мин гомерем буе апалы, абыйлы кешеләргә кызыгып яшәдем. Авыр чакларымда барып сыенырлык, киңәш сорарлык, сер сөйләрлек тугансыз калдырды мине сугыш. Шөкер, үзем бу дөньяга өч кыз тудырдым. Иптәшем Рөстәм белән, әниләр өчен дә яшәп, 40 ел гомер итәбез. Бүгенге тормыштан без чиксез канәгать. Бары бер генә теләк: сугышлар булмасын, безнең әниләр узган ачы язмышларны кызларыбыз кабатламасын. Амин!

Апас районы Түбән Барыш авылында яшәүче Рушания ЯРУЛЛИНА сөйләгәннәрне Эльмира ХӨСНЕТДИНОВА язып алды.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

ЗУР КОРАБКА – ЗУР СУ ЮЛЫ

Мәдинә АВЗАЛОВА

Бик теләгәндә, хыялың тормышка аша, диләр. Хак әйтәләр икән. Казаннан якында гына урнашкан Яшел Үзән шәһәрендә хәрби корабльләр, пассажир суднолары төзелеп ятуын белсәк тә, барып, аны үз күзләребез белән күрү – күптәнге хыялыбыз иде. Һәм менә без 120 еллык тарихы булган, дөньяга танылган «А. М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» биләмәләрендә. Ни өчен дөньяга танылганмы?! Чөнки биредә ясалган «штучный товар» дөнья океаннарын, диңгезләрен гизә. Бездә – Татарстанда, бездә – Яшел Үзән шәһәренең А. М. Горький исемендәге заводында эшләнгән корабльләр ИГИЛ иярченнәрен утка тотып, Россия хәрби-диңгез флотының көчен бөтен дөньяга күрсәтте.

Еллар дәвамында төзелгән (өч елга бер корабль эшләнә, диделәр) гайрәтле ул мәһабәт корабльләрнең, завод капкаларын киереп ачып, Иделнең киң күкрәгенә төшеп ятуын, дулкыннарны киң елганың ярларына бәрә-бәрә акрын гына йөзеп китүен кайсыгызның күргәне бар?! Әйтеп-аңлатып бетергесез тәэсир... Күңелне айкап алырдай бетмәс-төкәнмәс хис...

Кайнап торган олы казанны хәтерләткән, без белмәгән, хәер, күбесен белергә дә ярамаган бу «тормыш»та – һәркемнең үз урыны. Шуңа да уңыш андагы осталарның һәркайсына, корабльнең «гомере» үзе дә, аерым алганда, һәр шөрепкә бәйле.

Өйрәнчектән – баш бухгалтерга

– О-о, бирегә килгәнче! – дип суза соравыбызга җавап бирә башлап директорның финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Алеся Илгизәр кызы ЗАРИПОВА. – Зур бер тормыш юлы артта калган сыман. Миңа хәзер 42 яшь. Ә хезмәт стажымның күпме булуын беләсезме? 25 ел! Әйе, мин 17 яшемнән саннар белән «кайный» башлаган кеше. Әлбәттә, белеме булмаганны саннар янына, исәп-хисапка якын да җибәрмиләр, – дип дәвам итә ул сүзен. – Мин башта Казан финанс-икътисад институтына читтән торып укырга кердем. Көндезгедә уку өчен бер балл җитмәде. Дөресен әйткәндә, артык борчылмадым да. Эшләп укуның үзенә бер өстенлеге бар аның. Имтихан бирергә киләсең, янында дебетны кредиттан аера белмәгән студентлар кайнаша. Ә син инде болар хакында ишетеп кенә түгел, кулыңа тотып, эшләп карап беләсең.

Беренче эш көнен ул яхшы хәтерли. Гаиләнең Түбән Вязовой шәһәрендә яшәгән чагы. Аны район кулланучылар җәмгыятенә алалар, бухгалтерга өйрәнчек итеп куялар. Ишекне ачып керүгә күзгә ташланган беренче нәрсә – һәркайда: шкафта, өстәлдә кәгазь, кәгазь, кәгазь... «Нишләп була икән бу кадәрле кәгазь белән?» – дип уйлый ул. Менә шул кәгазьләргә «җан» кертергә өйрәтәләр дә инде аны. Баксаң, ул кәгазьләрдәге саннар күзгә күренмәс җепләр белән үрелә барып, синең, юк, алай гына да түгел, син эшләгән коллективның да язмышын бер селтәнүдә хәл итә дә куя. Менә бит нинди кирәкле, нинди мөһим аның хезмәте. Үзенең ни дәрәҗәдә әһәмиятле, бер караганда, баш китмәле эш башкаруын ул азга гына да исенннән чыгармый.

– Саннарның санга туры килеп, матур гына киштәләргә урнашып баруын күрү – акционерлык җәмгыяте өчен дә, заводның стратегиясе өчен дә, бюджет өчен дә кирәкле нәтиҗә алу – аерым бер осталык, тәҗрибә сорый, – ди ул.

«Бу сыйфатларның барысы да миндә бар», – дип кенә өстәми. Тыйнак чөнки. Шулай диюгә, әтисенең әйткәннәрен исенә төшереп куя: «Ул миңа һәрвакыт бер сүзне кабатлый: «Укучы «3»легә белер. Укытучы – «4»легә. Бары Аллаһы Тәгалә генә барын да белер – «5»легә белер». Дөрес бит, бер уйласаң. Ник дигәндә, осталыкны чарлауның чиге юк. Аны берәү дә белми. Укучы гына булып башлаган эшеннән баш бухгалтер дәрәҗәсенә ирешеп, һөнәренең серләренә төшенеп, Казанга – хосусый предприятиегә эшкә күчкәндә, Алеся эшне өр-яңадан башлаячагына икеләнми. Белмәгән эше түгел үзе: шул ук баш бухгалтер вазыйфасы. Тик һәрнәрсәнең үз тәртибе, үз кагыйдәсе.

– 13 ел эшләдем мин анда, – ди Алеся Илгизәр кызы. – Алга таба да шунда эшләп кала идем. Тик көннәрдән бер көнне мине шушы заводка эшкә чакырдылар. Әлеге дә баягы, яңа директорның яңа команда туплаган чагы. Бу – 2009 ел. Ул чагында инде мин кияүдәге кеше, кызым үсеп килә, Юдинода үз йортыбыз да бар. Без дүртәүләшеп: әти, әни, ирем өстәл янына утырып, уйлашып, фикер алышып таң аттырдык.



■ «А. М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы» ачык акционерлык җәмгыяте суднолар төзү предприятиеләре арасында илдә иң эреләрдән һәм стратегик яктан мөһимнәрдән санала. Биредә бүгенге көнгә кадәр 1500 диңгез һәм елга судносы ясалган. Шуларның 600 е – хәрби корабль. 2016 елның 27 апрелендә заводта Вьетнамның хәрби-диңгез көчләре өчен эшләнгән «Гепард–3,9» фрегатын суга төшерү тантанасы булды. Тантанада Вьетнам Социалистик Республикасы Милли оборона министрлыгы, «Рособоронэкспорт», Татарстан хөкүмәте, Яшел Үзән муниципаль районы, «Ак Барс» холдинг компаниясе» ААҖ вәкилләре катнашты.

Барыргамы-бармаскасы, тәкъдимне кабул итәргәме-итмәскәме дигән сорауга җавап эзләдек. Уен эш түгел, язмышым хәл ителә бит. Уйлый торгач, уртак фикергә килдек: тәвәккәлләргә! Бу адымны ясавыма һич кенә дә үкенмим. Кем кул астында эшлисең бит.

Унҗиде яшьтән эшли башлаган кыз, читтән торып югары белем алган арада, тәҗрибәле белгечкә әверелә.

Ә безнең Ренат Искәндәрович белән таулар күчерергә була. Бик ышанычлы кеше ул. Эшли башлавыма алты ел булды. Мин – 5000 нән артык кешесе булган зур коллективның, зур корабның бер бәләкәй шөребе генә. Әмма бергә булганда без илнең оборона иминлеген тәэмин итүче олы көчкә әверeләбез — иманым камил.

Ренат Мистахов килгәннән соң бик күп нәрсә уңай якка үзгәргән. Үз командасы белән килү хикмәтеме, җитәкченең үзенең шулкадәр дә белдекле, булдыклы булуымы – соңгы алты ел эчендә бирeдә яңалык арты яңалык... Шул исәптән, завод эшчеләренә йорт салу да... Монысы инде хәзер, гомумән дә, беркайда булмаган хәл кебек кабул ителә.

PRESSA.RU



Аларның өйләнешкәннәренә яренгә 20 ел тула. «Менә шул юбилейда киярмен инде ак күлмәкне...» — дип елмая «кәләш».

Ул вакытлар...

– Ул вакытларны искә төшерә башласаңмы? – Ул серле елмая. Күренеп тора: аның өчен «ул вакытлар»ның һәр минуты кадерле, һәр мизгеле күз алдында. Әнә ничек сөйли бит...

– 1996 елның 5 сентябре иде ул, – ди саннарны тапкырлау таблицасы шикелле истә калдырган әңгәмәдәшем. – Хосусый предприятиедә эшләгән чагым. Ул көннәрдә Казанда Богдан Титомир концертлары бара иде. Бу хакта сүз чыккач, әйтеп куймыйммы: «Миңа шундый ирләр ошый», – дип. «Алайса, ярар, – ди җитәкчем, – мин сине Титомир белән таныштырам әле». Көлешеп алдык та оныттык. Берзаман кичен идарә каршына КамАЗ килеп туктады. Аннан ике чибәр егет сикереп төште дә директор кабинетына кереп югалды. Мин булачак иремә бер күрүдә гашыйк булдым. Кырынмаган да, ябык үзе, эче-эчкә ябышкан. Күрүгә үк: «Минеке!» – дидем. Башка кеше сөйләсә, ышанмас идем. Минем белән шундый хәл булды. Ул мине кичен «һава сулап керергә» чакырды. Бик теләп, рәхәтләнеп риза булдым. Без иртәнгә чаклы йөрдек, таңны бергә аттырдык. Бер-беребезгә: «Моннан ары гел шулай булыр, без беркайчан да аерылышмабыз», – дип сүз куештык. Шуннан бирле без бергә...

Әни башта Володяны кабул итмәде. Рус егете бит. Тик без бернигә карамый загска бардык та язылышып кайттык. Әни белән эти дә, эштәгеләр дә белмичә калды. Бер тартма конфет, бер шешә шампан алдык та... бөтен туй тантанасы шул булды. Соңыннан эти-әни ризалашты. Әйбәт кеше ул, игътибарлы, мине, балаларны ярата. Аның үзен дә яратмыйча мөмкин түгел. Яренгә бергә тора башлавыбызга 20 ел тула. Менә шунда бәйрәм итәрбез, дибез. Ак күлмәге дә булыр, чәчәкләре дә, кунаклар да... Сыналган мәхәббәтне тантана итү күпкә кадерлерәк ул.

«Мин аңа кырыс булдым»

Алесяның әнисе Зөлфирә ханым шулай ди. Кырыс булу бала өчен файдага гына, күрәсең. Тормышта авырлыкларны җиңәргә, сынауларны уңышлы узарга да әни холкы, әни тәрбиясе ярдәм иткәндер.

– Алесянең 3 нче сыйныфта укыган чагы, – дип сөйли Зөлфирә ханым. – Мәктәпкә киткәндә муенына фатир ачкычын тагып җибәрә торган идем. Бу моны югалткан. Елый гына бит. «Бар, – мин әйтәм, – ачкычыңны тапмыйча кайтма». Тәки табып кайтты. Сөенүләре баланың... Кырыс булдым мин аңа карата. Һәр адымын тикшереп тордым. Хәзер дә шулай. Инде гаиләсе, ире, балалары бар... Алай ук кирәкмәсен дә аңлыйм, тик башкача булдыра алмыйм.

«Кырыс булдым», – дисә дә, әле менә алты айлык оныгын: «Үзем карыйм, эшкә чык», – дип алып калган бит. Караган, үстергән дә. Хәзер өч яшь ярымлык малайның белмәгән нәрсәсе юк. «Хәтта Карл Маркс белән Ленинның кем икәнлеген дә белә», – дип көлә әнисе. Кызлары Дианага 15 яшь. Әнисенең горурлыгы ул. «Сулагай ул, – ди әнисе. – Ә сулагай балада күрәзәчелек була. Малаемны табар алдыннан, табиблар бер-бер чире юкмы дип, пункция ясатырга куштылар. Бер дә күңелем тартмады шунда. Ә Диана: «Ясатма, әни, барысы да әйбәт була», – ди. Тыңладым сүзен. Ясатмадым. Балам да сау-сәламәт туды. Тагын бер мисал: ирем ял вакытларында балыкка йөрергә ярата. Шулай бервакыт әзерләнде дә китәргә җыена. Ә кызым өзми-куймый: «Башта әбинең хәлен белеп чык», – ди. Кайнанам ул вакытларда сырхаулап тора иде. Шул килеш китеп барган. Ә балыктан кайтуына кайнанам үлгән».

Диана, чыннан да, сәләтле балага охшаган. Рәсемнәр ясый. Күп укый. «Туган көненәме, ниндидер бәйрәм уңаеннанмы, бүләк әзерләргә җыенуымны белсә, шундук кисәтеп куя: «Миңа китапка сертификат бүләк ит, әни. Башка берни кирәкми». Аннары кибеткә бара да үзе теләгән китапны сатып алып кайта. Укымаган китабы калмады инде. Әтисе бик ярата аны. Кыз бала әтисе янындарак була икән ул. Туган гына чагын хәтерлим. Баланың елап уянуы була, ирем шундук сикереп тора, чүпрәген алыштыра да, миннән сорый: «Кайсы күкрәгеңә салыйм: уңынамы, сулынамы?» – ди. Хәзер дә... карап торсаң, бер тамаша менә: «Әтием» дә, «Кояшым» гына алар...

Әйтәсе дә юк, балалар әти-әнидән үрнәк алып, аларга охшарга тырышып үсә. Кайчандыр беренче кыңгырауны мәктәп ишеген ачып кына кергән бәләкәй Алеся чылтыраткан булса, дистә еллар үткәч, аны кызы Диана кабатлый. Кайчандыр, 9 нчы сыйныфта укыганда, Алесяны актив булганы, әйбәт укыганы өчен Артекка юллама белән бүләкләгән булсалар, бүген Артекка аның кызы Диана җыена. Һәркайда беренче булган әнисен кабатламыйча тагын кемне кабатласын инде ул?!

Бәлкем, әле киләчәктә Диана да әнисе кебек финансист булыр. Кем белә? Әйтеп булмый. Әнә бит, Алеся үзе дә бу һөнәрне сайлармын дип, бер дә уйламаган. Гайшә әбисенең каны тартканмы, әнисенекеме? Кемгә генә охшамасын, кемнең генә геннары уйнамасын, бүген ул мактаулы, белдекле һөнәр иясе. Хезмәттәшләренең ышанычы, терәге. Миңа калса, әлеге коллективта бары шундый кешеләр генә эшлидер сыман. Ни дисәң дә, хезмәтләре бик җаваплы, бик җитди бит аларның. Завод идарәсе каршында биредәге эшчеләрнең хезмәтенә һәйкәл булып торган «Калюжный» бронекатеры да, аннан ерак түгел генә урнашкан завод музее да, заводның «Дельфин» санаторие дә, яхта клубы, мәктәбе булу да күп нәрсә турында сөйли. Әйтерсең, алар үзләренә аерым бер дәүләт. Һәм бу дәүләтнең үзләре генә белгән, үзләренә генә кагылган үзгәрмәс кануннары, тәртипләре бар. Һәм ул беренче чиратта кеше мәнфәгатьләрен кайгыртуга юнәлтелгән.

...Аның бүлмәсен берсеннән-берсе матур гөлләр бизи. Арада «Хатын-кыз бәхете» дигәне дә бар. «Бу гөлнең чәчәк атканын күргәнегез бармы?» Ул шулай дип сорый да, шундук җавабын да бирә: «Әллә ничә елга, ә бәлкем гомергә бер чәчәк ата торган гөл ул. Малай белән йөккә калыр алдыннан атты бит ул минем. Искитәрлек...» – дип куя.

Очраклылыкмы? Юк, шәхсән мин үзем андый нәрсәләргә ышанмыйм. Тормышта берни дә агымсудай эзсез югалмый. Барысы да әйләнеп кире үзеңә кайта. Хәтта гөлләр дә шушы канунга буйсынып яши. Һәм алар үзләренә ихластан куанучыларга гына йөзләрен ача. Бу – синең мәхәббәтең шикелле, яраткан эшең шикелле, киң Иделдән юл алып, диңгезләр айкап йөргән кораб шикелле... Кабатланмас, үрелеп тә буй җитмәс. Бәхет формуласы шундый ул!

ТАРИХЫ ДА ДАНЛЫ



■ Завод 1895 елдан эшли башлый (ул әле башта суднолар ремонтлау мастерское дип йөртелә). Заводның Идел буенда – Россиянең үзәгендә урнашуы аңа көймәләрнең су юлы буйлап, Кара диңгезгә, Каспийга, Ак диңгезгә, Балтыйк һәм Баренц диңгезләренә озату мөмкинлеге бирә.

■ 1934 елда беренче оборона заказы алына һәм елга бронетанкеры төзелә башлый. 1942 елда эшчеләрнең акчасына «Калюжный» БКА-75 бронекатерын төзергә карешәләр. Ул ел ахырында суга төшерелә һәм 1943 елның 5 августында Каспий хәрби флотилиясе составына кертелә. 1967 елдан һәйкәл буларак урнаштырыла *(фотода)*.

■ 1966 елда яңа техника җитештерүдәге казанышлары өчен завод Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

■ Биредә 1967 елдан 1994 елга чаклы «Альбатрос», «Ягуар» (ГДР, Куба, Югославия, Алжир, Ливия илләре өчен) көймәләре, катерлары эшләнә. 1972 елдан 1995 елга кадәр – «Звук» дип аталган суднолар җитештерелә.

■ Завод дөньяда беренчеләрдән булып уникаль, тиз йөрешле суднолар һәм корабльләр ясаучылар исәбендә йөри. «Метеор» пассажир теплоходы, «Сокол» корабле, «Бора» һәм «Самум» ракета корабльләре шушы завод капкасыннан чыккан.

■ 1997 елда заводта эре габаритлы металл конструкцияләр әзерли башлыйлар. Соңгы елларда гамәлгә ашкан мөһим проектларның берсе – А145 проекты буенча эшләнгән тиз йөрешле пассажир теплоходлары; RST25 проекты буенча нефть ташу танкерлары; «Грачонок» катерлары; «Буян-М» кече ракета корабльләре, шулай ук «Гепард–3.9» фрегатлары...

■ Бүгенге көндә заказ буенча «Грачонок» катерлары, патруль корабльләре, кабель суднолары эшләп чыгару дәвам итә.

■ Предприятие кадрлар сайлап алуга, квалификация үстерүгә, эшчеләргә лаеклы хезмәт хакы түләүгә, аларның сәламәтлегенә зур һәм җитди игътибар бирә. Заводның 120 еллыгы уңаеннан эшчеләр өчен «Красный металлист» торак комплексы төзеп тапшырылды. 78 гаилә яңа фатир алды. Бу комплекста 2020 елга кадәр тагын 10 йорт сафка басачак. Заводның үз мәчете, чиркәве һәм «Дельфин» дип аталган санаторие бар.

■ Былтыр заводның сугышчан һәм хезмәт даны музеенда төзекләндерү эшләре төгәлләнде.

PRESSA.RU















Лия Заһидуллина! Беләм, берәү дә миннән: «Кем ул?» дип сорамаячак. Аның Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Халыкара телевидение һәм радио академиясенең гамәли әгъзасы булу-булмавын да тикшермәс. Лия Лия инде ул. Чибәр ханым. Талантлы тележурналист. Бай эрудицияле, кызыклы әңгәмәдәш. Мин әле Лия Заһидуллина – экран йолдызы, дигән җөмләмне юри әйтми торам. Чөнки беләм – һәр кеше, Лия Заһидуллина исемен атауга шунда ук зәңгәр экраннан елмайган «Ханым»ны яисә эчке дулкынлануын тыя төшеп, «Чын күңелдән» җитди итеп сөйләшкән дикторны күз алдына китерәчәк. Бу нәфис йөзгә, лалә сабагыдай гүзәл буй-сынга елмаю да, җитдилек тә бик килешә.



Асия ЮНЫСОВА

СӨЙКЕМЛЕ СӨЯК

Төрле төбәкләрдә булырга туры килгәндә андагы телевидение дикторлары белән үзебезнекеләрне чагыштырып карау гадәтем бар. Мин һәрвакыт канәгать кала идем: «Безнең Лия яхшырак! Чибәррәк! Акыллырак! Зифарак!» Моннан илле ел элек пар кара толымнан экранда күренгәннән бирле яратабыз бу сөйкемле сөякне.

Юбилее алдыннан өенә килгәч, мин аның Татарстан телевидениесе белән узган илле елда бер тамчы да үзгәрмәгәнен күреп тә сөендем. «Үзгәрдем», – ди үзе. Карлыгач канатыдай чәчләренең аккош каурые төсенә керүен генә әйтмәгәнен аңлыйм. Чөнки телевидениедәге өзлексез иҗат тормышында – телетапшырулар, телефильмнар булдыру барышында ул бу катлаулы медиачараның бөтен нечкәлекләрен өйрәнеп, күп нәрсәне үзе башлап йөреп, тәмам аска әйләнгән, димәк ки, үзе дә нисби үзгәрешләр кичергән. Гап-гади бер диктордан «Татарстан» дәүләт телевидение һәм радиокомпаниясе директорының урынбасары дәрәҗәсенә кадәр юл үтеп кара әле син! Үзгәрмәс җиреңнән үзгәрерсең! Үзең үзгәрү бер хәл. Сиңа җеп кебек тагылган, синең идеяләреңә ышанган һәм һаман яңарып торган иҗат төркемеңне, альпинист кебек, биектән-биек үрләргә таба алып менеп кара әле син! Ул җитәкләгән коллективның елның-елында халыкара, Бөтенроссия, Татарстан конкурс-бәйгеләрендә һаман саен алдырыклар (призлар) ала торуына ияләштек, моны бер гадәти хәл саный башладыкмы әллә?

Юбилей көннәрендә кеше хатирәләр йомгагын сүтүчән. Шул форсаттан файдаланыйк әле. Димәк, Лия Михайловна белән өендә очрашабыз.

Мине хатирәләр аягүрә каршы ала. Түрдә Лия ханымның портреты. Бөтен буена! Тереме әллә дип, килеп күрешүең дә бар. Ярый әле Лия ханым үзе янымда тора – ялгышмыйм. Бу портрет мәшһүр Бакый Урманче ясаганы түгел әле. Аныкы, мөгаен, музейдадыр. Һәр экспонат янында туктылсам, Эрмитаж галереясындагы кебек, озакка каласымны аңлыйм да, төрле илләр, төрле халыклар мәдәниятеннән хәбәр булган курчаклар, сувенирлар тулы шкафлар яныннан үтеп, фатирның үтә дә оригиналь бизәлешенә, дизайнына сокланып (иҗат кешесенең фатиры әнә шулай эксклюзив була торгандыр инде ул), балконына узам. Анда юбилей көнен көтеп төш күреп утырган бәллүр гөлсарларга карап елмаям: «Көтегез, матурларым, озак калмаган. Бик тиздән



Ләйсәнә САДРЕТДИНОВА:
«Халкым минем...» тапшыруларының идеясе, мөгаен, Лия Заһидуллинаның Төркиядә, Европа илләрендә яшәүче татарлар турындагы фильмнарын карагач тугандыр. Инде менә мин дә аның кебек, иңнәремә кинокамера куеп, дөнья әйләнеп чыктым».

сез ак, кызыл розаларны, каллаларны, орхидеяларны, лаләләрне кочып утырырсыз». Ә мин тәрәзәдән Лия ханым көн дә күзәтә торган манзараны карыймчы. Юк, бу моннан ун ел элек күргән манзара түгел инде. Чөнки фатиры бүтән. Ул вакытта Татарстан урамындагы йортның уникенче катындагы тәрәзәләрдән Сөембикә манарасы, Университет биналары, төнге ут-энҗеләр белән бизәлгән үзәк урамнар, иң мөһиме – Лия ханымның бишеге – Яңа Бистә урамнары күренә иде. Без ул Бистәгә, мөгаен, бүген дә әйләнеп кайтырбыз. Хатирәләр башы, туган телнең беренче аһәңнәре шунда калган лабаса.

Кабат бүлмәгә керәм. Антиквар өстәлдә өр-яңа компьютер. Юк, хәзер инде ноутбук. Аңа әле һаман көзге сөялгән икән. Эш өстәле бу. Җәмгыятьтә әһәмиятле урын биләгән һәм чибәр булудан тәм таба белгән хатын-кызның эш өстәле. Йокысыз төннәрдә туган күпме матур да, креатив та идеяләр шушы өстәлдән старт алгандыр.

Лиягә, бәлки, әнисе Мәрьям кебек, табиб буласы калгандыр. Лиянең әтисе дә хирург «корбаны» лабаса. Чибәр лейтенант-разведчик өч тапкыр яралана, өчесендә дә кыр госпитале хирургы Мәрьям Заһидуллина өстәленә эләгә. Сугыш юлын Сталинградтан башлаган бу икәү Берлин шәһәрендә өйләнешә. Тәвәккәллеге әнисеннән мирас итеп алган сыйфаты икән. Хәер, бөтен булмышын авыруларның гомерен ялгауга багышлаган табиб-хирург кызын махсус тәрбияләп, көйләп утырмаган. Бу вазыйфаны миһербанлы, әмма нык куллы Бибиәсма әбекәй башкарган. Иң әүвәле ул оныгын, бөтен әбекәйләр гадәтенчә, тәмле кабартмасумсалары белән күпертеп үстергән, аннары туган тел оеткысын бала күңеленә онытылмаслык итеп салып калдырган. Театр училищесында сөйләм телен укыта алырлык тел осталыгы менә кайдан килә. Югыйсә русча тапшыруларны алып бара торган дикторның хәленә кергән булыр идек. Татарча сәлам биреп, русчага күчүләренә ияләшеп беттек лабаса.

PRESSA.RU

– Әйе, татарчам Бибиәсма әбием казанышы. 16 яшемә кадәр аның белән үстем. Әнием гел эштә булды. Әбекәем миннән бер авыз сүз русча әйттермәде. Русча сүзне ишетмәде дә. Минем янга килгән сыйныфташ кызларга, русча эндәшсәләр, ишек тә ачмый иде. «Исәнмесез, Лия өйдәме?» дисәләр, айдай балкып: «Әйдүк, әйдүк, түрдән уз, балам», – дип каршылар иде. Әнә шулай, үз ысулы белән көрәште әбекәем минем татар телем өчен. Таныш түгел сүзләрне язып алу өчен махсус дәфтәр йөртә идем.



Эльмира ЗАКИРОВА:
«Лия ханым белән «Борис Полевой» теплоходында алты мәртәбә яшь журналистларның «Алтын каләм» семинарларын уздырдык. Мәктәп укучылары аңардан камера плюс каләм осталыгына өйрәнсәләр, мин хатын-кыз хәйләләрен оттым. Чемоданга рулон итеп төреп салганда күлмәкләрнең бөгәрләнми икәнен ул өйрәтте».

Хәтерлим мин ул спорт киеменең кесәсенә дәфтәр тыккан, уң кулына теннис ракеткасы тоткан кызны. Ул кызның кулында кыш көне чаңгы таяклары да була торган иде әле.

– Ерак Кабанны йөзеп чыга ала идем, чаңгыда егермешәр километр уза торган идем.

Спортны шулай яраткан кеше өчен автомобиль нәрсә ул менә – иптәшме, әллә шулай ук тренажермы?

– Остап Бендер әйткән бит: автомобиль байлык түгел, бәлки хәрәкәт итү чарасы, дип. Мин аның белән килешәм. Менә 37 ел инде машина йөртәм. «Жигули»дан башлаган идем, «Тойота»га җиттем. Тормышымны машинадан башка күз алдына да китерә алмыйм. Мин машинага утырганда Казан урамнарында өч кенә хатын-кыз рульдә иде. Берсе – таксист, икенчесе – Нәҗип Җиһанов хатыны Нина Ильинична, өченчесе – мин. Минем эшемдә җитезлек һәм мобильлек иң кирәкле сыйфатлар. Җәяү йөреп кенә күп эшкә җитешеп, өлгереп булмый ул.

– Күп кыйтгаларны урап чыгарга өлгергән тырыш Кырмыска – Лия ханым сызган картага гына күз салсаң да, җитезлекнең нәтиҗәсен күрергә мөмкин. Тырышлыкка мәхәббәт кушылган сәяхәтләрнең кайсына тукталырга белмим. Шулай да иң әүвәле мең яшәр Казаныбыз буйлап йөреп чыгу дөрес булыр. Башкаланың меңьеллыгына йөз фильм төшерү идеясе Лия Заһидуллинаның иң зур казанышы дияр идем. Бүген бик күп борынгы урамнары, архитектур җәүһәрләре югалган шәһәр үзе дә бу фидакарь ханымга рәхмәтледер. Лия ханым төшереп калдырган бу йөз фильм 14 кассетада искермичә, кыйммәтен җуймыйча киләчәккә барачак, безнең Казаныбызның документаль биографиясе рәвешендә озак яшәячәк әле. Фильмнарның байтагы Казан Кремленә багышланган, аларда әле Иске Татар Бистәсе дә исән, Печән базары да шаулап тора. Бу йөз томга, йөз фильмга сыенган тарихта татарның мәгърифәтчеләре дә, галимнәре дә, сәнгать әһелләре дә, гомумән, исемнәре инде онытыла, хәтердән җуела башлаган шәхесләрнең байтагы зурлап түргә «утыртылган». «Фильмнарны төшерү өчен акчаны күп вакыт үзем таптым, – ди Лия ханым. – Миңа Леонид Девятых, Роберт Хисамов, Салават Юзеев ярдәм иттеләр. Аларның эзләнүләре соңыннан китаплар булып дөнья күрде. Иске Татар Бистәсе турында гына да биш фильм төшердек. Ә элекке хәлендәге Бистә үзе хәзер юк та бит инде. – Кеше хезмәтен күрә, олылый белә Лия ханым. Шагыйрь, галим, тәрҗемәче Равил Бохараев белән хезмәттәшлеген дә сагынып искә ала. – Без иҗади тандемда берничә ил буйлап йөреп кайттык. Нәтиҗәдә, Һиндстан, Англия мөселманнары турында фильм төшерелде».

Телеоператор сыйфатында, иңгә кинокамера куеп кузгалган юл башында Төркия иде бугай.

– Әйе, Төркиягә генә дә унбер тапкыр барылды. Европаның Венгрия, Франция, Англия, Швейцария, Монако кебек илләре, шәһәрләре күрелгән, ул илләрдән дистәләгән тапшырулар әзерләнгән. Иң беренче чит илдә төшерелгән фильм Төркиядәге «Сөннәт туе» булган иде. Чит илләрдәге Сабантуйлар да калмады. Чит-ят җирдә ике татар күрсәм, кинокамерамны төби идем инде.

Күп күргән кешегә ничегрәк – борынгы шәһәрләр фонында безнең Казан нык оттырамы?

– Һич юк. Казан – иң матур шәһәрләрнең берсе. Әллә Европа шәһәрләрен гел тарихи урыннардан гына тора дип уйлыйсызмы? Безнең Казанның үз йөзе бар. Мәскәү белән Питер Казан янәшәсендә соры шәһәрләр. Аларда кеше – ком бөртеге. Безнең шәһәр кешене зурайта. Син Казанда үзеңне шәһәр белән тиңдәш итеп күрәсең. Мин үзем менә Болак буен яратам. Төнге утлар янганда әкият кебек була ул. Камал театры тирәсендәге фонтаннар үзе бер могҗиза! Төннәрен җәүһәр кебек балкып торган Колшәриф мәчетен әйт син!

Казан шәхесне зурайта дип, бөтенләй яңа сүз әйттең әле. Димәк, бу хакта элек үк уйлангансың. «Ханым» дигән тапшырулар циклы шул уйланулар йомгагы булмадымы икән.

– Уйланулар йомгагы да, зур шәхесләр белән очрашулар җимеше дә булгандыр инде ул – 15 елга сузылган цикл. Сәкинә Шәймиева язмышына сокланудан башланган иде. Аннары бу цикл мине гаҗәеп шәхесләр белән очраштырды. Изге Коръәнне тәрҗемә иткән Валерия Порохова да, табиб-профессор Динә Табиева да, тел галиме, профессор Флера Сафиуллина да, дәүләт эшлеклесе Дания Дәүләтшина да «Ханым» каһарманнары булды. Остазым – мәшһүр Валентина Леонтьева турында да фильм эшләп калдык. Мәскәүдә

дикторлар курсына баргач, ул мине үзе сайлап алган иде. Аның белән шәхси дуслыгыбыз утыз ел – дикторның вафатына кадәр дәвам итте. «Чын күңелдән» тапшыруларын үзебездә башлап җибәргәч, аның сыман булырга тырыша идем. Киенүем генә түгел, сөйләмем дә аныңчарак китә иде бугай. Һәр җөмләне яттан белергә дә, залдагы йөзләгән тамашачы арасыннан шул җөмлә тәгаенләнгән кешене оптик төгәллек белән табып ала белергә дә ул өйрәтте мине. Ә бу – гаҗәп кыен нәрсә! Башлаган сүзең беткәндә нәкъ кирәкле кеше янында туктап калу, аңа микрофон сузуны әйтәм. Әгәр кешесен ялгыштырсаң, нинди конфуз чыгасын күз алдына китерү дә кыен.

Тамашачы яки чакырылган кунак белән эшләү, гомумән, җайсыз нәрсәдер ул.

– Алар өчен үзең генә сөйләгәндә бик үк кыен түгел әле ул. Ә менә телекамерадан бүкәйдән курыккан кебек курыккан кешене экран каршысына яки сәхнәгә чыгару кадәресе хәйләсез генә булмый. Бервакыт шулай Менделеев химия заводыннан тапшыру әзерләдек. Героем миңа химик тәҗрибәне яхшылап аңлатты. Аңладым инде. Бик тырышсам, камера каршында да үзем дә башкарып чыга алам. Ә миңа шушы кешенең әлеге тәҗрибәне үзе эшләп күрсәтүе кирәк. «Аңламадым», – дим. Бу тагын кабатлый, ә мин тагын берни «аңламыйм». Тәмам йөдәп бетте бу мин «дивана» белән. Ахырда, кулын селтәде дә, тәвәккәлләп, үзе чыкты операторлар каршына.

Камера, бигрәк тә туры эфир булганда, каушата инде ул. Ә сезнең өчен телевизор экраны бер балкып алу, хәтта ки «яшәп алу» урыны сыман. Күз өстендә каш туташ-ханымнар әле мода өлкәсендә дә тон биреп торалар. Хәзер әнә титрларга «дикторның күлмәге фәлән бутиктан» дип, спонсорларга рәхмәт сүзләре дә языла.

– Мин киемнәремне «Мода йорты»нда тектерә идем. Хәзер инде күлмәк табу авыр мәсьәлә түгел. Ә менә элегрәк, чыннан да, киенү үзе бер осталык, үткенлек таләп итә иде. Минем тегүчеләрем хәтта үзара көндәшлек чире белән «авырыйлар» иде. Берсе әйтә бервакыт: «Лия сеңлем, мин теккән пальтоны бик яратып киясез. Андый пальто Казанда түгел, Мәскәүдә юк. Ә бит күрмиләр!» Ак пальто иде ул. Яз-көз кия торган. Биле өзелеп тора. Килешә инде миңа, бик килешә. «Ярар, күрерләр, күрсәтермен», – дип, тегүчемә вәгъдә бирдем. Командам белән Суворов училищесының тынлы оркестры турында махсус фильм әзерләдек. Мин шул пальтомнан училище каршында йөренәм. Кулларымны кесәмә тыгып алам, имеш, пальтоның кесәсе дә бар. Матур уелган якаларымны күтәреп куям. Кыскасы, тегүчегә биргән вәгъдәмне үтәдем.

Егерме еллап «Диктор-ТВ» студиясен җитәкләгән остаз каләмле дикторлар әзерләгәндә һөнәрнең әнә шундый, ягъни киенүгә, бизәнүгә бәйле нечкә якларын да өйрәтәме икән?

– Иң элек мин алардан ике телдә камил сөйләшә белүне, хатасыз яза алуны таләп итәм. Аннары инде хатын-кыз серләренә чират җитә. Әйтик, хатын-кыз, бигрәк тә диктор, тантананы алып баручы сәхнәдә фәкать биек үкчәле туфлидән генә йөрергә тиеш, дип, колакларына киртлим. Биек үкчә сынны турайта, карашны горур итә, биек үкчә кигән хатын-кыз вак-вак кына итеп, матур атлап йөри. Ул инде сәхнәдән солдат адымнары белән чыгып китмәс. Минем әнә утыз ел элек кигән туфлиләрем дә бүген алып киярлек. Аяк үлчәмем дә шул килеш, гәүдә авырлыгым да. Бу – үз-үзеңне контрольдә тоту нәтиҗәсе. Белгәнегезчә, иң зур тәрбия чарасы – шәхси үрнәк!



Илдар КЫЯМОВ:
«Телевидениегә килүемдә Лия Михайловнаның роле зур. Чөнки аны күреп, сокланып үстек. Мин аның командасында эшләп, аңардан осталыкка өйрәнгән Инсаф Абдулла, Эльза Гобәй-дуллина кебек дикторларның уңышларына сөенәм».

Сәхнә сүзе чыкты. Сез алып барган кичәләр онытылырлык түгел. Бер сүз белән «сүнеп беткән» залны кабат уята торган идегез. Шаляпин исемендәге опера, Нуриев исемендәге балет фестивальләрен, «Уңыш бәйрәмнәрен» шәп итеп алып бардыгыз да соңыннан шул мәдәни чараларның режиссерына, сценарий авторына, жюри әгъзасына әйләнеп куйдыгыз. «Ел хатын-кызы», «Бәллүр каләм», «Алтын каләм» бәйгеләрен Лия Заһидуллинадан башка күз алдына китерү кыен — ул башкаларны бәхетле итү серен белә булыр.

– Чыннан да, һәр кеше җиңү бәхетен татырга тиеш. «Бәллүр каләм» үзе дә мине беренчеләрдән булып тапты. Медальләрем дә бар. Халыкара бүләкләрем дә. Арада берсе аеруча кадерле. Әллә исеме артык купшы булганга микән? Минем иҗат төркемем төшергән «Казан ханлыгының мәшһүр ханымнары» дигән фильмнар өчен Алматы шәһәрендә узган телевизион конкурста мине, тамашачылар тавышын җыеп, «Җәүһәр диплом» белән бүләкләделәр. Ялтада узган халыкара форумнан да алтын медаль алып кайткан идек. Барысын да саный китсәм, мактануга охшый башлар. Әниемнең васыятенә тугры каласым килә. Ул миңа: «Тыйнак бул!» – дип тукып тора торган иде. Тыйнаксызлана күрмим тагын.

Олы дәрәҗәләрне, мактау сүзләрен сезнең белән бергә юбилеен билгеләп үтүче «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең дә казанышлары итеп кабул итәбез. Чөнки Сез бу каналның тере легендасы, сөйкемле сөяге, яшь дикторларның остазы. Чылбыр өзелмәсен.

PRESSA.RU



КАЙДА СОҢ УЛ СОҢГЫ ЧИК?



Мәдинә КАШАПОВА

КАЙЧАН УЛ «ГАИЛӘ ЭШЕ» БУЛУДАН ТУКТЫЙ?! ӨЙДӘГЕ НИЗАГЛАРНЫҢ КӨНДӘЛЕККӘ ӘВЕРЕЛГӘН МӘЛЕННӘНМЕ? ИРНЕҢ ХАТЫНГА БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КУЛ КҮТӘРГӘН КӨНЕННӘНМЕ? МИНУТ ЭЧЕНДӘ ГЕНӘ БАРЛЫККА КИЛМИ БИТ АНЫҢ СӘБӘПЛӘРЕ.

Бу дөнья тәмугында...

Ир – баш, хатын – муен, дибез. Гаиләдә ир кешенең баш булуы хатыны белән дә, балалары белән дә дөрес мөнәсәбәтләр кора белүендә, гаилә тормышы җылылык, наз һәм ярату белән өртелгән булуда чагыла. Шундый очракта гына ата сүзе гаиләдә бәхәссез кабул ителә. Кызганыч ки, берберсен ярты сүздән аңлап, яратышып яшәгән бәхетле гаиләләр хакында түгел бүген сүзебез.

Җөмләне элек-электән шулай килгән инде ул, дип башларга мәҗбүрмен. Иренең каты кулын тоеп, изелеп яшәргә дучар ителгән хатыннар җитәрлек әле арабызда. Кыйналып, кагылып яшәүгә, хәтта ки сексуаль җәберләүгә ireннән курыкканга гына түзеп тормый хатын-кыз. Психологлар тиран ирдән аерылып китә алмауның сәбәбен хатын-кызның мөстәкыйль булмавы, ireннән, аның акчасыннан, фатирыннан башка яши алмавы белән аңлата. Өйдәге низагка, сугыш-талашка, исереп кайткан ирнең тормышны газапка әверелдерүенә күз йомып, теш кысып түзүләр, ахырда бик күңелсез тәмамлана. Бер уйласаң, кемгә кирәк инде мондый сабырлык? Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгыннан алынган кайбер мәгълүматларга күз салыйк та, уйланыйк. Бу мисаллар, бу саннар гыйбрәт өчен китерелә.

«Сөяркәгә сүз әйтмә»

Былтыр җәй көне бөтен Татарстан халкын аякка бастырган вакыйганы күпләр ишетеп беләдер. Питрәч районының Ленино-Кокушкино авылында булган хәлләр белән танышкач, чәчләр үрә тора. Иң «крутой» кинофильмнарың бер якта торсын. Хөкем карарындагы юлларны укыгач, түбәндәге күренеш күз алдына килеп баса:

...Җәй уртасы, көн кичкә якынлашып килә. Бу төндә авылда тетрәндергеч вакыйга буласын әле берәү дә белми. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының тернәкләндерү үзәге директоры урынбасары, алтмыш яшьлек Марат Била-



СЫЕНЫР УРЫН БАР!

Ире залим булган, бертуктаусыз кыен ашап яшәгән хатыннарга кая барып сыенырга? Нишләргә? Аларның күбесе: «Китәр идем. Сыеныр почмагым юк», – дип, түзә ич. «Барыр җирем юк», — диләр алар. Чыннан да, аларга кая барырга, ярдәм сорап кемгә мөрәҗәгать итәргә? Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга дигәндәй, без дә ныгытып эзли башлагач, таптык «вакытлыча сыенып торыр урынны». «Добро даром» хәйрия фонды исәбенә оештырылган һәм «Кризис үзәге» дип аталган социаль кунакханә инде былтырның сентябрь аеннан бирле эшли икән. Үзәк җитәкчесе Раушан ХӘКИМУЛЛИН сөйли:

– Безнең төп максатыбыз – бәлагә тарыган әниләргә, иренең җәберләвеннән качкан ханымнарга, социаль ятимнәргә ярдәм күрсәтү дә инде. Барлыгыбызны баштарак белеп тә бетермиләр иде. Без үзебезне белдерер өчен видеороликлар эшләдек, җир асты юлларында, кеше күп йөри торган урыннарда игъланнар элдек. Белсеннәр, күрсеннәр, безгә килеп, вакытлыча гына булса да, үзләренә сыеныр почмак тапсыннар дибез. Мөрәҗәгать итүчеләрнең берсенең дә үтенечен кире какмыйбыз, борып җибәрмибез.

Бәбиләрен бала тудыру йортында калдырырга җыенган әниләр белән дә эшли безнең үзәк. Кайсының бәләкәчен алып кайтыр урыны юк; кайсылары ирсез тапкан да, әти-әнисе өйгә кертми; кайсы бөтенләй үк чит төбәктән. Без 4 нче бала тудыру йорты белән һәрдаим элемтәдә.

Кунакханәбез әлегә зур түгел. Ул алты кешегә исәпләнгән. Бүген исә үзәктә бәбиләре белән дүрт әни яши. Аның берсе – Таҗикстаннан. Ире хатынны сигез айлык көмәне белән ташлап киткән. Әни кеше бәбиен бала тудыру йортында калдырырга теләгән иде. Без сөйләшкәннән соң, кире кайтып төште. Икенчесенең әти-әнисе эчә, ул анда баласын алып кайта алмый. Өченчесен, игезәк бала табуга ук, ире ташлаган. Дүртенчесе – Башкортстаннан. Аның ире начар кеше булып чыккан. Өйдән чыгып киткәндә, ире аны акча урлауда гаепләп, судка биргән икән. Ярдәмгә килмәсәк, ни белән беткән булыр иде?

Әле күптән түгел бездә ике баласы белән бер хатын яшәп китте. Ире – чын мәгънәсендә, палач. Ир беркайда эшләми. Хатыны эшкә киткәч, балалары елый башлады исә, тота да кыйный икән. Ә бервакыт кечкенә малаен башы белән салкын суга тыгып җәзалаган. Алар үзәктә ай ярым торып киттеләр. Хатын янә шул иренә кайтты.

Бүгенге көндә тормышларына куркыныч яный торган 53 хатын-кыз бар. Алар белән социаль яклау үзәкләре аша элемтәдә торабыз. Әлбәттә, безнең «оябыз» бик кечкенә, ә килергә теләүчеләр күп. Шуңа Кризис үзәкләрен республиканың һәр районында оештыру тәкъдиме белән чыктым.

Безнең өчен иң мөһиме – кисәтү. Ятимлекне кисәтү, җинаятьне кисәтү, бәла-казаларны булдырмый калырга ярдәм итү... Хокук саклау органнары җинаять инде кылынгач, буласы булгач кына эшкә керешә.

Безгә бер тиен акчасыз калган хатыннар да килә. Алар үзәктә иң күбе өч ай яши ала. Шулай каралган. Шул вакыт эчендә йә алар ирләре янына кайта, мөнәсәбәтләрен көйли, йә яшәр урын табып, эшкә урнаша. Өч ай аз вакыт түгел. Бик теләгәндә, моны эшләргә була.

Ярдәмебезгә мохтаҗлар өчен безнең телефон:
+7 (937) 009-09-60; +7 (987) 228-48-91.

PRESSA.RU

ловның 40 ел бергә гомер иткән хатынын ерткычларча кыйнап үтерүе авылдашларын тетрәндерә. Низаг чыгуның сәбәбе җитди, әмма хәл итмәслек булмый. Хатын иренең өйгә сөяркәсен алып кайтуын ошатмый. «Ичмаса, яшермисең дә, күз алдында кыланасың...» – ди хатын. Иргә шул җитә кала. Ярты сүздән котырып киткән ир хатынын идәнгә сузып сала да, типкәли, кыйный башлый. Тикшерүчеләр хатынның тәнендәге күгәрекҗәрәхәт эзләре буенча ирнең егермеләп мәртәбә сукканын ачыклыйлар. Шашынган ир «аңына» килгәндә, хатын инде үлгән була.

Көнкүрештәге җинаять — ул баланы балачаксыз итә торган гаилә фаҗигасе.

Документлардан күренгәнчә, Билалов, хатынын үтергәннән соң, җинаять эзләрен яшерә башлый: корбанын караватка күтәреп сала, киемнәрен алыштыра, идәнне сөртеп чыгара һәм... видеокүзәтү камерасындагы язуларны алып куя. Әйтәм бит, без коточкыч дип караган фильмнарың бер якта торсын. Инде төш җиткәндә генә ул туганнарына, дусларына: «Хатын баскычтан егылып үлде», – дип шалтырата. Туганнары килеп керүгә «спектакль» уйнарга керешә: елаган була, мәетнең суына башлаган тәне өстендә ясалма сулыш ясаган булып кылана. Сөяркәсенә шалтыратып: «Исеңдә тот! Бу төндә мин синең яныңда булдым», – дип үзенә алиби булдырмакчы була. Ашыгыч ярдәм машинасы белән килеп җиткән медиклардан мәетне медицина экспертизасына җибәрмәүләрен сорый. Хатынының йөрәк өянәгеннән үлүе турында белешмә бирүләрен үтенә.

Соңыннан Билалов хатыны белән низаг чыгуын, аңа сугуын таный. Әмма хатынының ул кыйнаганнан соң вафат булуын кире кага. Аннан гына кеше үлми, янәсе. Кыскасы, ул ни әйткәнен дә аңламый бугай. Әле «баскычтан егылып үлгән», әле «өйгә кергән угрылар үтергән» ди. Күрсәтмәләрендә буталып бетә.

Суд аның гаебен тулысынча исбатлый. Һәм Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәре «гадәттән тыш хәлләр»е өчен җиде елга ирегеннән мәхрүм ителеп, катгый режимлы колониягә озатыла.

Түзә һәм кичерә

Юктан гына, тиктомалдан гына чыга тавыш. Кунакка барган җиреннән ире хатынын өйгә әйдәкли. «Кайтыйк та, кайтыйк!» Тиккә генә ашыктырмаган икән ул хатынын. Кулы кычыткан булган. Бусаганы атлап керүгә үк Михайлов (фамилиясе үзгәртеп бирелә) хатынының чәченнән эләктереп ала да башы белән стенага бәрә. Салмыш иренең моның белән генә тукталып калмаячагын белгән хатын фатирдан кызы белән чыгып йөгерәләр. Ләкин ерак китә алмыйлар. Баскычта ир аларны куып тота, хатынны бетон идәнгә егып, башына, аякларына, гәүдәсенә тибә башлый. Моны күреп торган 12 яшьлек кыз әнисенә ярдәмгә килмәкче була. Тик Михайлов үги кызын, киеменнән эләктереп алып, баскычтан очыра. Корбаннарына өйгә керергә боера. Ана белән кыз, һичнинди каршылык күрсәтмичә, гипнозланган шикелле янә өйгә керәләр. Ир, кулындагы швабра таягы сынганчы, үзе арып туктаганчы, кыйный аларны. Соңыннан баланы буа башлый. Ярый да кыз аның кулыннан ычкынып кача. Хатынына һәм балага Михайлов үтерәм, дип яный.

Шушы хәлләргә дә карамастан, хатын судта, җәбер күреп яшәүче йөзләгән-меңләгән хатыннар шикелле, ирен яклап чыга. «Зинһар, төрмәгә утыртмагыз, ул исерек иде, нәрсә кылганын аңламады», – дип яклый. Бары тик зыян күрүченең үтенече, кем әйтмешли, беркемгә дә кирәк булмаган «киң күңеллелеге» генә саклап кала ерткычны төрмәдән. Шартлы рәвештә бирелгән җәза вакыты, андый залимнар өчен срок түгел инде ул. Менә бит хатыннар нишли?! Барын кичерә, гафу итә, ә моны шулай булырга тиеш дип кабул иткән ир корбанын җәберләүне дәвам итә. Минемчә, мондый очракта, зыян күрүчесе, хатыны булган очракны әйтүем, гаепләү мотивы итеп корбаннар фикере китерелергә тиеш түгел. Эш нәкъ менә факт буенча каралырга тиеш. Югыйсә ирен саклап калган хатыннар соңыннан йә гомер буе кыйналып яши, йә гомерләре яшьли өзелә. Шуңа да бит әнә бездә көнкүреш җинаятьләре артканнан-арта бара.

Әле күптән түгел генә Бөгелмәдә булган хәлне исегезгә төшерегез. Ир белән хатын башта эчәләр, аннары хатын, нәрсәгәдер ачуы чыгып, иренә отвертка белән кадый. Тагын бер җан тетрәткеч мисал: алты бала анасы шушы араларда гына дүрт елга ирегеннән мәхрүм ителде. Элек бу гаилә «куркыныч яный» торган төркемдә буларак исәптә торган. Аннары исәптән алынган. Чөнки әни кеше төрмәдән башы чыкмаган ире югында үзен яхшы тота. Балигъ булмаган яшүсмерләр белән эшләү комиссиясе хезмәткәрләре әйтүенчә, өйдә балалар өчен яшәү шартлары бар. Сабыйлар әниләре өчен җан атып, яратып тора. Бу юлы да бөтен эшне төрмәдән «на побывку» кайткан ир боза. Хатынын эчәргә кыстый, икәүләшеп эчәләр дә тавыш чыга. Шунда хатын иренә пычак белән чәнчи.

Мамадыш районы прокуратурасы әле бу арада гына 55 яшьлек иргә карата РФ Җинаять Кодексының 117 нче маддәсе буенча җинаять эше кузгатты. Ике арада килеп чыккан аңлашылмаучылыкны ир гадәти булмаган юл белән ачыкларга алына. Ул 51 яшьлек хатынының аяк-кулларын бәйли, авызына скотч ябыштыра да дүрт сәгать буена бертуктаусыз кыйный. Исерек иргә өч ел ирегеннән мәхрүм ителү яный.

Хатынына үч итеп

Моның ише башка сыймый, йөрәк кабул итә алмый торган күңел тетрәткеч хәлләр безне

әледән-әле эссе табага бастырып тора. Бу хәлләргә инде сигез ел вакыт үтеп китсә дә, ерткычлыгы белән тиңе булмаган ул җинаять берәүне дә битараф калдыра алмас. 37 яшьлек Александр Григорьев 5 яшьлек улы Алексейны пычак белән суеп үтерә. Фаҗигагә берничә минут кала, ул өенә кайта. Улыннан әнисенең кайдалыгы белән кызыксына. Сабый, ничек бар шулай әйтеп бирә: «Әни янына бер абый килде», – ди ул. Ата кеше, хатынына үч итәм дип, кулына пычак ала да дүрт мәртәбә баласының эченә кадый. Бала шундук җан бирә.

Ни өчен бу хакта сөйлибезме? Кисәтәсебез килә: гаиләдә тавыш чыкмыйча тормый. Ул юктан гына да давыл булып күтәрелергә мөмкин. Низагны кузгала башлауга ук туктату, күп вакыт хатын-кызның үзеннән тора. Хатын-кыз зирәгрәк, хатын-кыз хәйләкәррәк. Аннары бәхетсезлеккә илтүче юлның башы өстәлегездә утырган аракы булуын онытмагыз! Гаиләдәге сугыш чукмарларына карата хокук саклау органнары аеруча җитди, кырыс чаралар кулланырга да риза. Чөнки бәланең килеп чыгуы шулар аркасында. Алар – Эчке эшләр бүлекләрендә исәптә тора. Хезмәткәрләр аларны азга гына да күз уңыннан ычкындырмаска тырыша. Сугыш чукмарлары белән яшәгән хатыннарның да көннәрдән бер көнне сабырлыгы бетә, һәм алар соңгы адымга бара: кулларына пычак алып, аянычлы гамәл кыла. Эчкән хәлдәме ул, көнкүреш низаглары нигезендәме... Ә бит җинаятьләрне кисәтергә, булдырмый калырга да була иде. Моның өчен бары гаиләдәге җәбер-золым, эчкечелек аркасында килеп чыккан тавышлар турында вакытында полициягә хәбәр итәргә генә кирәк. Закон буенча хокук тәртибен бозучыларга карата бик күп үтемле чаралар каралган, бер уйласаң.



ГАИЛӘ БӘХЕТЕ МӘКТӘБЕ

Дөресен әйткәндә, баштарак без аны ялгызларга бер-берсен табышырга, кавышырга ярдәм итү мәктәбе дип уйлаган идек. Алай булып чыкмады. Аның мәгънәсе тирәндәрәк икән. Казан шәһәрендә урнашкан «Ышаныч» үзәгенең «Ювента» психологик-педагогик ярдәм бүлеге җитәкчесе, психолог Марина ЯЦЕНКО болай дип аңлата:

– «Гаилә бәхете мәктәбе» дип ул тикмәгә генә аталмый. Безнең өчен гаилә кыйммәтләрен саклаудан да зур бурыч юк. Саклыйсың икән, син инде бәхетле. Бу мәктәпкә йөрүчеләр беренче көннәрендә, чыннан да, үзләренә тиң ярын табарга дип килә. Килә, күрә, мәсьәләгә төшенә дә, психологлар тәкъдим иткән чаралар белән килешә. Аларның һәркайсы белән зур, җитди аңлату эшләре алып барыла. Алар дәресләргә йөри-йөри гаиләнең ни икәнлегенә төшенә, ничек итеп үзара аралашырга, партнерының ихтыяҗларын хөрмәт итәргә, аңларга өйрәнә. Бер-береңне ишетү һәм тыңлау осталыгын чарлый. Бу мәктәпкә йөрүчеләр бергәләшеп культпоходлар оештыралар, кино-театрларга баралар. Бер-берсе белән аралашырга өйрәнәләр. Безнең бурыч – аларны өйләнештерү түгел. Тик шулай да, кайчак анысы да булып куя. Без аларны елмаерга өйрәтәбез.

Бервакыт бер ир кеше килгән. «Миңа бер хатын-кыз кирәк», – ди. Мин гаҗәпләнә калдым. «Нәрсәгә кирәк ул сиңа?» – дим. Аңлыйм үзем, теләге изгеләрдән. Ләкин аның хатыны буласы кеше белән аралашырга, аны яхшырак, якыннанрак белергә вакыты юк. Ул акча эшли. «Көн-төн эштә мин, йөрергә вакытым юк», – дип кырт кисә. Бик озак сөйләшкәннән соң гына хаклыгыбызны аңлады. Чыннан да, бер белмәгән кеше белән ничек яшисең аннары?!

Хәер, ирләр генә түгел, хатын-кызлар да шундый җилбәзәк бу мәсьәләдә. Алар да: «Башта очрашырга кирәк. Аннан карарбыз», – диләр. Башта әзерләнергә кирәк, дим. Син ул танышың белән ни хакта сөйләшерсең? Дөнья хәлләре турындамы? Очрашкач уртак сөйләшер сүзең булмаса, соң була. Кабат күрешәсең дә килми аннары. Безгә аерылган кешеләр дә мөрәҗәгать итә. Сораштыра башлыйсың да, аның үзенә янә элеккеге хатынына яисә иренә охшаган ярны эзләвен аңлыйсың.

Безнең психологлар загсларда да еш булалар. Кайчак язылышу минутларын көтеп утырган парларга карыйм да, сискәнеп куям: аларның 80 проценты диярлек «шулай кирәк» булганга, мәҗбүри өйләнә, кияүгә чыга. Чөнки тиздән туачак баланы ятим итәргә ярамый.

Безнең бүлек Казан шәһәренең Маршал Чуйков урамында, 79 нчы «А» йортында урнашкан. Телефоныбыз: (843) 522-55-81. Гаилә бәхетенең ни икәнен беләсегез килсә, безгә килегез!

Былтыр республикада 3326 шундый җинаять теркәлгән. Шуларның аеруча авыр дип аталганнары — 383. Быелның гыйнвар, февраль айларында гына да аларның саны 495 кә җиткән. Күп вакыт моңа ир белән хатынның кара-каршы утырып эчүе, аннан аның үтереш белән тәмамлануы сәбәпче була.

PRESSA.RU

АЧЫ ДАРУ

Дару баллы булмый, диярсез. Язмыш учларыңа салганнары – башка, аларда – әрем ачылары. Әмма йотмый чараң юк...

Ходай кешегә үзе күтәрә алганнан да зуррак сынау бирми, диләр. Алайса нигә сынаулар бирәүләрне сындыра, юкка чыгара, тезләндерә, ә икенчеләргә көч өсти, турайтып бастыра, ныгыта? Алай гына да түгел, тормыш куйган бу киртәләр аша узганда алар бөтенләй башка кешегә әйләнәләр, үзләрен табалар. Бүгенге әңгәмәдәшем – шундыйлардан.

Ялгыш та: «Әгәр дә...» – дип әйтми ул. Әгәр аерылмаган булсак, балам сау-сәламәт туса, әгәр фән юлыннан киткән булсам... Мондый икеләнүләр инде күптән артта калган. Шул ук вакытта: «Мин язмышны җиңдем», – диюен дә ишетмәдем. Язмыш белән көрәшми, яши генә... Әмма үзен дә, бәхетсезлеген дә җиңә алган Наилә ВӘЛИЕВА (ШАКИРОВА) – бүген тормышка якты елмаеп карый торган интерьер һәм ландшафт дизайнеры булып яңарган һәм үзенә яңа юл салган...

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



– Хәзер артка борылып карагач, әлбәттә, аңлыйм: әйе, бу мин үтәргә тиеш юл булган. Ул чакта берәрсе «Бу сынаулар сиңа – ачы дару урынына. Син хәзер дәваланасың, түз, аннары якты көннәр киләчәк», – дисә, аларны кичерү күпкә җиңелрәк булыр иде дә. Тик кем әйтсен?! Киләчәкне кайсыбыз белә?

ДЦП! Минем алма бөртеге кебек кечкенә кызымда балалар церебраль параличы! Аяз көнне яшен сугу шулай буладыр ул... Берсенең дә җавабы булмаган сорауларга күмелеп каласың: нигә, ни өчен нәкъ менә минем белән?! Үзеңне жәллисең, баланы кызганасың... Камилә туганда миңа 20 яшь кенә иде әле. Казан дәүләт университетында, биология факультетында укыган чагым. Ул көннәрне искә төшерсәм, бүген дә яшемә тыгылам... Диагноз тәгаенләнгәч, баламның әтисе юкка чыкты. Аңа үпкәләмим. Начар кеше түгел иде ирем, әмма бу авыр йөкне ул күтәрергә тиеш булмагандыр, күрәсең. Кайбер нәрсәләрне акылым аңлап та, йөрәгем кабул итмәгәндә, үземә юаныч таптым: кечкенә чакта әби өйрәткән догаларны кабатлый башладым. Мәгънәләрен белмим, әмма булыша!

Карма турындагы китапларга күмелдем: аның берсе миңа бу хәсрәтнең ни өчен килүен аңларга ярдәм итте, икенчесе – барысы да Аллаһы Тәгалә кулында икәнен төшендерде... Шул мизгелдән тормышым үзгәрде.

Беренче тапкыр дәваланырга неврология шифаханәсенә яттык. Палатадагы күршемнең дүрт яшьлек улы үрмәли башлаган көн иде ул. Алардагы бәйрәм! Инде өметләнмәгән дә булганнар... Ул хатынның өч баласы бар иде. Кызлары инде зурлар, малай кирәк дип, өченчегә тәвәккәлләгәннәр. Ире әзәрбайҗан булган аның, уллары тууга Карабах вакыйгалары башланган, һәм ул иленә кайтып киткән. Шуннан бирле хәбәре юк: кайда ул, исәнме, түгелме – хатыны белми. (Хәле синекеннән авырраклар гел бар, дип әйттем бит.) Без палатага кергәндә ул нидер эзли иде. «Муенсамны югалттым», – диде. Аны мин табып бирдем. Куанды! Баксаң, ул очрашуга барырга җыена икән. Университет профессоры белән танышкан. Чәчен ясады, иреннәрен буяды да, йөгереп түгел, очып китте очрашуга. Алай яшь тә түгел, кырыкларны узган иде инде ул. Ә мин шифаханә ишеген ачып кергәндә, монда тормыш туктаган дип уйлаган идем... Әлеге хатынның юлымда очравы тормышымны шактый үзгәртте. ДЦПлы бала булган әниләр күбрәк ялгыз кала, диләр. Авыру бала аркасында түгел ул. Проблемаларга чумып, үз-үзеңә бикләнсәң, сиңа кем игътибар итсен?! Йөзең балкып, күзләрең янып тору бөтенләй башка бит ул!

Бишенче курсны группадашлар белән бергә тәмамладым. Алар кайсы кая эшкә урнашты, ә мин... Безнең тормыш бер эздән акты да акты: өч ай – өйдә, бер ай – шифаханәдә. Еллар буе шулай! Бер ноктага тамып тамчы ташны тишә, диләр, дөрес ул: без дә максатыбызга ирештек! Камиләгә куелган диагнозны шундый балалары булган әниләр һәм табиб-неврологлар гына күрә. Менә ул могҗиза! Без аны үзебез ясадык!

Беренче сыйныфка Камилә яшьтәшләре белән бергә керде. Әмма ул елны «читтән торып укыды». Класс җитәкчебез шулай дия иде. Укырга йөргән көннәреннән авырган көннәре күбрәк булды шул. Балалар бакчасы аша узмагач соң... Кая ул эшкә урнашу турында уйлау?! Бу вакытта мин кабат кияүгә чыккан идем инде. Ирем миңа бик нык булышты. Ул олы йөрәкле кеше булып чыкты. Кызым аны үз әтисе дип санады.

Камилә башлангыч мәктәпне «бишле» билгеләренә генә тәмамлады. Урта мәктәпкә исә зур юл аша узып йөрдек: кулыннан җитәкләп озатам, каршы алам. Музыка мәктәбендә дә укыйбыз, түгәрәкләргә йөрибез. Университет каршындагы лицейга керергә әзерләнәбез... Шул вакыт мин белмичә дә бер ялгыш ясадым: иремә игътибарымны киметкәнмен. Моның ни белән тәмамланганын чамалыйсыз инде.

Кеше эчтән үзгәрсә, аның тирәюне дә үзгәрми калмый икән.

Дус кызымның туган көне җиткәндә Камилә белән санаторийда идем. «Килмәсәң – үпкәлим!» – дип шалтыратты. Икенче бер ахирәтем кызым янына килеп торырга ризалашты. Иремә хәбәр дә итеп тормадым – каршы алып мәшәкатьләнмәсен, дидем. Бүләкне алдан әзерләгән идем, өйгә сугылып, шуны гына алып чыгам да, янәсе. Ишекне ачып керсәм – алар икәү... Тагын күңелдә шул сораулар, тагын «ни өчен»нәр!.. Онытып, алга таба яшәп китү турында сүз дә була алмый иде. Чөнки: «Гафу ит...» – дип үтенгән, үкенгән кешене генә кичерергә була, ә ул, күземә карап: «Фаҗига ясама, әллә нәрсә булмады лабаса!» – дип тора. Көн саен килә дә: «Мин сине яратам! Син минем гаиләм! Тик тормышымда ул да бар», – ди... Тәмам буталдым, берни аңламыйм! Психологка бардым. «Тиздән ирең икегезнең берсен сайларга тиеш булачак, ә ул моны эшли алмаячак һәм сине гаепләячәк», – диде. Аерылыштык... Ул кыз турында сөйли башласа, иремнең йөзе үзгәрә, балкый башлый. Шулай булгач, аны үз янымда тотудан ни мәгънә?! Ул бит аның белән шундый бәхетле! Ә бәхеткә лаек кеше иде ул... Әмма алар хәзер бергә түгел...

Миңа бу вакытта утыз биш яшь. Ирем юк, эшем юк... Фатир алган гына идек, аңа ремонт ясалмаган... Аннан ирецне югалтканда, үзеннән-үзе дусларның да яртысы югала икән: алар бу хәлләрне күптән белгән, әмма әйтмәгәннәр. Күрәсең, жәлләгәннәр... Бер тапкыр да җаны авыртып карамаганнарга аның әрнүен ни белән чагыштырып аңлатыйм икән? Суларга телисең, тик сулап булмый. Хәтта тын да ала алмыйсың! Ашау-эчү турында сүз дә юк! Әмма шул килеш тә яшәргә, суларга кирәк... Иң-иң авыр чакларда тагын әбинең догалары ярдәмгә килде. Бөтенләй сулый алмый башласам, шул догаларны кабатлыйм һәм миңа җиңелрәк булып китә. Әмма җан сызлавын баса торган дару юк!

Сиңа бит иң беренче чиратта аралашу, күңелне бушату кирәк. Дуслар тыңлый, билгеле. Бер тапкыр,

Фото: Евгений Канаев

PRESSA.RU



Язылмаган кагыйдәләр:

- Сиңа ярдәм кулы сузарлык кешеләр һәрвакыт табыла. Иң мөһиме – тартынуны җиңеп, ярдәм сорый белү.
- Әгәр сиңа бик-бик начар икән, үзеңнән дә авыррак хәлдәге берәүне табып, аңа ярдәм итәргә кирәк. Шул чакта да җанга җиңеллек килә.

ике... Аннан – арыйлар, ә син башка нәрсә сөйли белмисең! Авырткан җирдән кул китми... Кемдер миңа йога белән шөгыльләнеп карарга киңәш итте. Беренче дәрестән соң ук мин үземнең проблемам турында бер сәгать (!) уйламыйча тора алуымны аңладым. «Нигә, ни өчен»нәрсез бер сәгать! Аннан бер атна тоташ сулый ала башладым. Шундый ябыктым ул чакта – коточкыч!

Безнең белән нинди генә яңалык булса да, ул иң элек күңелебездә, уебызда өлгерергә тиеш бугай.

Аннан, ниһаять, эшкә урнаштым. Интерьер дизайнеры булып. Сәнгать мәктәбендә укуым менә кайчан кирәк булды... Әле ирем белән торганда Казан төзелеш институтында дизайнерлар курсын тәмамларга өлгергән идем – ярый әле, аның укучылары өчен (ул каратэ остазы иде) кимоно тегеп, тар диварымда миләүшәләр үстерү белән генә чикләнеп калмаганмын (тормыш мине, үземә дә сиздермичә, әзерләгән!). Өйрәнчек булып кына йөрергә вакытым юк – мин шунда ук акча эшли башларга тиеш идем. Кулымда бала – аны ашатасы, киендерәсе, укытасы бар... Фатирга ремонт ясап керәсе... Әйе, бөтенләй белмәгән эшкә тотындым дип әйтә алмыйм. Чирканчык алганым бар иде инде. Бер дус кызымның кинәт кенә ире үлеп китте. Шушы хәл булыр алдыннан гына икенче балалары туган һәм алар яңа зур фатир алганнар иде. Бик аз акча белән ул шушы фатирга ремонт ясап керергә тиеш иде. «Булыш!» – диде. Аларның нинди фатирда яшәячәген ул чакта мин хәл иттем: һәр бүлмәгә обойларны үзем сайладым, тәрәзә пәрдәләрен мин сатып алдым... Иремнән аерылгач, безне шушы дус кызым үзенә сыендырды. Эш мине коткарды! Авыр уйлардан бары тик эшкә күмелеп кенә котылып тора идем. Иртәнге алтыда чыгып китәм, төн уртасында кайтып авам – эштән соң үз фатирымда да нидер эшләргә өлгерергә кирәк бит. Иң авыры ул чакта Камиләгә булгандыр: моңарчы кулда гына «күтәреп» йөрткән бала бит! Әкренләп барысы да җайлаша башлады: кызым лицейга укырга керде, дуслары күбәйде. Үз фатирыбызга күчендек – анысы бер бәхет булды.

Беркөн шул дус кызым: «Сине группадаш егет белән таныштырырга телим», – ди. Мин дәшмәдем. Берничә көннән шалтырата: «Марат ярты сәгатьтән сине опера театры янында көтә», – ди. «Юк!» дип әйтергә дә өлгермәдем. Кояшлы матур язгы көн. Беренче көн урамга туфли киеп чыккан идем. Бер очрашканнан ни була, дип, киттем. Килсәм? Марат юк. (Ул гел соңга кала.) Ә мин соңга калучыларны яратмыйм. Тик ул көнне ничектер сабыр идем. Спектакль башлануга 10 минут кала килде дә, мине җитәкләп театрга алып кереп китте! Шулай тиеш кебек иярдем. Соңыннан кафеда чәй эчтек, озак сөйләштек. Әллә никадәр уртак танышларыбыз барлыгы ачыкланды. Юллар гел янәшә барган, нигәдер кисешмәгән генә. Язмышларыбыз да охшаган. Ике айдан бергә булырга хәл иттек... Кызыбыз Зөһрә барыбызга да бәхет алып килде. Әмма үткәннәрем булмаса, бүгенгемнең кадерен белмәс идем. «Нәрсә инде, ир, бала, эш... Бөтен кешенеке кебек», – дияр идем. Ә хәзер барысын язмыш бүләге итеп кабул итәм.

Тормышның башка чоры башланды. Мин моңарчы төрле фирмаларда эшләдем – үз исемем турында уйламадым. Кырык биш тулгач кына, ниһаять, тәвәккәлләдем. Ландшафт дизайны буенча курслар тәмамлап киләм менә. Читтән караганда гади генә кебек: киләсең дә хуҗадан сорыйсың: «Йә, бакчаңда нәрсә утыртыйк – алмагачмы, чияме, әллә карлыганмы?» – дип. Мин башта заказ бирүчем белән утырып сөйләшәм: ничек яши ул, нияләр белән кызыксына, нәрсә хакында хыяллана... Әңгәмә вакытында күңелемдә ул кешене йә бер җыр, йә фильм белән чагыштыру башлана. Инде шул җыр белән бәйле күренешләр күз алдына тезелә. Әгәр күңелен дөрес «укыган» булсаң, кәгазьгә төшергән бакча рәсеме аның рухи дөньясы белән тәңгәл килә. Утыртасы агачлар да, син сайлаган чәчәк сортлары да. Интерьер дизайны белән дә шулай. Фатир яки йорт хуҗаларының нindiлеген аңласаң, үз сүзеңдә катырак торырга кирәк: чәчәкле обой кирәк, дип, ул кемдәдер күреп кенә әйтергә мөмкин. Соңыннан барыбер: «Нигә мине ныграк үгетләмәдегез?» – диячәк. Йортның интерьерын эшләгәндә ким дигәндә биш елга алга карап планлаштырырга кирәк: ул чакта биредә кемнәр, ничек яшәячәк... Ошый миңа эшем! Бу бүлмәләрдә миннән соң бәхетле кешеләр яшәячәк дип уйлыйм.


Наилә Вәлиеваның (Шакирова) киңәшләре белән сайтыбызда таныша аласыз.

ЯРДӘМ

«Бизнес хатын-кызлары» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы катлаулы икътисадый ситуациягә юлыккан эшмәкәр хатын-кызларга юридик киңәшләр белән бушлай ярдәм итү максатыннан федераль кайнар элемтә ачты. Үзәккә кече һәм урта хатын-кыз эшмәкәрлеге субъектлары хокук һәм финанс мәсьәләләренә караган сораулар, шулай ук дәүләт ярдәме һәм субсидияләр буенча белешмәләр белән мөрәҗәгать итә ала. Кайнар элемтә: 8 800 250 73 53 (чәршәмбе, җомга).

ҖӘМГЫЯТЬ



■ Җиңү бәйрәме көнендә узган «Үлемсез полк» Бөтенроссия акциясендә 107 мең татарстанлы катнашты. Әлеге маршка Казанда 45 мең кеше кушылды. Бөек Ватан сугышында катнашкан туганнарының портретларын күтәреп, алар урамнардан уздылар. «Үлемсез полк» башында Татарстан җитәкчеләре барды. Ирек мәйданында башланган тантана 1 Май мәйданында шигъри митинг булып дәвам итте һәм Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу белән тәмамланды.

■ ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов «Игелек. Мәхәббәт. Кайгыртучанлык» ордены белән бүләкләнде. Ул, үз чиратында, РФ Президентының Бала хокуклары буенча вәкиле Павел Астаховка ТР Президенты Указы белән нәтиҗәле хезмәттәшлек һәм бала хокукын яклау эшенә керткән зур өлеше өчен «Дуслык» ордены тапшырды. Бүләкләр «Созвездие-Йолдызлык» XVI республика фестиваленең гала-концерты кысаларында тапшырылды.

ТУКАЙ ЮБИЛЕЕ

■ Казанда бөек шагыйрь Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган бәйрәм чаралары узды. Аларда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Дәүләт Советы һәм Хөкүмәте әгъзалары, министрлык һәм ведомство вәкилләре, иҗат әһелләре һәм IY Халыкара хатын-кызлар форумы делегатлары катнашты. М. Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театрында узган тантанада Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде: рәссам Нәҗип Нәккаш; шагыйрь Газинур Морат; «Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкларга сузылган юл» экспозицион инсталляция авторлары төркеме.

■ Казанның Островский урамындагы 10 нчы йорт (элеккеге «Шәрык» клубы, хәзер Казан дәүләт Яшь тамашачылар театры) диварына Габдулла Тукай истәлегенә элмә такта куелды. 1908 елның 14 октябрендә әлеге тарихи бинада Г. Тукай беренче тапкыр «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын укыган.

■ Казанда узган «Габдулла Тукай һәм төрки дөнья» дигән халыкара фәнни-гамәли конференциягә төрки дөнья галимнәре, чит ил белгечләре җыелды. Әлеге чарада тарих фәннәре докторы, Американың Висконсин университеты профессоры Юлай Шамил углы, тарих фәннәре докторы, Иранның «Праги» журналы баш редакторы Сарлы Араз Мәхмәт, Алтайдан килгән филология фәннәре кандидаты Альбина Киддикова, Уральскида Тукай үзеген җитәкләүче Нурия Хәбибуллина һәм башкалар Тукай татарныкы гына түгел, ә барлык төрки халыкларның да байлыгы ул дигән фикерне куәтләделәр.

КОТЛЫЙБЫЗ

■ «Татарстанның ел тәрбиячесе» финалында 40 педагог үзен һәрьяклап күрсәтү өчен тырышты. Казанның Яңа Савин районындагы 380 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Гүзәл Мөхәммәтҗанова беренче урынны яулады. Ул «Россия ел тәрбиячесе» конкурсында катнашачак.



МӘДӘНИЯТ



■ Мәскәүдә «Алтын битлек»-2016 Россия милли театраль премияләрен тапшыру тантанасы узды. Тантанада «Алтын битлек» Г. Камал театрыннан Россиянең һәм Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдиновка «Театр сәнгате үсешенә зур өлеш керткәне өчен» бирелде.

СПОРТ

■ Казанда дзюдо буенча Европа чемпионаты булып узды. Ул 46 илдән 400 ләп спортчыны җыйган 2016 елгы Олимпия уеннарына әзерлек этабы да булып торды. Ачылыш тантанасы миллилеге, Татарстанның кунакчыллыгын күрсәтә алуы белән җәлеп итте. Россия Президенты Владимир Путин да әлеге спорт бәйрәмен ачу тантанасына махсус килде.



PRESSA.RU



НИЧЕК КЕНӘ ЕРАК ТОЕЛМАСЫН, БЕРЗАМАН БУ КӨН ДӘ КИЛЕП ҖИТӘ...

Балаларның үсеп җитеп, һөнәр сайлау алдында торган көнне әйтәм. Баланы 7 яшьтән 10 яшькә кадәр төрле һөнәрләр белән таныштыру мөһим икән. Бу яшьтә алар әле бик кызыксынучан була.

Фото: Сөмбел Гаффарова

Дөресен генә әйткәндә, яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү – ул дәүләт сәясәте дә булырга тиеш. Җәмгыять өчен үтә дә мөһим булган һөнәрләрне матур, мавыктыргыч итеп, кызыклы якларын ачып күрсәтү дәүләтнең бурычы. Бу җәһәттән бераз җанлану сизелә хәзер. Апрель аенда Казанда узган «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia 2016) чемпионаты – шуңа бер дәлил. Казан 2019 елда һөнәри осталык буенча WorldSkills Competition Дөнья чемпионатын кабул итәргә әзерләнә. WorldSkills – бөтен дөньяда эшче һөнәрләрнең дәрәҗәсен күтәрү һәм һөнәри осталыкны чарлау максатыннан 1953 елда башланып киткән халыкара хәрәкәт. Төп эш алымы – эшче һөнәр ияләре арасында дөнья буйлап төрле дәрәҗәдәге ярышлар уздыру. Россия бу хәрәкәткә 2012 елда кушылды һәм илебездәге беренче чемпионат 2013 елда Тольятти шәһәрендә узды. Бүген WorldSkills хәрәкәте 72 илне колачлый.

Мәктәп укучыларына яшьли һөнәри юнәлеш бирү һәм һөнәр нигезләренә өйрәтү максатыннан 2014 елдан Россиядә JuniorSkills программасы да эшли. Бу программада 10 яшьтән алып 17 яшькәчә яшүсмерләр катнаша. Аларга үзләрен кызыктырган һөнәрләрне үз куллары белән башкарып карау, күңелләренә ошаган эшне ачыклау мөмкинлеге бирелә.

Чын профессионаллардан эшнең нечкәлекләренә өйрәнгән укучылар мәктәпне тәмамлаганда ук һөнәрле булып чыга.



Лилия ГӘРӘЕВА

УҢГА КИТСӘҢ – УҢАСЫҢ, Ә СУЛГА КИТСӘҢ?..

Улым тугызынчыны тәмамлый быел. Әле тагын ике елы бар дип йөри идек: «Мин унга-унбергә бармыйм! Безнең класстан барысы да китә», – ди. Укыйм дип артык атлыгып тормаган кешене, бәлки, чынлап та кыстамаскадыр. Ике ел буе репетиторларга түләгән акчага (имтиханнарны яхшы тапшырыйм дисәң, ансыз да булмый) берәр һөнәр алуы, бәлки, дөресрәк тәдер. Аннары, тели икән, укуны дәвам итәр. Техникум яки училищелар югары уку йортына керү юлын япмый лабаса. Әмма... нинди һөнәр сайларга дигәч, көймәсе комга терәлде улымның. Дөреслек хакына әйтергә кирәк: үзенә ошаган һөнәре бар иде аның: артист буласы килә иде. Берара автослесарь буласым килә дип тә йөрде. Этмәчеләрне бик ярата – бәлки, шәп кенә ветеринар да була алыр иде. Аптыраган: кайсы юлны сайласак, адашмабыз? Монда инде сайласак, дим, чөнки бу четерекле эштә әти-әни киңәшеннән башка гына булмастыр.

«Доверие» балалар һәм яшүсмерләргә социаль хезмәт күрсәтү үзәге каршында эшләп килүче «Сердәш» психологик-педагогик ярдәм бүлегенең педагог-психологы Лилия САФИНА белән дә сүзебез әнә шул хакта.

– Булачак һөнәр турында мәктәпне тәмамлаганда гына уйлана башлау дөрес түгел, – ди ул. – Балаларның киләчәккә хыяллары 10 яшькә кадәр формалаша, шул чорда ул үзенә образ тудыра. Казанда «Һөнәрләр шәһәре» («Город профессий») дигән җир бар. Алып барыгыз сез анда балагызны һәм күзәтегез: кайда озаграк тукталыр ул. Кешенең һөнәр юлы еш кына менә шуннан башлана да инде. Бала кызыксынган һөнәрләр турында икәүләп мәгълүмат туплагыз. Аларның кызыклы һәм авыр якларын белешегез. Элегрәк әти-әни эшләгән җиргә экскурсияләргә бару гадәте бар иде. Бала шунда нинди һөнәр иясенең тәгаен нинди эш башкарганын, нинди шартларда эшләгәнен күрә иде. Бу аңа бер тәҗрибә була иде. Сыйныф сәгатьләренә әти-әниләрне чакырып, алардан үзләренең һөнәрләре турында сөйләтү дә әһәмиятле. Бу да балаларга төрле һөнәрләр турында күзаллау бирә. Бер дә тәҗрибәсе булмаган бала кайсы һөнәрне яратуын кайдан белсен инде. Төрле мастер-класслар бар, уку йортларында ачык ишекләр көне үтә – кызыксыныгыз.

Без укыган чорда УПК – укыту-производство комбинатлары бар иде. Балаларны хезмәткә өйрәтү һәм һөнәрләр белән таныштыру максатыннан кертелгән өстәмә дәресләр рәвешендә оештырылган иде алар. Һәр мәктәп кайсы да булса берәр оешмага беркетелеп, шунда һөнәргә өйрәнә иде. Без менә хастаханәгә йөрдек. Атнага бер-ике сәгать идән юу, авыруларга булышу кебек эшләр иде инде ул. Мин үзем дә табиб булырга хыялландым. Ләкин нәкъ менә УПК аркасында ул һөнәрнең минеке түгеллеген аңладым. Табиб булу ул әле халат итәген җилфердәтеп йөрү генә түгел икән...

Дөрестән дә, без һөнәрләр турында аз беләбез. Өстәвенә, һөнәр базары үзе дә бик тиз үзгәрә, хезмәт шартлары, таләпләр алмашына. Һөнәр сайлаганда аның уңай якларын, ул эш өчен күпме түләнүен, эш табып булу-булмауны гына түгел, шушы һөнәрнең тискәре якларын да барларга кирәк. Ә иң яхшысы – һөнәр ияләренең үзләре белән сөйләшү. Нәрсә җәлеп иткән аны, кайсы ягы ошый, әллә ошамый торган яклары да бармы? Бу һөнәр кешедән нинди «корбаннар» сорый? Аннары интернетта күп кенә һөнәрләр турында аңлатма – профессиограммалар бар. Аларны укысагыз да шактый яңалык ачарсыз.

Нинди юнәлештә белем алырга белми аптыраган кеше күп очракта әле үз-үзен ачмаган була. Яки инде гаиләдә каршылык бар: әти-әнисе бер якка каера, ә бала башка якка. Яшерен-батырын түгел, күп кенә әти-әниләр үзләренең чынга ашмаган хыялын балаларында ашырырга омтыла. Гомерем буе табиб булырга кызыктым, ичмасам, син шул һөнәрне сайла, янәсе. Әнисе кайчан-



Россия Федерациясенең атказанган,
Татарстан Республикасының халык артисты
Исламия МӘХМҮТОВА

Мин үскән гаиләдә бөтен кеше гармунда уйный, җырлый иде. Аларга кушылып мин дә җырлыйм, биим. «Артист булырсың!» – дип үсендерәләр. Гел шул сүзне ишетеп үскәнгәме, башка һөнәр хакында уйламадым да, артист булам, дидем. Мәктәпне тәмамлап, Казанга килсәм, театр училищесына кабул итү беткән. Иптәш кызым белән Кремль карап йөргәндә, күзем күчмә театр игъланына төште: артистлар җыялар. Туп-туры шунда киттем. Кердем: «Абый, мине театрга алыгыз әле?» – дим. «Син нишли беләсең соң?» – диләр. «Бөтен эшне эшли беләм», – дим. Күчмә театрның директоры Мөхәммәт Хәмзин, режиссер Равил Тумашев һәм парторг Фәридун Юнысовлар мине җырлатып, сөйләтеп карадылар да шул көнне үк эшкә дә кабул иттеләр. Онытмыйм әле: «Сеңлем, театрда эшләсәң, гаиләң булмый, кияүгә чыга алмыйсың, фатирың юк та юк, әниеңә шулай дип кайтып әйт!» – дип озатып калдылар. 1963 елның 17 июле иде ул. Сүзләре рас килмәде: өч елдан Хәлил Мәхмүтовка кияүгә чыктым, кызларыбыз Лилия белән Ләйсән туды. Акчасы да җитте, фатирын да алдык. Балалар гел безнең белән юлда булды, артист тормышының авырлыгын күреп-белеп үстеләр. Кызыбыз Лилия мәктәпне тәмамлагач, артистлыкка укыйм диде. Каршы төштек. Һәркем баласына җиңелрәк тормыш тели бит. Физиканы бик булдыра иде, университетның физматына укырга керде. Тешен кысып, дүртенче курска кадәр укыды да, аны ташлап, театр училищесына китте. Шулай бер: «Артист буласым килә, әти-әни каршы», – дип әнигә зарлана икән бу. Әни пыр туздырды: «Мин авыл хатыны була торып та ике кызымны да артист иттем (сеңлем Рузия Мотыйгуллина да артист). Сез икегез артист булып та, баланы теләгәненнән тыясыз». Кечесе Ләйсән инде бездән сорап та тормады. Сигезенчене тәмамлауга ук, театр училищесына урнашып кайтты. Яратып, рәхәтләнеп эшлиләр хәзер. Әле менә алтынчы сыйныфта укыган оныгым повар булам дип йөри. Пешерергә тотынсаң, хәзер йөгереп килеп җитә, ашарга пешерешергә бик ярата. Әлегә яшьрәк, үсә-үсә хыялы үзгәреп тә китәр, кем белә.

PRESSA.RU

дыр табиб буласы килгән өчен генә нигә ул бала табиб булырга тиеш? Әле тагын да яманрагы: «Син табиб булсаң, бөтенебезгә дә ничек рәхәт булыр иде!» – диләр. Бөтен кардәшлыру өчен җаваплы итмәгез инде сез аны – үз тормышы белән яшәсен.

Һөнәр сайлау кеше тормышының мөһим сәхифәсе булса да, ялгышулардан курыкмагыз.

Шушы уңайдан бер кыйсса диим микән, мәзәкме, сөйләп китим әле. Бәлки, сезнең дә ишеткәнегез бардыр аны: «Бер инженер көн саен урамда балаларга тамаша күрсәтүче клоун яныннан уза, үзе эченнән генә уйлый икән: «Әгәр дә әни сүзе белән йөрмәгән булсам, мин дә клоун булган булыр идем. Гомерем буе саннар белән чиләнеп утырмас идем». Инженерны күргән саен клоун да уфтана: «Әни мине мәҗбүри укыткан булса, мин хәзер монда шамакайланып тормас идем». Алай да әни гаепле, болай да...

Бу очракта әти-әнинең иң зур ярдәме – ирек бирү. Баласының нинди һөнәр сайлавы үзләреннән тора дип уйлап, әти-әниләр ялгыша. Әйдәгез, һәрнәрсәне үз исеме белән атыйк: әти-әни баласының кем булып эшләячәген түгел, ә мәктәптән соң алга таба аңа нинди белем бирүне генә хәл итә. Баланың көченә, гаиләнең керемено карап, гаилә белән бергәләп кабул ителә ул карар. Ә инде киләчәктә балагыз ул һөнәр буенча эшлиме, үзенә башка юл ачамы, анысын ул инде үзе сайлый. Әгәр дә гаиләдә хәл үтә дә четерекле булмаса, кая барырга белми аптыраган балага бераз вакыт бирергә кирәк. Тугызынчыда гына укый икән, унга-унбергә барсын. Ир балалар нәкъ менә югары сыйныфларда көчлерәк укый башлый. Яки инде көче җиткән берәр техникумга, училищега керсен. Бернәрсә дә югалтмый бит ул аннан. Әгәр дә ошап китә икән, соңрак югары белем алыр. Ниндидер бер юнәлеш буенча белем алып, без үзебезне шушы һөнәргә бәйләп куябыз дигән сүз түгел бит әле. Хәзерге заманда уку дигәндә һөнәргә өйрәнү түгел, ә билгеле бер юнәлештә белем алу күздә тотыла. Сүз дә юк, белем тирәнрәк булган саен, кешенең уңышка ирешү мөмкинлеге зуррак.

Профессия ул – яшәешнең бер чагылышы. Танылган психолог, академик Евгений Климов һөнәрләрне биш төргә: табигать, техника, кеше, билгеләр, сәнгать белән бәйле һөнәрләргә бүлеп карый. Кызыксынсагыз, Евгений Климовның бу мәшһүр классификациясен интернеттан таба аласыз. Мәскәү өлкәсенең «Яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү үзәге» белгечләре төзегән «Һөнәр сайлау матрицасы» белән дә танышырга киңәш итәм. Интернетта кешенең шәхси мөмкинлекләренә нинди һөнәр туры килүен ачыкларга ярдәм итүче тестлар күп. Мәсәлән, «Голланд тесты». Ул да үз мөмкинлекләрегезне, теләкләрегезне тәртипкә салырга ярдәм итәр.

Ә инде баласы мәктәп бусагасын атлап чыгарга торган әти-әниләргә киңәш шул: «Синең бар да яхшы булачак, синең холык белән теләсә нинди хәлдән дә исән-имин чыгып була», – дип әйтүдән тайчынмагыз. Ышаныгыз, буш сүзләр түгел бу, бәлки, ышаныч уята торган сүзләр.

КИҢӘШ



«Әйбәт кенә укыган кызым тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, унга бармыйм, барменлыкка укыйм дип «котны алды». Күреп торам, бармен булу аның һөнәре түгел. Төгәл фәннәргә сәләте бар, физика-математиканы су урынына эчә. Мәктәпне ташлый икән, киләчәген җимерә бит... Әти-әнигә бу очракта нишләргә?»




Айсылу НӘГЫЙМОВА, психология фәннәре кандидаты, социология фәннәре докторы

Мондый очраклар еш була. Яшүсмерләр үз тормышларына үзләре хуҗа икәнлеген күрсәтергә ярата бит алар. «Юк, бернинди бармен булмыйсың!» – дип, кырт кына каршы төшәсез икән, кирелеген генә уятасыз. Аның белән җентекләп сөйләшергә кирәк. Иң яхшысы – баланы бу һөнәр белән ныклап таныштыру. Шул эшне бераз эшләп караса да ярый. Көне буена аяк өстендә, ябык бинада, еш кына тәмәке төтененә «балта сабы» эләрлек булган бүлмәдә эшләү ошармы аңа? Барменнар бит төнлә дә эшләргә тиеш. Кайдан туган анда мондый теләк? Мотивациясе нәрсә? Боларны ачыкларга һәм балага аңлатырга кирәк. Бергәләп шушы һөнәрнең нечкәлекләрен белешегез, чынлап та ул шушы эшне башкарырга телиме, көче, сәламәтлеге җитәме? Яшүсмерләр мондый гамәлне еш кына дусларына ияреп кылучан.

Күптән түгел генә студентлар арасында сораштыру үткәргән идек. Үзләре укыган һөнәр белән ныклап танышып, белеп сайлаучылар 2 проценттан артмый. Калган 98 процент һөнәрне әти-әни кушуы буенча, дусларына ияреп, шушы уку йорты якын булганга, монда укуы җиңел күренгәнгә... сайлаган. Һөнәрне киләчәктә акчаны күп эшләр өчен дип тә сайлаучылар бар. Һөнәр сайлаганда төп мотивация акча булырга тиеш түгел. Шушы һөнәр миңа үз бизнесымны ачар өчен кирәк ди икән, бизнес-план төзеп карасын. Акча өчен генә гомер буена күңел тартмаган эш белән шөгыльләнү җәзага тиң бит ул. Бала мәктәптә нинди фәннәрне җиңел үзләштерә – һөнәр сайлаганда шуңа да карыйсың. Минем үз балаларым физика-математикадан көчле булды. Аларның киләчәген шул юнәлештә күрәсем килсә дә, алар, әтиләренә карап, хокук өлкәсен сайлады. Үзләре теләгәч, каршы килмәдек.

ҮЗЕМ ҮСТЕРГӘН ҖИЛӘКНЕ САТАМ




«Автомобильдән саклан» дигән фильмда Анатолий Папановның мәшһүр каһарманы әйткән сүзләр канатлы булып китте – совет илендәге яшәү рәвеше үлемсез ул! Россия Федерациясендә яшәп ятучы һәр бишенче кеше 2016 елның «май бәйрәмнәрен» дачасында эшләп үткәрергә җыенган иде.



- 8,7% – табигатькә чыгам
- **20,4% – БАКЧАГА БАРАМ**
- 17,3% – эшлим
- 5,4% – чит илгә барам
- 6,3% – бүтән шәһәргә барам
- 8,3% – кунакка барам
- 33,6% – өй эшләре белән мәшгуль

БУ МИНЕМ БАКЧАМ!


СССР заманында һәм хәзер Россия Федерациясе халкы азык-төлекне ничегрәк хәстәрли (процентларда)



* Беренче дачалар Петр I заманында барлыкка килгән. «Дача» сүзе «бирү» сүзеннән килеп чыккан. Дачалар шәһәр кешеләренең ял итү урыны буларак Россиядә XIX гасыр азагында барлыкка килгән. Дөньяда андый нәрсә бүтән күзәтелми. СССРда шәһәр кешеләре бакча-дачаларда бәрәңге, яшелчә һәм җиләк-җимеш үстерә башлый. Дачалар бигрәк тә Хрущев җитәкчелек иткән дәвердә кулланылышка керә, чөнки чирәм җирләрне үзләштерә башлауга карамастан, азык-төлек белән кыен заманнар. Җир фәкать бакчачылык белән генә шөгыльләнер өчен бирелә. Брежнев заманында мәйданы 25 квадрат метрдан артмаган җәйге өйләр төзергә рөхсәт ителә башлый. 90 нчы елларда индивидуаль төзелешкә юл ачыла. Үз җирләрендә дачалар гына түгел, бәлки даими яшәрлек өйләр дә салына башлый. Хәзер инде дача-бакчаларны яшелчә үстерүдән бигрәк, шәһәрдән читтә ял итү өчен сатып алалар. Шулай булса да, бакчачыларның 81% ы үз җирләрендә гаиләсенә җитәрлек яшелчә-җимеш үстерә икән.



Россия Федерациясендә яшәүчеләрнең, 2012 ел белән чагыштырганда, 2015 елда төп азык-төлек продуктларын куллануындагы үзгәрешләр (процентларда)



Соңгы ике елда төрле илләрнең сәясәтмәннәре санкцияләр һәм антисанкцияләр белән мавыккан арада, Россия халкы азык-төлеккә бәяләрнең арта баруын искәрде. Шәһәрдә дә, авылда да өстәлдә витаминлы ризыклар кимеде. Авылларда исә бәрәңге генә мулдан булып чыкты. Калган азык-төлек ягыннан алар шәһәрдән калыша. Шәһәр кешеләренә дача-бакчаларга чынлап торып тотынырга вакыттыр, бәлки?!

PRESSA.RU



ОКОПТА ТАТАР ҖЫРЫ



Хәмидә ГАРИПОВА

Татар халык җырчысы Галия Кайбицкаяның әтисе Мотыйгулла хәзрәт Кече Кайбычта туып-үскән, Каһирәдә белем алган, «Мотыйгыя» мәдрәсәсен оештырып, анда мөдәррислек һәм мөгаллимлек иткән, ятим Апушны үз канаты астына сыйдырып, аңа тирән белем, күркәм тәрбия биреп, талантын ачып, татар халкының күренекле шагыйре Тукай дәрәҗәсенә күтәрелергә ярдәм иткән шәхес. Әтисенең туган җиренә хөрмәт йөзеннән, Галия апабыз Кайбицкая тәхәллүсен алган да инде.

Миңа Галия апа үзе исән чагында аның белән якыннан аралашырга туры килде. 1976 елда Кайбычка кунакка кайткан иде ул. Җитмеш яшь иде инде аңа. Әмма ул яшьләрчә җиңел-житез, нәфис, якты йөзле, нәзакәтле ханым иде әле. Кайбыч басуларында күкрәп үскән тук бодай башакларын сыйпап, арышлар арасында күкчәчәкләр белән сөйләшеп йөрүләре әле дә күз алдында. Галия апаның ихласлыгы, үз-үзен зурга куймавы күңелгә ятышлы иде. Аның Казандагы фатирының ишеге кайбычлар өчен һәрвакыт ачык, күңеле киң булды. Кайчандыр Салих Сәйдәштән калган җыйнак кына бүлмәсендә очрашып, чәй эчеп, гәп корып утырган вакытыбызда, мин аның сугыш вакытында госпитальләрдә чыгыш ясавы, хәтта фронтка барып, ай ярым дәвамында концертлар куеп йөрүе турында сөйләвен ишетеп, сөйләгәннәрен язып та алган идем. Бәхеткә, ул истәлекләр әлегәчә сакланган.

– Бөек Ватан сугышы вакытында, опера сәхнәсендәге чыгышлар һәм репетицияләр арасында буш вакыт табылуга, бер төркем артистлар белән Казан госпитальләрендә дәваланучы яралы солдатлар янына ашыга идек. Җырлап, биеп, нәфис сүз сөйләп, авыр хәлләрен аз булса җиңеләйтергә омтылдык. Шулар яныннан кайткач та, күземә йокы керми интегәм. Әле балалыктан чыгып бетмәгән сукыр, кулсыз, аяксыз, эчләре, башлары бәйләнгән гаскәриләрнең йончыган, сызланулардан газапланган йөзләре күз алдымда тора. Кызганудан, күземә яшь тыгыла. Үз энеләрем кебек якын иде алар миңа, чөнки ул чакта газиз туганнарым да сугышта кан коя иде. Бертуган абыем Әдһәм Мәскәүне фашистлардан саклаганда һәлак булды. Хәмидә апамның ике улы да фронтта. Берсе чит туфракта башын салды, икенчесе дә утлы өермә эчендә. Камил абыйның сугыштагы улы Рәфкатьтән хат-хәбәр юк. Берүк исән генә йөри күрсеннәр, дип Ходайга ялвара идем. – Бераздан Галия апа чәен яңарта. Чынаягындагы чәенең суынганын да сизмичә, фронт хатирәләренә чума, фотолар, хатлар белән таныштыра. Дулкынланудан күзләре дымлана. – Төньяк-Көнбатыш фронтта дошманнарны аяусыз кыручы Татар дивизиясенең оешуына 1943 елда 25 ел тулды. Республика җитәкчелеге бу дивизияне ТАССР халкы исеменнән фронтка барып котлау өчен сәнгатькәрләрдән бер иҗат төркеме туплады. Бу төркемгә мине дә керткәннәр икән. Бер көнчел «эшем иясе», опера җырчысына, җитмәсә, балалы хатынга фронтта ни калган? Синең урының театрда, тамашачыңны кемгә калдырып китәсең, дип, үзенчә «чеметкәләде». Ул чакта аңа җавап биреп тормадым бугай. Поездда фронтка китеп барганда, гасабиланып, үзалдыма сөйләнеп, теге кемсә үзе ишетмәсә дә, аның белән «бәхәсләшеп» бардым. «Утлы җәһәннәм эчендә, үз-үзләрен кызганмыйча, синең белән мине, безнең балаларны яклап кан түгүче сугышчылар өчен без – җырчылар – кирәгрәк тә әле! Моның шулай икәнлеген җылы өеңнең мичәнә арка сөяп утырып кына аңлап булмый ул. Шул мәхшәрдәге кешеләрне барып күрергә кирәк! Ут эченә тирәнрәк кергән саен, үземнең хаклыгыма ныграк инана бардым. Сугышта кешенең күңеле ката, диләр. Минемчә, киресенчә. Кеше авырлыкны ничаклы күбрәк күрә, күңеле шулчаклы сизгерләнә генә. Мин аны хәлиткеч атака алдыннан (кем исән кала, ә кем – юк!) окоп эченә тезелешеп басып, йә кырын ятып минем җырлавымны тыңлаган гаскәриләрнең җылы күз карашы белән очрашкан вакытта тирәнтен аңладым.

Казаннан берничә вагон азык-төлек, бүләкләр, хатлар алып бардык. Фронт сызыгына якынлашкан саен, яралылар төялгән составлар ешрак очрады. Поезд туктап торган арада яралыларның күңелен күрергә, хәлен җиңеләйтергә өметләнеп, тиз генә мини-концерт куеп алабыз. Перронда татар, рус җырларын яңгыратабыз, вагон тәрәзәләреннән башлар сузыла, сызланудан чытылган ябык йөзләргә елмаю куна.

Охват станциясендә поездданн төшеп, дивизия штабы җибәргән машинага кучеп утырдык. Бүләкчүтәнәчләрне полуторкаларга төяделәр. Ул чакта фронт сызыгы Ловать елгасы буеннан уза иде. Коточкыч бәрелешләр көн саен булып тора. Габдулла Галиев җитәкчелегендәге делегациябездә танылган гармунчы Фәйзулла Туишев бар иде.

Любовь Бердникованың дәртле биюенә кушылып, солдат күнитекләре дә тыпырдый. Нәфис сүз остасы Павел Макеевның фашистларны мыскыллаган шигырьләрен тыңлап, солдатлар гөрләшеп көлешә.

Ике атналык командировка 45 көнгә сузылды. Алгы сызыктагы һәр солдатның безне күрәсе килә. Аларны рәнҗетеп кайтып китеп булмый бит инде. Баш очында ядрә сызгырганда, артында дошман пулеметы тырылдаганда җырлап тору җиңел эш түгел, әлбәттә. Гомерең кыл өстендә! Тик бу хакта



PRESSA.RU

уйламаска тырышасың. Башта бер генә уй: тиздән атакага ташланасы гаскәриләрнең сугышчан рухын күтәрергә! Бөек Җиңү көнен якынайтуга һәрберебез үз өлешен кертә бит. Без барган дивизиядә татарлар, башкортлар күп иде. Якын туганнарымдай тоелды алар миңа. Үз телебездә аралашу-сөйләшү – үзе бер кадерле истәлек.

Полковник бинокленнән каршы якка күз салгач, куркуымнан тәннәрем чемердәп китте. Дошман кул сузымында гына булган бит!

– Галия апа, алгы сызыкта йөрү бик хәтәр булгандыр. Немец ядрәсе: «син – сугышчы, ә син – артист», дип, аралап, аяп тормый бит...

Галия апаның нурлы йөзе уйчанлана. Әле генә рухланып концерт тыңлаган, җырлавыңны яратып, кул чапкан солдатларның, атакага күтәрелгәч, чалгы тигән кыяк үләндәй егылып, күз алдында җан бирүен күрү кемгә җиңел булсын соң?

– Яшермим, фронтта йөргәндә, кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күперләрен кичкән чаклар шактый булды. Газраил әллә ничә мәртәбә яныннан ук үзып китте, гомерем бетмәгәнгәдер, күрәсең, бугаздан буа алмады... Берсендә ат арбасына төялешеп, элемтә ротасына юл тоттык. Аның командиры үзебезнең милләт кешесе икән дип ишеткән идек. Юлда барганда, көтмәгәндә дошман артиллериясе ут ачты. Шартлау дулкыны арбаны әйләндереп каплаганын сизми дә калдык. Зыяны үземә дә тиде, шунда җиңелчә контузия алдым. Бәхеткә, бөтенләйгә чукрак калмаганмын. Ничек кирәк алай, тиешле җиргә барып җиттек. Капитан Насыйровның элемтә ротасы солдатлары безне татар, башкорт, рус телләрендә алкышлап каршылады. Андый чакларда сөенечтән башлар күккә тигәндәй була иде. Данлыклы «Катюша»дан ут яудыручылар алдында чыгыш ясадык.

Бер мәлне Алябьевның «Соловей» романсын бик бирелеп башкара идем, конферансье Паша яныма килде дә: «Әкренрәк җырлый күр, немец пулеметчылары ут ача күрмәсен», – дип колагыма пышылдады. Мин аны шаярта дип торам.

Әллә каушап калудан, әллә куркуымнан, гомер булмаганны, тавышымны күтәреп: «Безнең җирне таптыйлар бит бу оятсыз илбасарлар! Нигә кырып салмыйсыз шуларны?» – дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым.

Полковник, елмаеп, окоптагы гаскәриләргә ишарәләде!

«Күрәсезме, солдатларым атакага әзер. Приказ бирүемне көтәләр. Сезнең концерт тәмамлануга башлыйбыз», – диде.

Тынычлангач, гафу үтендем, билгеле...

Казанга кайткач, Галия апага фронттан хатлар килә, ул үзе дә командирларга бәйрәм уңаеннан котлаулар юллый. Галия апа ядкарьләрне кадерләп саклый.

Галия Кайбицкаяга хәрби часть командиры генерал В. Грибовтан килгән рәхмәт хатында менә нинди юллар бар: «Татарстанның якты йолдызы Галия! Сезгә фронт сәламе юллыйм. Дуслыгыгыз, котлауларыгыз өчен ихластан рәхмәтлемен. Бары тик талантлы, фидакарь кеше генә безнең алда җырлый, без кичергән авырлыкларга түзә ала. Сезне үтеп чыккысыз кара урманнар һәм сазлыклар да, немец снарядларының шартлап ярылуы да, пулялар сызгыруы да куркытмады. Тыныч шартларда Сезнең талант тагын да көчлерәк чәчәк атар әле».

Галия апабыз «Почет билгесе», Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә, ТАССРның халык артисткасы исеменә лаек була. Бу дәүләт бүләкләрендә утлы фронт юлларының да өлеше бар.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН



Фото Г. Камал исемендәге ТДАТ архивыннан

Театр архивында сугыш вакытында И. В. Сталин җибәргән рәхмәт телеграммасы саклана: «Сотрудникам Татарского государственного академического театра, собравшим 120000 рублей на постройку новых видов вооружения мой братский привет и благодарность Красной Армии». 1942-1943 елларда мәдәният министрлыгы һәм театр җәмгыяте фронтка җибәрү өчен концерт бригадалары оештыра башлый. Ил күләмендә артистлар тарафыннан фронтта куелган концертларның саны 1350000 гә җитә. Татарстаннан киткән концерт бригадаларында Камал театры артистлары да бар: «На основании приказа Управления по делам искусств при СНК ТАССР командировать для художественного обслуживания прифронтовых частей... Р. Зиганшину, И. Гафурова, А. Масаутову, Р. Таминдарову, баянистку Р. Ибрагимову».

«...Безне Төньяк-Көнбатыш фронтка Ленинград ягына җибәрделәр. Кыр госпитальләрендә һәм аерым частьларда чыгыш ясарга маршрут билгеләделәр. Һәр көн ике-өч концерт куябыз. Күктә снарядлар сызгыруы ишетелеп тора... Сугыш дәһшәтен үз күзләребез белән күреп, өч айга якын алгы сызыкта йөрдек». Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншинаның «Күңелем түреннән» исемле китабыннан.




АК КАЛФАКНЫҢ ҖЫЕЛГАН ЧАГЫ

Апрель аенда Бөтендөнья Татар конгрессы дүртенче мәртәбә Хатын-кызлар форумын җыйды. 500 делегатның 110 сы дөньяның 22 иленнән, 270 е Россиянең 52 төбәгеннән, 120 се Татарстанның 43 районыннан башкалабыз Казанга килде. Мәшһүр Мөхлисә Бубыйның «Гүзәл затларыбыз милли җанлы булса, татар упкынга төшмәячәк, яшәячәк» дигән үлемсез сүзләре форумның шигаре итеп алынган иде.

Быелгы форум бөек Тукаебызның 130 еллык юбилеена туры килгәнгә күрә микән, аеруча тантаналы төс алды. Кәрим Тинчурин исемендәге театрда узган пленар утырышны чирек гасыр тарихлы «Ак калфак» оешмасының хәзерге җитәкчесе Кадрия Идрисованың чыгышы ачып җибәрде. Аннары Татарстан Премьер-министрының урынбасары Энгель Фәттахов форум кунакларына Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның мөрәҗәгатен ирештерде. Форум эшендә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма Комитеты рәисе Ринат Закиров, Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм тел мәсьәләләре комитеты рәисе Разил Вәлиев тә катнаштылар.

Хатын-кызларның бу форумда да уртага салып сөйләшәсе сүзләре бик тә җитди булып чыкты. Алар хакында секция утырышларында сөйләштеләр. «Мәгариф системасында милли тәрбия», «Милли-мәдәни мирасны саклап калу һәм үстерү», «Татар халкының тәрбия системасында кулланылышта булган яңа проектлар» хакында сөйләшүләрдә Төркиядән Гөлтан Ураллы, Мәскәүдән Нәзифә Кәримова, Кытайдан Фәхринур Хәсән, Башкортстаннан Зөлфия Гыйзетдинова һәм башкалар гаять хисле итеп сөйләделәр. Кайбер чыгышлар нигезендә махсус карарлар да кабул ителде.

Беренче кичтә кунаклар Кәрим Тинчурин исемендәге театрда Чулпан Закирова җитәкләгән «Казан» җыр һәм бию ансамбленең концертын карап, рухи ләззәт алган булсалар, икенче көнне алар Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театрында Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган тантанада катнаштылар. Тантанадан чыгуга делегатлар Казан Ратушасына «Калфак туе»на юнәлделәр. Форумның һәр делегаты калфактан иде...



Тулырак мәгълүмат һәм фоторепортажны сайтыбызда таба аласыз.

PRESSA.RU

ҖИДЕ ЯТ АРАСЫНДА...

МИН АНЫ, МОННАН УНИКЕ ЕЛ ЭЛЕК ПАРИЖГА ЯҢА АЯК БАСКАН, АТАКЛЫ ЭЙФЕЛЬ МАНАРАСЫНА СОКЛАНЫП, ГАҖӘПЛӘНЕП КАРАП БАСЫП ТОРГАН РЕЗЕДАНЫ КҮЗ АЛДЫНА КИТЕРӘМ. ФРАНЦУЗЧА БЕР КӘЛИМӘ СҮЗ БЕЛМӘГӘН ЯШЬ ХАНЫМНЫ...





Гөлнур САФИУЛЛИНА

Парижда төпләнеп, француз мәдәниятенә кушылырга теләсәгез – кызыгызның исемен алыштырыгыз!

Балалар бакчасында табиб берсендә Резеданы шулай дип каршы ала. Сөембикәнең исемен үзгәртергәме?! Дус кызлары: «Миңа да шундый исем кирәк!» – дип йөргәндәме? Булмаганны!

– Аның әтисе тиздән Франциядә докторлык дәрәҗәсен яклый, минем дә ике югары белемем бар – без бер телем ипи эзләп килгән эмигрантлар түгел. Бакчадагы бөтен бала кызымның исемен тутырып әйтә, сез дә өйрәнерсез! – дип җавап бирә ул аңа.

Әйе, чит илнең кояшы астында үз урыныңны табу җиңел түгел...

Тукмагың кайда – сукмагың шунда: ире укуын магистратурада Франциядә дәвам итәргә тиеш булгач, аңа да юлга җыенмый чара калмый. Инде менә ул да шушы шәһәрдә яшәргә, эшкә урнашырга тиеш... (Үзе эшләячәк офисның тәрәзәләре нәкъ менә Эйфель манарасына карап торырын ул чакта кайдан белсен соң әле ул?!)

Иң элек – тел өйрәнергә! Суга кергәч, йөзеп китми хәлең юк... Күчеп килүчеләрнең күбесе кебек Резеда да тел өйрәтүче курсларга языла. Түләүле булса да, «Альянс Франсез»ны сайлый (бу оешманың филиалы Казанда да бар), чөнки бушлай курсларда өйрәтүнең сыйфаты түбән. Группада 10-15 кеше булалар: берәүләр Кытайдан, Пакстаннан, ә икенчеләр Шри-Ланкадан, Испаниядән килгән. «Француз теле – шактый авыр тел. Әмма мин үземне мескен итеп тоярга яратмыйм. Кибеттә кирәк әйбереңне сорый алмау, табибта кай җирең авыртканны аңлата белмәү – мескенлек бит инде... Телевизор бик күп карадым. Рекламалар еш кабатлана һәм аларда ни хакында сүз барганы тәрҗемәсез дә аңлашыла. Аннан гел кибетләр җибәргән каталогларны актардым. Алар да әлифба кебек: рәсеме ясалган, астына ни икәне язылган», – ди Резеда.

Университетка укырга керү – тормышның икенче этабы була. Хәер, юк, өченчесе. Әни булу – Сөембикә туу бар бит әле!

– Франциядә бала табу йортына кергәндә, син инде туачак балаңа нинди исем кушачагыңны тәгаен белергә тиешсең – документлар шунда ук тутырыла. Ә Сөембикә исеме миңа күптән ошый иде. Башка халык арасында яшим дип, хыялымнан баш тарта алмыйм бит! Язганда кыскартырга тырышып карадылар, әмма без: «Юк!» – дидек. Кызым үз исеме белән бик горурлана! Аның ханбикә исеме икәнен кечкенәдән белә. Казанга кайткач, Сөембикә манарасы янына бармый калганыбыз юк.

Читтә яшәүнең иң кыены – бала үстергәндә булышыр кешең булмаудыр. Тел өйрәнү курсларын тәмамлау өчен Резедага да кызына нәнкә эзләргә туры килә. Танышлары аша бер төрек әбисен табалар. Сөембикәнең теле татарча ачыла. (Икесе дә шәһәрдә үскән яшь әти белән әни дә кызлары янында русча сүзләр кушмыйча сөйләргә өйрәнә!) Бары тик төрекчә генә сөйләшкән тәрбияче әбидән кызчык тиз арада төрекчәне дә ота – кайчандыр татар-төрек лицеен тәмамлаган әтисенә аңгәмәдәш арта. Ике яше тулгач, Сөембикәне балалар бакчасына бирәләр. Французча бер сүз белмичә яшьтәшләре арасына барып кергән бала ике-өч айда дуслары белән иркенләп аралаша башлый. «Балага никадәр күп тел өйрәтәсең, аның баш мие шулкадәр ныграк эшли», – ди Резеда. Сөембикә кечкенәдән татарча, төрекчә, французча сөйләшә. Инглиз телен аларга 1 нче класстан өйрәтә башлаганнар. Русчага аны берәү дә махсус өйрәтмәгән: Казанга кайткан чакларда телевизор карау, үзе кебек балалар белән аралашу җиткән. Быел исә мәктәптә аларга янә сайлау мөмкинлеге биргәннәр: кем испан телен сайлый, ә кем кытайны. Алар тагын юлның авырын сайлаган. Инглизчә, французча сөйләшкән кеше испанчаны болай да җиңел үзләштерә (нигә аңа вакыт сарыф итәргә?), димәк, кытай теле кала... Сөембикә, шулай итеп, алтынчы тел үзләштерә хәзер.

Тел өйрәнер өчен ихтыяр көче һәм тырышлык кирәк.

Франциядә балалар мәктәпкә алты яшьтән бара. Резеданың кызы яшьтәшләреннән ике сыйныфка алданрак укый. Әзерлеген тикшергәч, беренче класста ук укытучылары югарырак класска сикертергә уйлаган аны. «Буе да кыска бит әле», – дип, әти-әнисе риза булмаган. Ике елдан соң, мәктәптә кабат шул хакта сүз кузгатканнар... «Әйбәт кенә укып китте», – ди әнисе.

...Казанда финанслар менеджментын өйрәнгән Резеда, Париж университетына укырга кергәч, халыкара сәүдә өлкәсен сайлый. Стажировканы ул Франциянең иң зур банкларының берсендә уза.

– Франциядә банк системасы бик алга киткән. Шундый урында көчемне сынап карау күптәнге хыялым иде. Без группада егерме биш кеше укыдык. «Мин үземнең кайда эшлисе килгәнен беләм!» – дия идем аларга. Сабакташларым бу сүземнән көлде генә. Ә мин үзем стажировка узган, үзем теләгән шул банкка эшкә урнаша алдым! Әрсезлегем түгел, тырышлыгым белән ирештем бугай моңа. Кырык илдә филиаллары бар ул банкның (Россиядә – «Рус Банк» һәм «Дельтакредит»). Төп офислары – Парижның шундый ук зур оешмалар урнашкан районында. Бу офиста алты йөзләп кеше эшли, алар банкның дөнья буйлап таралган әлеге филиаллары белән идарә итә. Мин эшләгән финанс дирекциясенең җитәкчесе Румыниядән иде, ә минем белән бергә эшләүче ир-ат – Кытайдан. Чит Сай Шанхай университетында француз теле өйрәнгән, аннан Лионда бизнес-мәктәп тәмамлаган. Банкка минем кебек стажировкага килгән һәм урна-

PRESSA.RU



«Мин татар, лəкин Франциядə туганмын», — дип кабатларга ярата Сөембикə.

шып калган. Без төп офисның еллык бюджетын əзерлибез. Сентябрьдə башлыйбыз, гыйнвар азагында гына төгəллибез. Җаваплылык зур! Банк хезмəткəрлəре өчкə бүленə: берəүлəр атнасына – 35, ə икенчелəр 39 сəгать эшли, ə өченче төркемнең – монысына без керəбез – эш сəгате чиклəнмəгəн. Кирəк икəн, эш көне беткəч тə калабыз, өйгə дə алып кайтып эшлибез. Бу – контрактыбызга да язылган. Шуның өчен безгə 14-16 көн өстəмə ял бирəлəр.

Безнең, Россиядəн килгəннəрнең, эчендəге – тышында: нəрсə уйлаганны шунда ук əйтəбез. Ə кытайлар, əлбəттə, үз-үзлəренə биклəнгəн, аларның уенда ни икəнен белеп тə, аңлап та булмый. Чит Сайга, бəлки, минем белəн эшлəү авыррак та булгандыр. Парижга хатынын да алып килде, əмма ул французча өйрəнə алмады. Шуңа күрə хезмəттəшем миңа гел сокланып карый иде: «Син телне ничек өйрəндең? Хəтта эшкə дə урнаша алгансың!» – дия иде. Татарлар белəн үзлəрендəге уйгырлар аша беркадəр таныш иде ул. Ə французларның, мин алар арасында эшли башлаганда, безнең хакта ишеткəннəре дə юк иде (хəзер андагы ир-атның күбесе Казанны, Татарстанны «Рубин» аша белə). Франция үзе унитар дəүлəт булгач, «Рəсəйдəн килсəм дə, мин рус түгел», – дигəнемне аңлау, кабул итү авыррак аларга. Сорау арты сорау яудыралар: «Алайса нигə сездə рус паспорты?», «500 ел руслар белəн яшибез дисез, ə туган телегезне ничек саклый алдыгыз?», «Сезнең үз Президентыгыз булгач, Россиядə алар икəүмени?» – дилəр. Аңлатырга

БЕЗДƏ БОЛАЙ, АНДА НИЧЕК:

■ Турист булып, шəһəрне манзара кылып китү бер нəрсə, ə яшəргə дип килгəч, иң элек көнкүрештəге проблемалар белəн очрашасың. 15-20 квадрат метрлы фатирны күреп башта шаккаттым. Хəтта шок булды! Кухня да, ванна да шунда... Əти белəн əнинең «малосемейка» дип сөйлəгəннəре искə төште... Əйе, французларның күбесе сыерчык оялары кебек шундый кечкенə фатирларда яши.

■ Французларда бездəге кебек эштə дуслашу юк. Дөресрəге, дуслашу бар, əмма бөтен проблемаңны уртага салып сөйлəшү, уртаклашу юк. Монысын авырсынмыйм: өйдəге борчу-мəшəкатьлəреңне эштəгелəрнең белүе мəҗбүри түгел дип яшим мин. Эшкə – эшлəргə барам!

■ Августта Парижда кеше калмый – бөтенесе ял итə. Шəһəр бушый, хəтта бөкелəр дə бетə.

■ Француз хатын-кызлары тавыш бирү хокукына чагыштырмача күптəн түгел – узган гасырның илленче елларында гына ирешкəннəр. Ирдəн язма рөхсəтсез əле сиксəненче елларга кадəр банкта исəп-хисап счеты ача да, акча да ала алмаганнар. Ни өчен икəнен дəлиллəп бирмəгəндə, аларны беркайчан җиңел генə ирдəн аермаганнар. Хəзер дə шулай. Бəлки шуңадыр, Франциядə феминистик хəрəкəтлəр күп.

■ Француз гаилəсендə өй эшлəре гел икегə бүленə: син идəн юасың, мин ашарга пешерəм... Бездəге кебек: «Əтиегез!» – дип зурлап торулар анда провинциялəрдə генə очрый. Парижда – унисекс. «Кəефең начар күренə, бүген төнлə йокламадыңмы əллə?» – дип соравыңа, ир-атның: «Əйе, бала елады, төне буе аны күтəреп йөрдем», – дип җавап бирүе – гадəти күренеш. Гаилəдə ике əни дияргəме, əллə ике əти дип санаргамы, белмим. Соңгы сүз һəрвакыт ир-атта түгел аларда. Чөнки бер үк күлəмдə хезмəт хакы алгач, ир-ат «мин – гаилə башлыгы, сезне мин тəэмин итəм», дип əйтə алмый. Гомумəн, тормышны алып баручы ир-атлар анда бик аз.

■ Француз əби-бабайлары оныкларга артык бəйлəнмəгəн. Дөрес, оныкларын түгəрəклəргə йөртүчелəрне күргəлим.

■ Франциянең хезмəт кодексында шундый юл бар: балаларың кечкенə булса, тулы булмаган эш көненə урнаша аласың. Күп əнилəр чəршəмбе эшлəми, чөнки кечкенə балалар атна уртасында бер көн укымый. Түгəреклəр исə – эшли. Балаларын озатырга, каршы алырга, дип, шуңа күрə күплəр чəршəмбе ял ала. Эшеңдə җитəкчелек рөхсəт итсə генə, билгеле. Мин үзем бер генə ел алай эшлəп карадым.

■ Француз халкы һəрнəрсəдə тəртип ярата. Балаларын да кечкенəдəн шуңа өйрəтəлəр: билгеле бер вакыт-

тырышам, татар халкы тарихын сөйлим. Тыңлап-тыңлап торалар да, тагын сорау бирәләр: «Үзегез Рәсәйдән, ә нигә сез зәңгәр күзле, аксыл чәчле түгел?» – диләр...

Француз дусларны кунакка чакырганда, әлбәттә, татар ашлары әзерлим. Берәр бәйрәмгә дәшсәм: «Ә өчпочмак буламы?» – дип сорыйлар хәзер. Баскан токмачны бик яраталар. Һәрвакыт: «Син моны ничек шулай кисә аласың?» – дип аптырыйлар. Шулпалы бәлеш тә пешергәлим. Әмма ул бит мичтән алуга гына тәмле, ә Парижда гел бөкеләр: кунакларыңның син әйткән вакытка килеп җитмәве дә бар. Аннан инде каһвә урынына: «Монысы да татарча булсын», – дип, аларга чәй эчертәм...

Ә Парижда татарлар бармы икән? Бу сорауга җавапны Резеда килеп урнашканнан соң ике ел узгач кына эзләргә керешә. Баш-күз алгач, телне инде өйрәнгәч, шәһәрдә адашмыйча йөри белә башлагач... Хәер, аңарчы да дуслар тапмыйча тормый ул: башта – курсларда, аннан – университетта. Әмма җиде ят арасында сиңа татарча эндәшүчене табу – анысы бөтенләй башка.

Милләттәшләрне эзли башлагач, башта ул... Германия татарларына юлыга. «Татарлар-Дойчланд» җәмгыяте рәисе Венера ханым Вәгыйзова татарларның Франциядә дә оешмалары барлыгын әйтә. Парижга юл шулай итеп Берлин аша салына... (Баксаң, үзе эшләгән банкта ук татарлар бар икән! Казан кызлары Нурия белән Ләйлә, Себердә үскән Рамилә. Сөйләшеп, очрашып, аралашып торалар. Якыннар, чөнки үзеңнекеләр...)

«Франция–Татарстан йорты» оешмасы вице-президенты Әлфия Айзатова белән күрешеп танышкан көннән башлап Резеда Мәҗитова да татар диаспорасы үткәргән һәр чараның эчендә кайный. «Эш, гаилә белән генә тормыш тәмамланмый, – ди ул. – Милләтеңә дә нинди дә булса бер файда китерү кирәк. Монысы – күңелең, җаның өчен...» Инде ике тапкыр Парижның үзендә Сабантуй үткәргәннәр. Татарлар белән бергә руслар килгән, татар кызларының француз ирләре, ул француз ирләрнең дуслары... Франциядәге татар диаспорасы нинди генә очрашу үткәрсә дә, Сөембикә һәрвакыт яңа шигырь өйрәнеп бара. Аны Парижда шулай дип йөртәләр дә: «Татарча шигырь сөйләүче Сөембикә».

Теләсә кайсы милләтне күбрәк аш-су аша беләләр, аңлыйлар, истә калдыралар.

– Мине иң сөендергәне – күчеп килгән татарларыбызның бередә югалып калмавы. Кемне генә алсаң да, һәркем үз урынын тапкан, нәрсәгәдер ирешкән...

Минемчә, бу сүзләр иң беренче чиратта Резеданың үзе турында!



та ашарга, йокларга ятарга, торырга... Ялны да алар бер ел алдан планлаштыра. Безнең сыман юлга соңгы минутта җыенып чыгып китми. Бер яктан – бу бик әйбәт, икенче яктан – иҗатка урын калмый. Безнең кебек стресска җайлашу юк инде аларда... «Бүген кич нишлисең, әйдә, очрашып чәй эчик яки син бушмы, театрга билетым бар», – дип Россиядән килгән танышларга гына әйтеп була. Ә французлар белән авыррак... Гаилә дусларым – Кристин белән Жерар бар. «Фәлән датага шуны планлаштырабыз, сез килә аласызмы?» – дип, алар, гадәттә, кунакка бер ай алдан чакырып куялар. Мин дә шулай эшләргә тырышам.


■ Туган көнеңне, мәсәлән, ресторанда үткәрсәң, табынга китергән аш-су өчен бездә чакырган кеше түли бит. Аларда исә башка тәртип: һәр кунак нәрсә ашый, үзе шуңа түләп китә. Өйгә дә кунакка чакыралар: ул вакытта «һәркем үзе белән берәр нәрсә пешереп алып килсен», диләр.

■ Толерантлык сүздә түгел, эшгамәлләрендә күренә французларның. Дуңгыз ите ашамавыбызны безнең белән аралашканнары, әлбәттә, белә. Кунакка чакырсалар: «Балык әзерләсәк ярыймы?» – дип алдан сорамый калмыйлар.

■ Туйны алар 2-3 ел алдан әзерләргә керешәләр. Кәләшкә туй күлмәген дә ким дигәндә 2 ел алдан тектерә башлыйлар.

■ Өйләнү-кияүгә чыгу процессы бик авыр, катлаулы аларда: махсус тестлар үтәргә, нәтиҗәләрен кәтәргә кирәк. Аерылышулар да шулай – икешәр елга сузыла. Шуңа күрә яшьләр кавышырга, никахлашырга ашыкмый. Бергә торып, ике-өч бала табып, алар үсә төшкәч кенә, туйга әзерләнә башлау – гадәти күренеш анда.

PRESSA.RU



ФИЛЬМОГРАФИЯ

2006 **«Өйдә кем хуҗа?»** (сериал) – Марат Карсаев.

2007 **«Сайлау көне»** – Камил Ренатович.

2008 **«Радио көне»** – Камил.

2009 **«Феникс синдромы»** – Анатолий Абдрыков.

2010 **«Ирләр ни турында сөйләшә?»** – Камил.


2011 **«Ирләр тагын ни турында сөйләшә?»** – Камил.

2011 **«Яңа өйләнешкән пар»** – Антон.

2012 **«Гомерлек никах»** – Алексей Мухин.

2013 **«Пакетка төрелгәннәр»** – Сергей Камаев.

2015 **«Сайлау көне-2»** – Камил Ренатович.



КАМИЛ ЛАРИН



АРТИСТЛЫККА ЮЛ

Волгоградта татар гаиләсендә туа. Революциягә кадәр яшәгән бабасы, татарларны кысрыклауга түзә алмыйча, үзенә беренче ишеткән рус фамилиясен ала.

«Әти-әни сүзен тыңлап, энергетика техникумына укырга кердем. Шул ук вакытта Саратов театр училищесына да кергән идем, тик өйдәгеләр моны хупламады. Артист булу турында онытып торып, техникумны тәмамларга туры килде. Аннары үз сүземне кистереп әйттем инде: 1988 елда ГИТИСның үзем теләгән эстрада факультетына кердем». Тамашачы аны «Бармакларыгыздан ладан исе килә» (1993), «Акча» (2002), «Минем сөйкемле тәрбиячем» (2005) кебек фильмнарда эпизодик рольләрдә күреп белә.



«КВАРТЕТ И»

Шулай да танылуны аңа «Квартет И» дип аталган театр китерде. «ГИТИСта укыганда курсыбыз белән үзебезнең театрны булдыру турында хыялландык. Тик укып бетергәч, төрлебез төрле якка таралышты. Бишәү генә калдык: Александр Демидов, Леонид Барац, Ростислав Хайт, мин һәм режиссер Сергей Петрейков. 1993 елда «Квартет И» оешты. Шул гомердән бирле бергә без. Аерым гына башка проектларда да катнашабыз, тик табышны һәрвакыт бишкә бүләбез. Дуслык – беренче урында».



КАМИЛ РЕНАТОВИЧ

Ә киң аудиториягә театрны «Радио көне» һәм «Сайлау көне» спектакльләре таныта, соңрак алар фильм итеп тә төшерелә. Камил Ларин анда электрик Камил Ренатовичны (дуслары Камил Маринадыч дип йөртә) уйный. Аның герое эчәргә ярата һәм бу гадәтен ташларга хыяллана. Ларинның бу роле аңа шулкадәр «берегә», аны урамда танып: «Исәнмесез, Камил Ренатович», – дип исәнләшә башлыйлар. Ул үзе моңа Довлатов сүзләре белән җавап бирә: «Танымасалар да аптырыйм, танысалар да аптырыйм, шуңа күрә гел аптыраулы кыяфәттә йөрим».



ШӘХСИ ТОРМЫШ

Вокзалда очраклы рәвештә генә танышу яңа гаилә барлыкка килүгә сәбәпче була. Камил белән Галина 20 ел ир белән хатын булып яшиләр, Ян исемле ул үстерәләр. 2012 елда экранга «Гомерлек никах» дип аталган яңа фильм чыга. Ларинның герое анда 20 ел бергә яшәгән хатыны белән аерылыша. Озак та үтми кинодагы вакыйга тормышта да кабатлана: Камил белән Галина аерылышалар.

Камил Ларин күптән түгел икенче тапкыр өйләнде. Хатыны Екатерина Андреева узган ел 48 яшьлек актерга малай бүләк итте.



«МИН — ТАТАР!»

Камил Ларин «Радио көне» спектаклендә һәм фильмында әнисе белән татарча сөйләшә, тормышыннан зарлана. Ә спектакльдә сәхнәдән: «Хурлама мине, әнкәем», – дип җырлап кереп китә.

«Әти-әни белән татарча сөйләшәм. Туган телемне онытасым килми, сөйләмемне һәрвакыт камилләштерергә тырышам. Улым Янга да татар сүзләре өйрәткәлим, ул аларны ятлап кала. Әдәби телдә сөйләшмәгәннән генә минем татарлыгым кимеми!

Әни пешергән өчпочмакны яратам. Ул минем янга Мәскәүгә килгәндә һәрвакыт ике зур бәлеш һәм токмач алып килә. Кулдан кискән токмач!»



БУШ ВАКЫТТА

Татарстанның атказанган артисты Камил Ларин буш вакытында футбол, гольф, шахмат уйнарга ярата. Автомобильләр белән кызыксына. Балыкка йөри. Илһамы килсә, шигырьләр дә яза, замана яшьләре хакындагы фәлсәфи уйларын шигырь юлларына сала. «Миннән әйбәт журналист та чыгар иде, – дип белдергән Камил Ларин бер интервьюсында. – Әгәр журналист булсам, мин үз-үземә: «Син бәхетлеме?» – дигән сорау бирер идем. Һәм җавабым: «Мин бәхетле!» – булыр иде».

Мәгълүмат һәм фотолар төрле матбугат чараларыннан алынды

PRESS.RU

Ренат Харис... Татарстанның халык шагыйре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, Россия Федерациясе Дәүләт премиясе лауреаты... Аның шигърияте үзенә бертөрле, кӧтелмәгән: уйландыра, сокландыра, шаккаттыра... Йә булмаса, җыр сүзләре булып, «Кояшлы вальс»ындагыча, җанны иркәли. Хәтерлисезме: «Күрешербез әле, сөйләшербез әле...», «Уяндыңмы, елмай – көнне башла шулай...», «Кәгазь кӧймә, кәгазь кӧймә, каян килдең – сөйлә, сөйлә, сөйлә...» Ул – рәссам-график та! Шигырьләр язган дәфтәргә, кәгазьгә рәсемнәр дә төшерә. Аларында да – шагыйрьнең күңел халәте: туган авыл табигате, Буа яклары, урман сукмаклары, үзе яшәгән йорт тәрәзәсеннән күренгән дөнья, яраткан бакчалары, сынган килеш тә алмалары белән сыйлаучы алмагач... Юк, ул рәсемнәр – шигырь кебек. Әллә соң шигырьләре рәсем кебекме? Әйе, шулай! Поэмалары опера либреттосы, ораторияләр, кантаталар булып та халык күңеленә кереп кала. Кыю сәясәтче, күренекле җәмәгать эшлеклесе...

Бу көннәрдә киң җәмәгатьчелек, күпсанлы шигырь сөючеләр Ренат Харисны күркәм юбилее белән тәбрикли. Без дә кушылабыз! Укучыларыбызга шагыйрьнең хатын-кызларга багышланган өр-яңа шигырьләрен тәкъдим итәбез.


Ренат ХАРИС

Ә БЕЗ ҺАМАН ӘЛЕ ЭЛЕККЕЧӘ!

Кеше кайчан горур?

Кеше кайчан горур була?
Улы, кызы булганда,
киявеннән, килененнән,
оныклардан уңганда;
дусларына сөйләгәндә
гаиләсе турында,
рәхәтләнеп коенганда
үз шатлыгы нурында!

Кеше кайчан горур була?
Халкын мактый алганда,
яла аңа ук атканда,
әверелсә калканга;
туган теленең байлыгын
күрсәткәндә сүзендә
бер бөртек шатлык тамчысы
агып чыкса күзеннән!

Кеше кайчан горур була?
Ярышларда йөргәндә
иң югары пьедесталда
ил байрагын күргәндә,
аның җилфердәү тавышын
җыр итеп тыңлаганда,
оттырган чакларында да
күңеле сынмаганда!

Кеше кайчан горур була?
Өметен өзмәгәндә –
үз халкының тарихында
уй-гыйбрәт эзләгәндә,
вак-төякне атлап үтеп,
олыны күтәргәндә,
үчләшү хисе давылын
теш кысып үткәргәндә!

Кеше кайчан горур була?
Азат булса Ватаны,
җаны теләп каршы алса
Ватанының һәр таңын;
үзе теләгән хезмәттә
кичкә тоташса көне,
тыныч ял һәм назлы ләззәт
татырга бирсә төне!

Кеше кайчан горур була?
Үзен-үзе сынаса:
җаны – акылын, акылы
йөрәк сүзен тыңласа;
ерткычлыкны уятмаса
канындагы кыюлык,
масаюга әйләнмәсә
үзендә көч тоюы!

Кеше кайчан горур була?
Язмышын кулда тотса,
горурлыгының нигезен
белсә, аны ныгытса,
кая барганын аңласа,
җиткәч тә җиде чатка,
адашмаса, курыкмаса...
Кеше горур шул чакта!

Аклык хуш исе

Ак пионнар арасында булдым.
Җанга сеңде аклык хуш исе...
Сиңа гына әйтер сүзләремә
шул хуш исне ничек кушыйм соң?

Ә хуш исле була димсең төсләр?
Уйларыңны шикләр кисмәсен –
яңа сауган сөтне иснәп кара,
яңа яуган карны иснә син!..

Нинди җылы, нинди
сафлык-пакьлек!
Ак кар! Ак сөт! Ап-ак пионнар!
Мәхәббәттән туган һәр сүздә дә
хуш исләргә көчле тоем бар!

Сине уйлыйм. Сүзгә сүзләр тезәм...
Буш фикерме алар? Буш хисме?..
Укы әле шушы язганымны,
шәт татырсың пион хуш исен...

Беренче хәбәр

Шатландыммы,
әллә каушадыммы,
әллә курыктыммы икән мин,
«Мин авырлы...» дигәч...
Истә түгел
бу турыда хәбәр иткәнең...

Балалар да инде олыгая –
өйләнделәр хәтта оныклар...
Эх, яшьлекнең ваемсыз хәтере
нинди! нинди! көнне оныткан –

яңа дөнья тууы турында
хәбәр алган бөек мизгелне!..
Оныклардан бала көткән көннәр
әллә ничек безгә тиз килде...

Гомер сиздермичә үтеп бара,
чабуында безне өстерәп...
Ә без һаман әле элеккечә!
Дөнья гына бераз искергән...

Килә дә яз

Килә дә яз, тәрәзләрдә эреп,
сүрән кышлар белән хушлаша,
җылы ташкын, нурлы чәчрәү булып,
йөрәктәге язга тоташа!

Килә дә яз, тәрәзәдән күреп,
минем шатлык белән кавыша.
Шул чагында кар сулары белән
агып китә кебек сагышлар.

Килә дә яз, тәрәз аша кереп,
йөрәктәге язга сүз ката.
Ә яз җанның чәчәк бөреләрен,
тылсымлы дәрт өреп, кузгата.

Яшәештә тигез бөтен фасыл –
язы, җәе, көзе һәм кышы.
Никтер йөрәк
күтәп ала бигрәк
кар эрегән язлар балкышын.

Аһ!

И Җир-анам, йөт син аны берүк!
Раиса САРБИ,
чуаш шагыйрәсе

Әй, мәхәббәт! Мине газаплый ул –
бозга сала, утта яндыра,
кара төндә,
салкын көндә
көнләү давылының үзәгендә
ялгызымны гына калдыра.

Әй, мәхәббәт! Миннән киткән чакта
син кызганма аны, абынсын –
егылсын да авырттырсын кулын,
егылсын да ул онытсын юлын,
ачы яше белән капла аның күзен,
күрми торсын бераз якты дөнья
йөзен,
мине генә,
мине генә
минем кебек сагынсын...

Аһ, мәхәббәт! Зинһар, алай итмә –
аһларымны аңа беркетмә,
ул бит мине
көне-төне,
үз-үземне онытырлык итеп,
җәннәт багъларында йөртә.

Аһ, мәхәббәт! Ул да мине сөя,
җан-фәрманга миңа ашкына.
Келәм җәйдер аның юлларына,
көч-куәт бир аяк-кулларына,
илаһи нур белән сакла аның күзен,
ул бит үзе бизи якты дөнья йөзен, –
яши алмыйм,
яши алмыйм
сөйгәнемнән башка мин.

Әнием сөлгесе

Әни чиккән сөлге һаман матур,
керсә дә ул иске рәвешкә,
кайвакытта аны чыгарабыз...
Бик кирәктә генә... Рәешкә...
Бизәкләрен күрер өчен генә,
тояр өчен генә җылысын...
Менә шунда мине биләп ала
сагынуның иң-иң олысы...
Битләремә каплыйм аны... Исним...
Күкрәк сөте исен тоям мин.
Зәңгәр диңгез төсле күзләремнән
яшь агызам – һич тә оялмыйм.
Яшьләремне сөртәм әни чиккән
сөлге белән... Битем киптерәм...
Сагынулар һаман диңгез кебек,
күз карасы кебек бик тирән...

Мәхәббәт мәңгелек булса да

Мәңгелек мәхәббәт булмый ул,
мәхәббәт мәңгелек булса да,
аң-җанны – үлемсез, кешене
пәйгамбәр сыйфатлы кылса да...
Мәңгелек мәхәббәт булмый ул...

Өзлексез мәхәббәт булмый ул,
мәхәббәт мәңгелек булса да...
Кешенең тормышы болгавыр –
бар киртә, бар нәфес, бусага...
Мәхәббәт өзлексез булмый ул...

Гел кайнар мәхәббәт булмый ул,
мәхәббәт кояшлы булса да...
Хистәге нурларга кайвакыт
болытлар, давыллар кул сала...
Мәхәббәт гел кайнар булмый ул...

Мәхәббәт гөнаһлы булмый ул,
гөнаһлы мәхәббәт булса да...
Утларга, бозларга салсаң да,
ул кайнар, ул гүзәл, ул садә!
Мәхәббәт гөнаһлы булмый ул!

Бәхет йолдызы

Лилиягә

Ай янында якты йолдыз...
Белмим – кемнең йолдызы...
Күз нурымның йолдызга һәм
кирегә – юлы озын...

Бер гомер генә җитәрме
шунысын ачыкларга?..
Һәм ачыклау кирәк микән
янында Бәхет барда?!

Йолдызга очкан күз нурым
кайчан кайтыр чагылып?
Ләкин ул үзгәртә алмас
минем шушы чагымны:

мин беркемне дә көтмимен,
сагынмыйм беркемне дә,
чөнки мин – Ай, ә син йолдыз
минем күңел күгендә...

* * *

Туган көнендә хатын-кыз
тагын бераз картая...
Ир-ат та үзгәрми калмый –
ул бераз олыгая...

Ел саен безне үзгәртеп,
гомерләр шаулап үтә –
хатын-кыз картая... Ир-ат
картаймый үлеп китә...

Мәхәббәттә күтәрелү

Бер-береңә тартылу бар,
бер-береңнән этәрелү,
бер-берең биеклегенә
мәхәббәттә күтәрелү.
Шул биеклектә калу бар
соңгы кайнар сулышкача...
Шул биеклектә бәхеткә
фәрештәләр ишек ача!

PRESSA.RU

«Роза Мулланурованың хикәясен яратып укыдым. Аның китабын каян табып була?» «Сөембикә» журналы аша Роза Мулланурова иҗаты белән танышып барам. Тормышчан итеп, җаннарны кузгатырлык итеп яза...» «Роза апа хикәяләрен рәхәтләнеп укыйм...»

Редакциягә шундый хатлар килә. Озак еллар укучыларыбызны әдәби һәм тарихи язмалары, нечкә зәвыклы хикәяләре, командировкаларда йөреп язган мәкаләләре белән уйландырган, сөендергән язучы-журналист Роза Мулланурова-Камалетдинованың эзләнүләре дә, иҗат газаплары да безгә таныш һәм аңлаешлы. Хикәяләрендәге, очеркларындагы геройларын ул үзе генә түгел, без дә инде туганыбыз кебек якын итә башлыйбыз, язмышлары белән кызыксынып торабыз. Алар үзләре дә Роза апа кебек гади, кешелекле, бераз хыялый, бераз беркатлы, бераз үзсүзле...

Ә бүген Роза апаны түгәрәк гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Укучыларыбызны яңа хикәясе белән сөендерәбез!



Роза МУЛЛАНУРОВА

МИЛӘШ КАГЫ

(Хикәя)

Коега суга чыккан җирдән Фазилә кашы-күзе җимерелеп, сөмсере коелып кайтып керде. Олтанлы итегенә ябышкан бозлы кантарларны коеп, бүлмә уртасына ук узды. Чиләкләрен лапылдатып идәнгә утыртты. Суы чайпалып түгелүен абайламагандай, арткарак чигенде дә ишек яңагына сөялде. Кысылган иреннәре сизелер-сизелмәс кенә дерелди иде аның.

Учак янында кайнашкан киленнәре Зөһрә чиләкне суы кайнап беткән казанга бушатты. Буш чиләкне Фазиләнең иңендәге көянтә башына элмәкче иде дә, тегесенең усалланып фырылдавына аптырап, тукталып калды.

– Җитте! Ике аягымның берсен дә атлыйсым юк! Гарык! – бу ул инде!

– Кое янына берәрсе бүре арканлап куймагандыр ич?! Төсең качкан! – дип көлемсерәде килен. Аның шулай киная белән, төрттереп сөйләшүенә дә, ярсу холыклы Фазиләнең тиктән генә тәртәгә тибә торган гадәтенә дә күптән күнеккәннәр иде инде бу йортта. Нәкъ менә җиңгәләре кайчак берәр шаян сүз кыстырып каенсеңелне көйләп җибәрү җаен таба иде дә... Булмады бу юлы.

– Бүредән дә яманрак! Яман сүзнең йөрәккә ничек кадалуын белмисез...

– Нинди сүз тагын? Кем белән әләгешергә өлгердең? Җитез соң үзең дә!

– Сиңа көлке! Ә миңа... Үзәк-бәгырьгә кадалган сүз әле дә йөрәктә! – Фазиләнең юк-барга да кызып китә торган гадәте бер бүген генәме?! Ярсып сөйләнер, парын чыгарыр да тынычланыр дисәләр... Көянтәсен ишек янындагы урындыкка сөяп, шунда чүмәште. Буасы ерылдымыни, елап җибәрде.

Хәер, нәселләре белән кызу канлы Касыймныкылар. Гарасат кушаматы тиккә генә ябышмаган ич инде! Ә чәүчәләк Фазиләләре кайчак һәммәсен уздыра. Берәү гомер буе сер итеп саклардайны кибәк урынына очырганын сизми дә кала. Соңыннан кайтып та төшә, үкенгән чаклары күп була. Ләкин эш узган, сер тузгыган. Утыз ике теш арасыннан чыкканны кемнең җыеп ала алганы бар?! Төпчекләре Фәризәнең йөзе үзгәреп китүен, апасына ымлап, тукта яхшы чакта дияргә, нидер яшерергә теләүләрен төшенде инде Зөһрә.

– Йә, кем шулкадәр кайнатты саруыңны? Яраткан сөяләңә басты? – Җиңгәсе, хәйләкәр көлемсерәп, бу тамашаның дәвамын – кызыгын көтә. Нинди сүз икән ул? Хәер, Фазилә сер тотмас үрдәк белән бер, капчыкны төбенә кадәр селкеп, яхшы-яманны дөньяга чәчмичә туктый белми.

– Кем булсын? Шул инде! Карачутыр! Мине аңгырага исәпли. Берни белми, аңламый дип уйлыйдыр. Мәсхәрә! Бәхиллек кирәк булган аңа да!

– Нәрсә-ә?

– Әйттем ич инде, бә-хил-лек! Бәхилләшергә кермәкче! Әҗәткана!

– Уйган ишектән кем кермәс тә, кем чыкмас...

– Кереп кенә карасын! Йодрык татыйсы килсә... Мәңге онытасым юк... Житкән кыз булгач бит, артымнан егетләр көтүе белән йөри башлагач! Бер сүзе үтерде! Имеш, этиләре уҗымга йөрергә ярата. Кызы да шуңа ошамагае...

Шулчак олы якның пыялалы ишеге ачылды. Йокысызлыктан күзләре кызарган Маһирәттәләре тупсаны узмый гына Фазиләгә ым какты. Алгы бүлмәгә – әниләре янына чакыра иде ул аны. Зөһрәнең көлемсерәп:

– Аңа карап сазаган кыз булып утырып калмагансың әле. Менә дигән егетне эләктергәнсең, – дип төрттерүе йомылып калды. Ым кагучы булмаса да, килен белән Фәризә дә боларга ияреп, олы якка теркелдәде.

* * *

Олы як дигәннәре – сирәк ягылганга шактый нык суынган иркен бүлмә тып-тын. Әллә эре бизәкле челтәр пәрдәләрдән төшкән күләгә, әллә тәрәзә пыяласына сырышкан карлы абага бүлмәгә ниндидер сер, моңсулык өсти. Караңгы почмакларга, әйтерсең, шом оялаган. Әледән-әле озынча күләгәләр биешкән күк тоела. Сиздерми генә каядыр посып торган Газраил шәүләсе чагылып киткәндәй була. Эчтән нидер куырып алгандай итә, сискәндерә. Дару исе хастаханәне хәтерләткән шомлы бүлмәдән тизрәк чыгып качасы килә башлый. Йөзенә зәгъфран сарылары иңгән авыру әнкәләре түрдәге агач караватка биек итеп түшәлгән урын-җиргә сеңеп үк беткән. Балавыздан койгандай сап-сары кулы гына ак җәймә өстендә хәрәкәтсез ята.

– Әнекәйгенәм! – Фазилә, елап, юрган читенә капланды. – Бәгырькәем!

Әниләре, кинәт уянгандай сискәнеп, күзен ачты. Яңак сөяге тартышып куйды. Кызының җәймә өстенә сибелгән чәчләрен әкрен генә сыйпады.

– Сабыр, бала, сабыр! – диде дә: «Сөйлә, ни булды?» дигәнне белдереп, ым какты. Баягы ярсуы сүрелгән идеме, әнкәсенең суырылып калган төс-кыяфәте тетрәндердеме, Фазилә, ни әйтергә белми, аптырап, тәрәзәгә текәлеп торуын белде. Еллар буе кул тими яткан ак бүз, өр-яңа юрган сандыктан чыгып кәнәфи читенә кунаклаган. Бу шомлы бүлмәдән чыгып качасы, кар шыгырдатып көянтә-көянтә су ташыйсы иде хәзер. Текәлеп, барысы да аннан җавап көтә. Көтеп-көтеп тә тыны чыкмагач, әллә тавыш-гауга чыгарганы өчен оялтасы килеп, ә бәлки дәртләндерергә теләптер, Маһирәттәләре:

– Үзең тапкан карта, тарта-тарта аша, дияр иде бабаң исән булса, – дип куйды. – Әйдә, «ә»сен әйткәч, «б»есен дә әйт инде. Баягынак нәмәрсә дип тузына иең әле?! Кайсысы шулкадәр кыздырды суң каныңны?

Фазилә, ник сүз куерткanyна үкенгәндәй, калтыранган бармаклары белән юрган читен бөтерүен белде. Әллә нигә сулкылдап, авыр көрсенеп:

– Баягынак суга чыккан иием коега... – дип башлады да, туктап калды.

– Беләбез! – Киленнәре һәр сүзне келәшчә белән суырып алырдай булып аның авызына текәлгән. – Карачутырның ни дигәнен генә әйт тә...

Әниләренең йөзеннән күләгә шуып узды. Кушамат тагып, кемнедер кимсетеп сөйләшүне элек-электән өнәми иде ул.

– Кем? – диде кырыс, таләпчән тавыш белән.

– Теге... Кем инде, Мәүлидә...

– Апа диген! – дип өстәде әниләре ишетелер-ишетелмәс кенә.

– Шул Мәүлидә апа инде: «Бибисара хәл эчендә, диләр, дөресме?» – дигән була. Синең ни эшең бар, димәкче иием дә... дәшмәдем инде. Хәер, шуннан, дигәнмен икән. Ә ул: «Бәхилләшәсе ие бит, дөньяны-кы – дөньяда!» дигән була. Әҗәткана, эзең булмасын, бусагага аяк бастырмыйм... – Шулчак әнкәсенең тәмам төсе качкан, чырае сытылган йөзенә күзе төште дә, ашыгып: – Юк, юк! Анысын ук әйтмәдем! – дияргә ашыкты. – Әйтәсем бик килсә дә, телемне тешләдем. Син уйлама! Андый ук җүләр түгел ич мин. Беләсең!

– Күрше хакы – тәңре хакы, дигән борынгылар... Күрше белән ачуташлы булырга ярый рәзе? Бергә гомер иткән күрше белән шулай сөйләшәләр димени! –

Маһирәттәйнең сүз кыстыруы Фазиләне янә ярсытып җибәрде.

– И Маһирәттәй! Ни-нәрсә беләсең соң син? Арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит ич сиңа... Ә миңа... Житкән кыз булгач ишеткән сүз йөрәккә уелган! Хурлыгына ничек түздең, диең! Бака ботын кыстыргандай, өйрәтеп торма.

– Ипләп! Телеңне алай озайтма! Төн йокламый кем утыра әле әнкәгез янында? Шул түтәгез түгелме? – Сүз көрәштерүләр киленнең саруын кайната башлаган иде, ахрысы, алгы якта самавыр кайнавын сылтау итеп, чыгарга ашыкты. Артыннан ияреп кушып, тегеләргә дә кул изәде. Соң чиккә җитеп – алҗуын сиздереп әниләре күзләрен йомган иде инде.

* * *

Израп ял итәргә бик теләсә дә, күзеннән йокы качты шул әнкәләренең. Бу якты дөньяны калдырып китәсе кешенең гөнаһлы җирдә әле яшәп калачак дәвамына – газиз балаларына әйтәсе килгән сүзләре, үгет-нәсыйхәте бихисап та бит... Тыңлыйлармы, колак салалармы соң алар ачы тәҗрибә авазына? Ялгышлар ясый-ясый, абына-сөртенә үзләренчә яшәүне артык күрүләре хак-

PRESSA.RU

мы? Хәер, табигать кануны бит бу: картлар китә, яшьләр кала. Яшен яшәгән, ашын ашаган карт-корының – китәселәрнең нинди уй-гамьнәр белән бу дөньядан кичүен, әрнү-хәсрәт эчендә йөзгәнен каласылар каян белсен соң? Алар бүгенге белән яши. Үткән инде артта калган, онытылуга дучар ителгән дип уйлый алар. Ә бәлки уйлап мәшәкатьләнмиләрдер?! Алар күзлегеннән, киләчәк әле ерак. Киләчәк – чәчәк тотып киләчәк! Шуңа ышана адәм баласы.

Ә китәселәрнең үгет-нәсыйхәт биреп, үзләре ышанган, табынганны мирас итеп калдырасы килә. Килә дә бит... Ата малы белән бала көн күрмәс, дигән борынгылар. Мирас итеп калдырырлык малы бармы? Булган кадәресен дә әрәм-шәрәм итеп, чәчеп, туздырып бетерергә күп сорамый яшьләр. Чөнки... үзең казганган җир кадерле, үз көчең белән эшләп тапкан мал бәрәкәтле. Бәхетне аны берәү дә, беркайчан, беркемгә әҗәткә биреп тормый!

Алгы якта Фазиләнең: «Моңарчы кеше көлдерүләре дә бик җиткән. Әни гомер буе түзде, без оялып яшәдек», – дип чәпчүен дә, Мәһирә түтәләренең: «Аңа карап укаң коелмаган! Тату яшәделәр! Тату яшәүдән дә көлсәләр! Көлке көлә килә, артыңнан куа килә. Көләсе көлеп туйгандыр!» – диюен дә – һәммәсен ишетеп ята бит ул. Дөньяныкы – дөньялыкта! Чынлыкта, Мәүлидә бик хикмәтле сүз әйткән түгелме соң?! Ә ул үзе кызларына ни әйтмәкче иде соң әле? «Без китәсе, сез әле каласы. Сер тулы бу дөньяда мәңгелек канун бар: авызың тулы кара кан булса да, кеше алдында төкермә», – диярга теләгән иде түгелме? Күргән-кичергәннәрне аңлар, төшенер өчен зиһенегез, акылыгыз җитәрме икән?» – дисә... Күрмәгәнгә күрсәтмәсен, күргәннәргә күркәм сабырлык бирсен, дип акыл өйрәтә башласа... Яратмый шул замана яшьләре вәгазь укыганны, өйрәтмә, дип кенә җибәрәләр. Әнә, кызы да тутәсенә: «Бака ботын кыстыргандай...» дип торган була ич.

Тәүбә, тәүбә... Балаларына үпкәләрлек, рәнҗерлек сәбәп юк югыйсә. Кемнеке – аныкы дигәндә, берсе өчен дә йөзе кызарырлык булмады. Авырлык белән булса да тормышта һәркайсы үз юлын тапты. Эшләре бар, баш очында түбә... Тагын ни кирәк? Җан тынычлыгы! Шунысы гына җитенкерәми, ахры, замана яшьләренә. Муллаяны исән булса: «Әй син! Борсаланмый ят тыныч кына, Газраил килеп җиткәнен көтеп. Ничек кенә күңеләңне күрергә белми йөгерешеп йөриләр ич!» – дияр идеме?! Фәризәсе, әнә, Себер кадәр Себердән кайтып җиткән. Фазиләсе ярсучан, чәүчәләк инде. Нишләтәсең аны... Гомергә шундый булды. Арада бер холыксызы булмый калмый шул. Хәер, бүтәннәре күркәм холыклы булса, бер тырбызык араларына сыяр иде ничек тә... Бәлки үзендәдер гаеп. Һәммәсен йөрәгенә җыйды. Алай ярый рәзе?! Фазиләгә йөкле иде. Шул чакта кичергәннәре сабый йөрәгенә эз салган булса? Булмас димә!

* * *

Күрше Мәүлидәнең Сабирҗаны белән Касыймнарның Муллаяны сугышка бер көнне, бер атка утырып чыгып киткән иде бит. Өч елдан артык ут эчендә, сугышта йөреп Муллаян авылга кайтып төште. Яраланып, михнәт чигеп, нык бетәшеп, әмма үз аягында кайтып керде. Ә Сабирҗан әйләнеп кайтмады. Суга төшкән кебек юкка чыкты – хәбәрсез югалды. Кара кәгазь генә килде. Нишлисең, үз иркендә түгел шул яугир. Өч бала белән яшь көе ятим калган күрше Мәүлидәне жәлләп и елаган иде Бибисара. Жәлләмичә! Авылда бер чибәр иде ич Мәүлидә. Сабирҗаны – егет солтаны! Клубта театр куеп – Хәлил белән Галиябану булып уйнап, халыкны шаккаттырган, елаткан чаклары, ул җырлаулары, дисеңме! Бер-берсенә тиң яр, дип тормады, очты бәхет кошы. Койрыгына ябышып, саклап кала алмыйсың. Оча да югала икән...


Кичке шәфәкъ сүнеп барганга ифрат серле тоелган, карлы-сыкылы абага яфраклары тоныклана төшкән тәрәзәгә күз текәп, үз уйларына чумып ята ул менә. Сугыш чорында үпкәне куырган суык төзәлмәс чиргә әйләнде бугай. Китмәскә... алып китәргә, ахры, исәбе. Көннәр язга авышканда китеп барасы килми бит әле! Күп тә үтмәс, карлы абагалар эреп агар. Кояш елмаер, тып-тып тамчы тамар. Ярсып-дулап ташу агар. Бакча ак чәчкәгә күмелгәндә ни җаның белән тыныч кына ятмак кирәк? Якты дөнья ансыз ятим кала ич. Язын тәрәзә йөзлегенә, өй кыегына оя корырга гадәтләнгән карлыгачлар юксыныр ич аны. Хәтерсез, чит-ят сыерчыклар килерме? Шомыртларның ак бөркәнчек ябынган кәләшсыман назланып утырган мәлен бигрәк ярата шул! Тирә-якта выж-выж килеп йөзләгән бал корты, төклетуралар оча. Аннан миләш-кәләш актан киенә. Дөньяга ямь биреп, балкып утырган мәле – җирдәге оҗмах ич! Хәер, бар да үтә, үзгәрә. Миләш чәчәген коя. Яшькелт җимшән бөртә. Кызыл күлмәк ничек килешә аңа! «Миләшкәем, миләшкәем, нигә ачы җимешкәең» дип җырлый кыз-кыркын. Җырласалар ни! Радиодан ишетеп калганнардыр. Шифасын, тәмен белмәгәннәргә ачы ул. Өй түрендәге агачны җимешле диюеннән юкка көлә бала-чага. Миләш кенә димәссең бер дә! Аның өчен татлы җимеш, авыр чакларында савыктыргыч дәва булды бит ул. Җан дәвасы, йөрәгенә шифа! Аларныкы кебек мул җимешле миләш агачы авылда бүтән юк. Кешеләргә дә җитә, кош-корт та тук, тавык-чебеш, каз-үрдәк тә.

Тымызык тынлыкта оеп ята торгач, әллә төшләнә башлады инде. Кемдер «Мәүлидә!» дип дәшкәндәй булды. «Мәүлидә», дип, әллә үзе саташа тагын?

Ул яткан җирдән торып ук утырды. Кара инде, бер урамда чапырыш күрше булып яшәп тә, кемнең ишеге кайсы якка ачылганын белми яшәгәннәр, диген, ә?! Алай да була икән! Ә бит дөньяныкы – дөньялыкта диюләре хак!

* * *

Ә ул чакта... Кояшлы яз башы иде. Йомышы төшеп, идарәгә керәсе итте ул. Чут төймәсе тартып утырган сипкелле Мәрзия, эшен ташлап, аңа текәлде. Кап-кара күзләренең утлы карашыннан әллә нишләп, куырылып китүе истә. Шулкадәр төбәлеп-текәлеп карамаса! Иртән



мич ягып томалаган, ипи салган иде, битенә корым-мазар ягылып калмагандыр бит? Почмактагы чебен бизәп бетергән көзгегә күз ташлады: яулык читеннән бүселеп чыккан чәч алкасын рәтләде. Артык борчылырлык берни күзенә чалынмады. Чиста ак йөзе балкып, бите чак кына алсуланып тора. Аптырагач, үзе үк сорыйсы итте:

– Кызлар, нигә болай сәер итеп карыйсыз?

– Яратып инде. Яратып кына...

– Ә мин тагын ул-бу булганмы дип, курка калдым.

– Бездән курыкма син, апа, – диде хисапчы Мөнирә авыр сулаган булып. – Күршеңнән курык... Көндәш ачысы – яман, дигән сүз бар ич. Беләсеңдер...

«Нәрсәне?» – дип сорарга ачкан авызы йомылмыйча калды, җыештыручы Халисә апалары чиләгән ачу белән дөбердәтеп идәнгә куйды.

– Кеше ышандырып, җыен тузга язмаганны такылдап утырмагызсана! Ышанма дошман сүзенә! Боларның эше беткән, кеше тикшерәсе генә калган.

– Ышанды, ди... Юк ла, – дигән булды Бибисара. Ә үзенең эченә ут йөгерде. Утсыз төтен булмый, диләр бит... Бәлки, чыннан да хактыр... «Ялган! Юк!» – дип тәкрарлады ул, абына-сөртенә өенә кайтып җиткәнче. Кайтып җитте һәм бусагадан атлауга кискән агач кебек идәнгә ауды. Нәкъ менә Фазиләсенә – икенчесенә авырлы икәнен шунда белде. Йөкле икәнен белмәсә, бәлки, бер-бер эш тә кылган булыр иде. Ихтимал, шул бала – туачак сабые тотып калгандыр да әле аны. Ялгыш адымнардан саклагандыр.

Мәүлидәне чын күңелдән кызгана иде ул. Тол хатыннарга тигән әз-мәз яклау да урап узды аны. Ил-көн каршында алар да – хәбәрсез югалганнарның гаиләсе дә гаепле гүяки. «Сатылгандыр!» «Бәлки, ул анда... теге якта газап-михнәт күрмидер?» Сөйлиләр, берәүнең дә авызына яулык каплап булмый. Берсеннән-берсе вак өч баласын, тормыш йөген сөйрәп өшәнгән Мәүлидәгә ничек кыен икәнен кем генә аңлый соң? Кеше кайгысы – кештәктә. Уфалла арбасына җигелеп утын-печән ташыйлар, сабыйларның көче җитми. Көндезге чәйгә кайткан иренә дә күршесенең аяныч хәлен аңлатырга тели ул.

– Карале, сиңайтәм, көн дә ат җигәсең. Кайтарып аудар шуларга бер йөк утын. Сабирҗан хакына. Бергә чыгып киттегез. Ул кайтмады. Аның да хакы бардыр! –

Ире дәшми-тынмый тыңлый – «ә?» дә дими, «җә!» дә дими. «Вакыт юк әле» дисә дә, колагына керә, йә утыннарын тиз-тиз ярып ташлый яки печәннәрен абзар түбәсенә ыргытырга булыша. Кулы калмый ич. Күрше хакы – Тәңре хакы, дигәне дә бар бит әле аның. Күрше күршегә терәк булып, ярдәмләшеп яшәргә тырыша иде ул чакта. Сугыш елларындагы ачлык, юклык, җан әрнүләре әле басылмаган. Кешеләр ихлас, ярдәмчел иде.

Аның изге нияттән кылган гамәлен – күршегә ярдәм ит, дип, ирен үзе үгетләвен кем белде соң? Гайбәтчегә барыбер ич. Тапканнар: «уҗым», имеш!

Карт миләш агачын кочаклап елады да әрнүләрен эчкә йотты Бибисара-бичара. Төтеннең кайсы яктан күтәрелгәнен тикшереп, әрләшеп йөрү ят иде холкына. Ә кем белә? Нидер булгандыр бәлки. Гаиләсен ташлап чыгып китсә дә, ни кылыр идең? Йортны таркатмады, чыгып китмәде Муллаян. Балалары әтиле булып үсте. Сугыш тегермәне изгән, канлы өермәдән исән-сау котылып кайта алган ир затлары авылда гынамы,

PRESSA.RU

илдә-көндә санаулы заман иде бит ул. Ә шул чакта даулашып, ямьсезләнеп йөрсәме?.. Ни-нәрсәгә ирешер иде икән? Балалар нишләр? Теләсә кемне каратырдай матурлыгы белән ялгыз гомер кичерде чибәр Мәүлидә дә. Кем белә, Муллаян да ул кадәр үк сөттән ак, судан пакь булмагандыр. Таң атканда гына кайтып кергән чагын хәтерли әле ул аның. Йоклаганга салышып ятса да, ишетте, уфтанганын да, баланың өстенә япкан булып текәлеп карап торганын да... Калыйммы-юкмы дип ачыргалангандыр. Мәүлидә, теләсә, үз ягына аударган булыр иде аны. Акылы җитте, гаиләне җимермәде. Муллаян гайрәтле, үзсүзле һәм гаярь, әгәр кыек-мыек сүз белән бәйләнә башласаң, холкын күрсәтер. Кадерле иде ир затлары!

Ә эчтә, әнисенең хәсрәт-борчуын аңлагандай, сабые тибенде – Фазиләсе.

Әй, шул елны ул ашаган миләш! «Үтең сытылырлык ачы ашап тешең дә камашмый икән дә, ничек тамагыңнан үтә?» – әнисендә сорау бихисап. Гаҗәпләнә, әмма кызының хәл-халәтен аңлый алмый йөди. Уңып та күрсәтте соң ул елны миләш! Ачыларын сыга-сыга как коярга гадәтләнде ул. Шуннан шифа тапкандай булды. Ә сердәш-миләш агачы өй кыекларын узып, буйга үсте. «Кемгә хаҗәт ачы миләш, кисеп кенә ташлыйк!» – дип балта кайраучы да аз булмады. Үсә төшкәч, улы да каныкты: күләгәсе генә, имеш... Сезгә тансык булмагач та... кирәксез дигән сүз түгел ич. Кошлар рәхәтләнеп ашый аны, дип, яклады, кистермәде. «Син койган как авызга тәм кертә», – дип, кем генә сорап килмәде миләш кагын. Карасана, онытылган! Торадыр әле имгә – даруга дигән кагы! Шуның белән тирли-тирли чәй эчсәме?! Мәүлидә белән гөрләшеп чәй эчсәләр... Тәм керсен әле авызларга! Бөрешеп ятарга теге!

Гаҗәп хәл, кинәт кенә җиңеләеп, юрганны читкә алып, торып басты. Кермәгән Мәүлидәне көтеп утырсынмыни? Тау Мөхәммәдкә каршы килмәсә, Мөхәммәд үзе тауга барыр, диләрме?! Тотар да үзе килеп керер ул аларга! Урам аша чыкканчы адашмас. Тегеләй ит, болай, дип, кеше өйрәтеп яисә иргә боерык биреп – тоҗырып утыру гына түгел бит ул: дөнья көтү дигәннәр аны. Сора, ела, ялвар – Муллаяны барыбер ишетми инде аны хәзер. Унынчы елын мәңгелек йортында – яралары сызлап интектерде, тынычлангандыр...

– Әнкәй! – Ишектән башын тыккан төпчеге Фәризәнең үзенә бер нурлы елмаю белән балкып, шатланып та, куркып та аваз салуы айнытып җибәрде.

– Кызым! Ачы тели күңелем, как телим! Төргәге белән суыткычның иң аскы тартмасында ятадыр. Чәй куй, Мәүлидә апаңа дәш... Авызга тәм керсен.

– Йөгердем, әнкәй. Лимон, как – авызга тәм кертә ул! – Фәризәнең шатлыктан балкыган йөзе пыялалы ишек артында эрергә өлгермәде, Фазиләсе килеп керде. Ишек төбендә туктап, еламсырап көйләргә тотынды:

– Әнкәй! Борчыган булсам, кичер, әнкәй! Күп борчу, хәсрәт китердем...

Әнисенең мәрхәмәтле күз карашын тоеп кыюланды, түргә узды. Күзләре кызарган, йөзе агарынып киткән. Шундый инде ул, юктан да шатлана-көлә, ис китмәслек сүзгә дә хәтере калып, җен майлары түгеп елый. Артык нечкә күңелле, рәнҗүчән... Тумыштан ук сәеррәк, күз яшьле, елак булды бу кызы, нишлисең? Сәбәпләре... бар инде. Эш-мәшәкатькә күмелеп, иркә-назларын һәркайсына тигез бирә алмавы да хак. Көйсез тамгасы суктылар да... Этеп-төртеп кенә тормадылар торуын, тик шулай да... Һаман әрләү, акыл өйрәтү кемне бәхетлерәк иткән соң? Моң-сагышлары карындагы нарасыйга зыян салмагае дип һафалану, җаны яралы булганга әрнеп кызгануы эзсез узамыни.

– Иркә песиемдер лә минем. Килче, бер сөйим әле үзеңне! – Әнкәсенә сырышты, сырт кабартып тормады кызы. Ул аны, сиздермәскә теләп, яшереп кенә артыграк та яратты бугай. Әйтәсе сүз күз яше булып тамакка тыгылган.

– Кызым, кичер, кырыс булдым. Гел гадел дә була алмаганмындыр.

– Син түгел, мин гафу сорарга тиеш, әнкәй... Бүгенгесе өчен генә түгел. Үткәнне кайтарып булса икән? Ире әйбәт, эше җиңел, рәхәт яши, диләр мине. Бер карагандa, алар хаклы. Эш бар, йорт, ир... Күңел генә китек.

– Бала – бәхет, дибез дә бит, кемдер, бәласеннән – башаяк, дип тә юана.

– Юатма, әнкәй. Кирәкми. Үз хәлемне үзем беләм ич мин. Үзем гаепле. «Мәүлидә башкисәреннән ерак йөре», дип кисәткәнеңне хәтерлисеңме икән? Колакка элмәдем. Яраттым шул. Данил да ярата иде мине. Авыл хуҗалыгы техникумына укырга кердек тә, качып киттек. Өйләнешәбез, дип хыяллана идек. Әнкәсе аяк терәп каршы торды. Мин – бәхетсез, Данил да харап булды.

– Тормыш катлаулы, кызым. Кайсыбыз хаклы, нәрсәнең хата икәнен бер Хода белә. Зарланма да, үкенмә дә. Нәҗип кияү – бер дигән. Көеңә генә тора.

– Ул мине кызганып... юк ла, яратып өйләнде. Ә мин... Данилга үч итеп... Әнисе итәгенә тагылган – җебегән, дип, чынлыкта, ачу итеп, тоттым да беренче очраган егеткә – Нәҗипкә кияүгә чыктым. И-и, ник сөйләп торам, ахырын беләсең ич, – диде. – Хыянәтне кичерә алмады, үзе теләп ут эченә Чечняга китеп барды Данил. Һәм башын салды. Белсәң... – Фазилә, әрнепөзгәләнеп эч серен түкте-түкте дә тынып калды.

Караңгыланган йортта әле ут алмаганнар. Алгы яктагылар дөнья мәшәкатьләре белән артыграк мәшгуль, күрәсең. Маһирәттәләре башын мендәргә төрткәндер дә, йокымсырап киткәндер.

– Белсәң, үзәк-бавырларыма кадәр көйдерде, кара күмер итте шул ут. Шуңа күрә күкрәгемә кысып сөярлек балам юктыр... Чөнки барысы янган, көйгән. Үземне жәлләмим, Нәҗип кызганыч. Нәселе калмый. Кит, дим дә...

– Ялгышма, бала. Ярата ул сине. Ярату хакына барсын да кичереп була.

Фазиләнең йөзе ачылып китте, күзендә очкын кабынды. Уе-күңеле белән һаман да кое янында гүяки:

– Дөньянкы – дөньялыкта! Чыннан да, хикмәтле сүз бит, әйеме, әнкәй!

Асия
ЮНЫСОВА

САВАПЛЫ ГАМӘЛ БИСМИЛЛАСЫЗ БУЛМЫЙ, ДИЛӘР. ГАИЛӘ КОРУ, КАВЫШУ КЕБЕК ЭШЛӘР ДӘ МӘХӘББӘТСЕЗ БУЛСА, ХӘЕРЛЕ ГАМӘЛ САНАЛМЫЙ ТОРГАНДЫР УЛ.

БҮЛӘК

Сәрия – башлангыч сыйныфлар укытучысы. Бала-чаганы бик ярата. Һәрхәлдә, мәгълүм бер очракка кадәр яратам дип белә иде. Бер көнне өченчеләренә, өйгә эш итеп, казлар тормышыннан бер хикәя укып килергә кушты. Икенче дәрестә биремнең үтәлү-үтәлмәвен тикшерде. Сорауларыгыз бармы, дигән булды. Бар икән сораулары. Мең дә берне белә торган шук малай бар аның сыйныфында. Шул сорап куйды: «Апа, мин укыдым хикәяне. Апа, «дуадак» дигән сүз бар анда. Ни дигән сүз ул?»

Сәрия, аны-моны уйламый гына, аңлатып бирде. «Бәбкәсез ана казны шулай диләр ул, балалар». Икенче дәрескә кергәндә кара тактада язу күреп аһ итте: «Безнең апа Дуадак каз». Сәрия аны-моны сиздермәде. Тугыз яшьлек балаларның уендагы – телендә, ни әйтер хәлең дә юк. Дежур укучыдан тактаны сөрттерде дә дәресен дәвам итте. Югыйсә эче-тышы ялкын иде. Язган бала, кем икәнен язуыннан таныды анысы, иң авырткан җиренә ук кадаган иде. Кай арада белеп өлгергәннәр диген – Мәхәсим кичә кич кенә чыгып китте бит. Бөтенләйгә китте. «Бәбәй китермәгән хатын белән гомер әрәм итмим», – диде киткәндә. Димәк, Сәрия чыннан да дуадак!

Сәриянең язмышы тормышның бер кәмите инде. Мәхәсимнең Сәриягә өйләнәсен белгәч, кайнана булачак Мәрфугаттәй сүз ишеттергән иде: «Нәселләре әллә кем түгел дә инде. Кызның көмәне бар икән. Шуңа күрә генә алабыз», – дигән ди. Туйлар узып, билгеле вакыт үтүгә авыл, ашыгып, туачак сабыйны көтте. Тик бәби дигән кадерле зат тугыз айдан да, бер елдан да, ике, өч елдан соң да тумады. Инде менә



ир заты да ташлап китте. Гомергә шулай дуадак каз язмышы язган микәнни Сәриягә? Шушы хәлдән соң яшь укытучы мәктәптән бизде. Бала-чага чыр-чуы гына булса – бер хәл. Аларның синең язмышыңны, яшәү рәвешеңне мыскалга салып үлчәп торулары үзәккә үтә.

Сәрия бер карарга килде. Бар акчасын барлап, әнисенең маясын да кушып, район үзәгендә лавка ачып җибәрде. Вак-төяк белән сату итә башлады. Монда сине тәгаенләп белүче, йөз ертучы сирәк. Ә базар тормышы үзенә күрә бер кызык. Әнә, күршедә генә әзәрбайҗан егете Сабирхан йөзем сата. Алучысы югында Сәрия белән дә сөйләшә. Бу чибәр егет татлы телле, ярдәмчел, юмарт. Чыннан да, Сәрия аның ярдәмен күп күрде. Егет машиналы иде. Еш кына яшь хатынны авылына да кайтарып куйгалый. Үзе бер дә әрсез түгел. Аның авызыннан «гыйшкым», «сәүгәлем» кебек сүзләр ишетелгәндә Сәрия оялып китә иде. Тора-бара ияләште. Ияләшү генә түгел, яратып та китте. Хисләр егеттә дә кабынган иде. Тиздән никах укылды. Матур яшәп киттеләр. Сабирханның ниндидер сере бар иде кебек. Үзе генә калдым дип уйлаганда елап та алгалый. Сәрия чамалый иде ул сернең ниндилеген. Тик фаразын тел тибрәтеп әйтергә кыймый иде. Ничек әйтәсең, үз-үзеннән дә яшерә бит ул аны. Сабирхан да өзгәләнә кебек. Сәриянең буйга узганын белгәч, кияү кеше ачылды: «Үз илемдә гаиләм бар минем. Кайтып килим. Анда араларны өзим. Мин сине бик яратам, гыйшкым минем. Сине ташламыйм мин. Кайтам да бик тиз урап киләм».

Сәрия җибәрде Сабирханны. Ә ул китте дә югалды. Сәрия бик матур кыз бала тапты. Аңа Нәүрүзгөл дигән исем кушты. Сабирханга үпкә сакламады. Аңа болай да зур рәхмәт! Сәрияне дуадаклыктан коткарган өчен! Гомергә җитәрлек кадерле бүләге өчен!

Кызы бик матур булып үсеп килә Сәриянең. Кызы туган көздә үк ул янәдән мәктәпкә әйләнеп кайтты. Янәдән балаларны ярата башлады. Үз балаң булгач, бөтен бала-чагага карата мәхәббәт туа икән ул. Акыллы, эшчән, күркәм Сәрияне тагын кияүгә димләүчеләр табылды. «Кызың үсәр дә чыгып китәр, ялгыз калма», – диде инәкәе. Авылда ялгыз дөнья көтү җиңел түгел. Ризалашты Сәрия – Хәмитне йортка кертте. Әйбәт кеше булып чыкты ул. Нәүрүзгөлне дә яратты, Сәриянең элекке ирләрен искә төшереп, ярасына тоз салып та газапламады. Тик аның да үз баласын сөясе килә икән. Ә бала дигән бүләк тагын юк. Өч елдан ирнең бусы да китте. Бала таба алырдай хатын эзлим, диде. Аптыраган дөньяның бу хикмәтенә – ни өчен бер бала табып күрсәткән хатын бу ирне дә куандыра алмый икән соң? Сәрия сәбәбен белә кебек. Арада Сабирханны гына өзелеп яратты бит ул. Күрәсең, бала мәхәббәттән генә ярала торгандыр.

PRESSA.RU



Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ шигыре,
Хөснул ВӘЛИУЛЛИН көе.

Кораб китте еракларга,
зур юлларга,
Карыйм күздән югалганчы
шул якларга.
Сез китмәгез, акчарлаклар,
акчарлаклар,
Чит җирләрдә каерыла
пар канатлар.

Мәхәббәтне ала алмый
бер упкын да,
Хыянәтне күтәралмый
бер дулкын да.
Сез китмәгез, акчарлаклар,
акчарлаклар,
Кавышуны вәгъдә итә
пар канатлар.

Сөйгән ярым китеп барды
кулын болгап,
Кайтыр микән тагын миңа
юллар урап?
Сау булыгыз, акчарлаклар,
акчарлаклар,
Мәхәббәткә кирәк икән
пар канатлар.

БӨРЕДӘ КАЛГАН МӘХӘББӘТ

Нечкә күңелле, батыр йөрәкле Шагыйрь иде ул. Җаны халыкка тоташкан шагыйрьне Идел акчарлагына һәм зур корабка тиңләп булыр иде. Кораб китте...

Озын гомерле, халык йөрәгенә кергән җырлар дигәндә шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов шигыренә композитор Хөснул Вәлиуллин көй язган «Акчарлаклар» җыры кабат-кабат хәтердә яңара. Без яшь чакта туган, кадерле истәлекләргә бай булгангамы, ул җыр күңелләргә мәңге онытылмаслык булып уелып калган. Рәшит-сабакташ белән бергә әле кайчан гына Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә имтиханнар биреп йөргән идек. Солдат каешы буган, дөнья күрергә өлгергән егетләрнең берсе – Рәшит Әхмәтҗанов безне – мәктәптән генә килеп, гыйлем йортына аяк баскан, унсигезәр яшьлек кызкыркынны бер күрүдә гашыйк итте дисәм дә, арттыру булмастыр. Какча гәүдәле, ягымлы зур күзле, йөрәккә үтәрлек үткен карашлы, мөлаем егет иде ул. Армия «бүләге» – чәче сирәкләнеп коела башлавы олысымак кыяфәт бирә, хөрмәтләп «абый» дип йөртәбез. Укый башлауга – сентябрь башларында ук беренче, икенче курс студентларын колхозга ярдәмгә – бәрәңге алышырга озату гадәте бар иде. Ютазы ягындагы Бәйрәкә Тамак авылына килеп урнашуыбыз истә әле. Юньләп бер-беребезне белмәсәк тә, «безнекеләр» дигән тылсымлы сүз телдә. Арып-талып, кырда эшләп кайтабыз да, юынып, чәйләп алуга клубка ашыгабыз. Студент

халкын зарыгып көтәләр. Концерт, спектакльләр әзерләү, авыл халкына ял кичәләре оештыру безгә йөкләнгән күңелле гамәл ич. Арабызда атказанган артистларының уздырырлык шәп гармунчы да бар, җырчы-биючеләр дә байтак. Ә шагыйрь егетебез – Рәшитебез үзе генә дә ни тора! Ялкынланып шигырь укый башласа, зал тып-тын кала. Шул чакта ук танылган шагыйрь иде инде ул. Дус-ишне сөендереп, Рәшитнең тәүге – «Хыялларым үзем белән» дигән җыентыгы китап нәшриятында дөнья күрде. Кызыктырып һәм сөендереп диюем арттыру түгел, чөнки татар бүлегенә кергәннәрнең күбесе каләм тибрәтә, язучы булырга хыяллана, хикәя-шигырьләре инде республика матбугатында күренгәли торган сәләтле яшьләр бит. 1969 елда диплом алган төркемдә илгә-көнгә билгеле, танылган шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Клара Булатова, Харрас Әюпов, Рәшит Ягъфәров, прозаиклар Флүс Латыйфи, Роза Зәйнуллина-Туфитуллова, Равил Вәли, Сәгыйдулла Хафизов, Ләлә Сабирова, Роза Мулланурова, ягъни мин фәкыйрегез дә булу күпне сөйли. Язучы-журналист Роза Туфитуллова «Ялкын», «Азат хатын»–«Сөембикә» журналларының баш мөхәррире, Татарстан Дәүләт Советы депутаты булды. Ләлә Сабирова-Гыймадиева байтак еллар «Сабантуй» газетасын җитәкләде.

Колхоз басуын, кичке уеннарны искә төшерүем очраклы түгел. Мәшһүр «Акчарлаклар» җырының яралгысы шул чакта ук борын төрткәндер дип ышанам. Авыл яшьләре студент туташларны озаткаларга атлыгып торса да, безне җил дә тидерми саклап йөртүче «абыйлар» бар: кырда булсын, клубтан кайтышлыйммы, фатир ишегенә кадәр озатып куялар. Чит-ятларга сүз кушу кая! Үткән еллар хатирәсен барлап утырганда Ләлә дус искә төшергәне истә: «Клубтан чыктык кына, Рәшит култыклап алды. И ашыктыра, и җилтерәтә бу мине. Аягымнан чүәгем төшеп кала язды. Кая ашыктыра дисәм… алдарак гармунчы егетебез Роза Зәйнуллина белән сөйләшеп кайтып килә икән. Аңладым серен: муеннан Розага гашыйк Рәшитем».

Шагыйрь мәхәббәте үзе тылсым, үзе сер ул. Әмма иҗатка рухландыручы, илһам бирүче Муза – гашыйк иткән кызны без белмибезме инде?! Сылу, чибәр Аксубай кызына без дә аның күзе белән карый башладык бугай. Роза Зәйнуллина имтиханнарын гел «бишле»гә бирде. Әбисе, әнисе, апаларына кадәр һәммәсе мөгаллимнәр, шуңамы аның үз-үзен тотышы да, төскыяфәте дә үзгәрәк. Аңардан зыялылык, затлылык хуш ис сыман бөркелеп тора. Зәвыклы. Ә елмаюы… җанны эретә. Шагыйрь күңелен шундый гүзәл зат җәлеп итүе бик тә табигый. Рәшит туташның күңелен яулау өчен бишкә ярылыр иде: шигырь арты шигырь багышлый. Әмма… Әллә туташның яшь булуы, ә бәлки Рәшитнең, хәзерге тел белән әйтсәк, публичный кешегә әйләнүе дә тәэсир иткәндер. Ихтимал, сербирмәс туташны көнләштерәсе килеп, шагыйрьнең башкаларга да күз аткалавы роль уйнагандыр, серле бу мәхәббәт бөредә килеш калды. Бөредә һәм җырда. Ә җыр туу үзе могҗиза бит ул. «Ике көннән радиодан абзагызның җыры яңгырар. Нәумиз булып, ишетми калмагыз» дип, Рәшит үзе хәбәр итте. Безнең, мәхәббәт җырыдыр әле диюебезгә, серле елмаеп: «Мәхәббәт ул минем җанда, минем башта, / Минем канда яшеренгән… Түгәсе бар күпме яшьләр, / Сөю миндә күпме яшәр – / Йә, кем белгән?» – дип шигырьгә күчте. Өстәде: «Акчарлаклар» дигән җыр ул… Хикмәт, нәкь менә Пушкинча килеп чыкты. «Светла моя печаль…»

«Акчарлаклар» җыры – кабатланмас яшьлек еллары хатирәсе дә, шагыйрьнең саф хисләре, садә мәхәббәте, җаннан китмәс моң булып та безнең йөрәкләрдә яши.

Шәриф Камал әсәре буенча куелган «Акчарлаклар» спектаклендә бизәде бу җыр. Шагыйрьнең йөрәк сере җырга күчте: «Мәхәббәткә кирәк икән пар канатлар!»

«Без яшәгән еллар давылында / Сиңа гашыйк көнем югалган» дип язса да, яшьлек таңында тамырланган саф мәхәббәте Рәшит күңелендә соңгы сулышкача саклангандыр дип уйлыйм. Безнең баш мөхәррир Роза Туфитуллованың үзе, эше, гаиләсе турында җылы сүз ишетү бәйрәм була иде аңа. Тансыклап, «Сөембикә»гә – безнең бүлмәгә еш керә иде ул. Рухланып, без инде ничә тыңласак та туймый, ялыкмый торган шигырьләрен укудан ләззәт ала: «Их, бу җирне күпме таптады / Безнең йөрәк бәйрәмнәренең / Кыңгыраулар таккан атлары!» Киң колачлы, иҗаты киләчәк буыннарны да шатландырырлык шәп шагыйрь безнең сабакташыбыз.


Якты сагышлы, нурлы иде аның шигъри дөньясы. Күңелендә саклаган сөю хисе дә якты, нурлы, шуның нуры хәтта дусларына да төшә. Югыйсә Рәшитнең тормышын көйсез дип булмый: аны хөрмәт итә торган табибә Луизаны яр итүе, «минем блондиным» дип йөртә торган ак йөзле улы Айдарны, чибәр кызы Ләйләне, оныкларын ихлас яратуы хак иде аның. «Сандугач керде күңелгә, җырламый түзиммени?» дип ялкынланып, әдәбиятта тәнкыйтьчеләр түтәл-түтәл итеп санап йөртә торган исемлекләргә сыймый, үзе бер дөнья булып яшәде, иҗат итте ул. 1991 елның эссе августында, Татарстанга мөстәкыйльлек яулау өчен көрәш кызган көннәрдә, ул, Фәүзия Бәйрәмовалар белән бергә, эссе кояш астында ундүрт көн ачлык тотты. «Ачлык мәйданы»н – тетрәндергеч поэманы язды.

Рәшит Әхмәтҗанов Тукай туган айда – 14 апрельдә Баулы районы Татар Кандызы авылында дөньяга килгән. Даһиебыз сыман ул да милләт гамен, рухи кыйммәтләрне халык йөрәгенә җиткерергә теләп, гамьле уй-хисләр ялкынында бәгырен өтә-өтә иҗат итте. Иртәрәк китте. Мәңгелек йортта – зираттагы урыны да Тукай янәшәсендә. Уйлап карасаң, монысы да бер хикмәт бит!

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

PRESSA.RU

КҮРШЕ АВЫЛГА КИЛЕН БУЛЫП ТӨШТЕМ. ӘЙБӘТ КЕНӘ ЯШӘП КИТТЕК. УЛ МИНЕ ЯРАТЫП, СӨЕП КЕНӘ ТОРДЫ. НИ ӘЙТСӘМ, ШУНЫ ҮТӘДЕ. ТИК БУ БӘХЕТ ОЗАККА БАРМАДЫ.



ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ



Флёра
ТАРХАНОВА

Фильм беткәннән соң, кызлар-егетләр, йөгерешә-йөгерешә, эскәмия-утыргычларны бер якка җыеп, бию урыны әзерләдек. Түгәрәк әзер булгач, беренче булып гармунчыбыз килеп утырды, сыздырып уйнап та җибәрде. Без, кызлар, егетләрнең биюгә чакырганын көтәбез. Шулчак ишек ачылып китте дә, төз гәүдәле, шактый сөйкемле егет килеп керде. Клубка кереп басуга, барыбызга да күз йөртеп чыкты. Күзләре миндә тукталды, яныма килеп утырды. Күрше авыл егете Илсур иде бу. Армиядән кайткан. Безнең авылга кызлар күзләргә төшкән икән. Танышып киттек. Дүрт ай йөрде артымнан. Ә мин, авылда каласым килмичә, Казанга китәргә уйлап йөрим. 8 Март бәйрәмендә бер бәйләм чәчәк күтәреп килде бу. Моңарчы андый нәрсәне күрмәгәнгә, аның шушы игътибары минем күңелемне кузгатты, һәм аңа икенче төрлерәк карый башладым. Шул көннән йөреп киттек. Әтием аны ошатмады. Аңа кияүгә бирергә теләмәде. Мин ике ут арасында калдым.

Алай да без өйләнештек. Ике ай чамасы үткәч, иремнең дусты өйләнде. Карыйм: бу кырына, ясана, матур киемнәрен кия. Туйга җыена. Мине чакырмый. Түзмәдем:

– Син нәрсә, Илсур? Яшь, чибәр хатыныңны өйдә калдырып, туйга үзең генә җыенасыңмыни? Мин дә синең белән барам, – дидем.

– Анда син кирәк түгел, йөрмә, өйдә утыр! – диде бу миңа, төксе генә.

Тиз генә җыендым да, каршы килүенә дә карамастан, автобуска чыгып утырдым. Ризасызлыгын белдерсә дә, кеше алдында тупаслыгын күрсәтмәде. Әмма туйда утырганда минем белән салкын сөйләште. Үзе янәшәмдә, күзе бер ләхүрә хатында. Хәтта бергә биеделәр дә. Бу хатын аның элек йөргәне булып чыкты. Шуңа күрә туй мәҗлесе йөрәгемә яра гына салды. Түздем, сүз әйтмәдем. Өйгә кайткач та ут йотканымны сиздермәскә тырыштым. Хурлыгы ни тора! Югыйсә бит аның өчен вәгъдәләшкән егетемне ташладым. Монысы әле чүп кенә булган икән, янартауларның котыруы, ут-ялкынның куырасылары алда булган икән әле...

Өч ел үткәч, кызыбыз туды. Кыз баланы кабул итмәдеме, бик еш эчеп кайта, холыксызлана башлады. Күп чакта ни эшләгәнен үзе дә аңламый. «Сөмбел, син миңа җен булып күренәсең», – ди торган иде. Хәтта әнисенә дә көн күрсәтмәде: әнине – әни дип, хатынны хатын дип белмәде. Беркайда да эшләми, тормыш алып барырга акча юк. Балага өч ай дигәндә, эшкә чыгарга мәҗбүр булдым. Ачка үлеп булмый бит инде. Кайнана да ризалашты, баланы үзем карыйм, диде.

– Син анда, эшлим дигән булып, кем куеныннан кайттың? – гел дә гел шундый сүзләр ишеттем.

Җәбер-җәфа күреп, тагын дүрт ел үтеп китте. Ниһаять, улыбыз туды. Шатлыгы, горурлыгы йөзенә чыкты. Тик бу халәте озакка бармады: өч ай үткәч, элекке эзенә кайтты. Ул гына да түгел: пычак белән уйный башлады. Көннәрнең берендә, аның котыруына түзә алмыйча, кызымны алып кечкенә өйгә кереп качтым. Ишекне эчтән бикләп куйдым. Улым кайнана белән калган иде. Бу, безнең кайда икәнне белеп алгач, пычагы белән тәрәзәләрне кырып төшерде.

– Чык хәзер үк. Чыкмасаң, малайны кереп суям!

Бу сүзләрне ишетүгә, котым алынды, йөрәгем ярыла дип торам. Йөгереп чыктык кызым белән: мине үтерсә үтерер, баланы саклап калырга кирәк дип уйладым. Баланы сакладым, ә үзем җәрәхәтләр алдым.

Китеп кенә барыр идем – китәр урын юк. Әниләр янына да кайта алмыйм: әти үлде, әни сукырайды. Ул өйдә абый белән килен дә бар бит әле. Ул безне кабул итәрме? Беркайчан да. Шулай булгач, кая барасың: ирең ни генә кыланса да, түзми хәлең юк. Шулай да мин бирешергә җыенмадым – ферма мөдире булып эшкә кердем. Читтән торып Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамладым. Клуб мөдире булып эшли башладым. Бу эшне әтидән дә өйрәнеп калган идем. Клубта эшләү миңа авыр булмады: бөтен нечкәлекләрен белә идем инде. Кыйналсам – кыйналдым, барыбер үз дигәнемә ирештем.

Әмма эшләп йөрүем иремдә нәфрәт, көнләшү уяту өчен сәбәп кенә булды: иртәрәк кайтсам да, соңарсам да – каты йодрык, әшәке сүзләр!

Соңгы вакытта бер нәрсәгә игътибар итә башладым: нинди генә этлек эшләмәсен, үзен-үзе белештерми котыра. Күзләр акайган, кан сауган, беркемне, бернәрсәне күрми, үзе калтырана, авыз кырыйларында – күбек. Беркөн шулай печән алып кайтып бушаткан гына идек, сәнәген тотып минем өскә килә башлады. Шоферлар да тотып кала алмады. Ярый әле, килеп җитте дигәндә генә, абынып егылды, мин тиз генә качып өлгердем. Аны шунда гына ирләр тотып алды. Акылына килгәч, елап җибәрде:

– Нинди зәхмәт соң бу? Кем мине шулай җенләндерә, ник мин тиле-милегә әйләндем? – диде газапланып. – Үземне дә бетерә бит бу зәхмәт!

Кайчакта аның күңеленә апалары да әшәкелек өсти иде: берсендә балаларың синеке түгел, йөреп тапкан балалар бит алар, дип шик салганнар. Бу этлекнең сәбәбен аңламадым. Югыйсә берсенә дә начарлык эшләмәдем. Апаларына мунча салышырга киткән иде бервакыт. Тагын әллә ниләр сөйләп җибәргәннәр. Бер гаепсезгә бит. Өстәвенә, авылдагы без яши торган өйне ике апасы бүлешә башлады: берсе – миңа язды-

«Яшь әни». М. Хаҗиев эше.

PRESSA.RU

рыгыз, икенчесе – юк, ул миңа булырга тиеш, дип, үзара гауга куптардылар.

Берсендә аш үткәрәбез. Кайнатай рухына дога укытабыз. Казаннан бер апасы кайтты. Кайтып керүенә әзер табынны, мин корган булганга, идәнгә сыпырып төшерде, тәлинкә-чынаякларның күбесе чәлпәрәмә килде. Илсурга шул мизгелдә анын җене күчеп өлгергәнме, минем янга очып килде дә каты итеп китереп типте. Мин идәнгә барып төштем, башым белән өстәл кырыена бәрелгәнмен. Уникe көн чирләп яттым: мием селкенгән булып чыкты. Табиблар килеп алып китә башлагач, үзе, елый-елый, зинһар, коткарыгыз, алып калыгыз үлемнән, дип ялварды.

Аллаһы Тәгалә, барын да күреп, ишетеп, ярдәменнән ташламагандыр инде. Мең рәхмәтлемен Аңа!

Апасы сүзенә караптыр инде, балаларга да рәхимсез булды. Бервакыт кечкенә чакларында, уйнап торган җирләреннән куып чыгарып, 30 градус салкында яланаяк верандада бастырып тотты. Балалар елый, мин дә, кайнана да чыгып ала алмыйбыз: икебезне дә алып кына бәрә. Шулай да көч табып, верандага бәреп чыктым да алып кердем мин аларны. Тик өйдә озак тотмады, ишегалдына эткәләп чыгарып, карда бастырып торды. Аннан көчкә ычкындым да, ике баланы да кыстырып, апаларга чыгып чаптым. Икенче көнне балаларны анда калдырып кайттым. Кайткач, тагын эләкте инде.

Кайда да булса эшләү түгел, өйдә дә эшләми. Эчеп кайта да ята, эчеп кайта да ята. Мал-туарны ун яшьлек кызыбыз карый. Мин эштә бит инде. Беркөн исерек килеш абзарга чыккан да: «Әниең кайда?» – дип, кызына сәнәк җибәргән. Ярый әле кызыбыз башын иеп калган – сәнәк абзар ишегенә килеп кадалган. Кызым апасына йөгергән. Әле артыннан килеп:

– Әниеңнең кайда икәнен әйтмәсәң, үтерәм, – дип буа башлаган.

Бу хәлне белүгә, йөгереп кайттым. Миңа тагын эләкте.

Бер елның февралендә бензин сибеп өйне яндырды. Малай – мәктәптә, кыз – Казанда апада, мин – эштә, кайнана газ өчен түләргә киткән иде. Шулай итеп, кыш көне бернәрсәсез урам уртасында калдык.

Түземем төкәнде, Казанга китеп бардым. Әле бит бу өйне яңа гына салып кергән идек. Йөрәк әрнүемне, җан сыкравымны айлар буе баса алмадым. Улым абыйларда торып торды. Кызым Казанда иде бит инде. Илсур үзе мунчада торып калды. Әнисе авылдагы кызына китте. Ике-өч айдан әнисен кызы куа башлаган.

Ул вакытларда кайнананың күзеннән яшь китмәде. Кайт инде, дип ялынды миңа. Илсур да килә дә ялына, килә дә ялына. Алты айлап заводта эшләгәннән соң, Илсур мине яңадан алып кайтып китте. Гел кеше өстендә торып та булмый бит инде. Бәлки акылына килгәндер, дип, ризалаштым. Подъездлар юып акча да туплаган идем. Апам да, кайтып кара, бәлки җайлангандыр, яши белмәгәненә үкенәдер, диде. Шулай итеп, кайттым. Яңа өй салдык. Түбәсен әйбәтләп ябып, эчен дә матур итеп эшләп куйдык. Ут, газ керттек. Өлгереп калыйм дигәндәй, ашкынып эшләде. Балаларга да үзгәрде: улым, кызым дип кенә йөрде. Өч ел эчмәде. Ун-унбиш тапкыр дәвалануга йөрттем. Кызым педучилище тәмамлады, аннары югары белем алды. Бүгенге көндә балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Кияүгә чыкты. Әлегә бала белән өйдә утыра. Аллага шөкер, тормышы әйбәт.

Шулай итеп, берничә ел матур гына яшәп калдык. Унберенче елның Яңа ел кичә. Бәйрәм иттек. Бик матур утырды. Бераз эчте. Тик эчте дә косты, эчте дә косты: нык газапланды. Икенче көнне эшкә киткәндә миңа:

– Исән-сау гына эшләп кайт, – диде, чәчләремне сыйпап, битемнән үпте. Күзләрендә – җанны тетрәндергеч моңсулык.

– Син нәрсә, кайтмас, дип уйладыңмы әллә? Тормышыбыз матураеп килә, нишләп бу тормыштан китим. Эшем бетүгә йөгереп кайтам, – дидем.

Йөгерә-чаба эштән кайтсам – мунчага кереп асылынган.

Инде калган гомерләребезне тигезлектә, балаларыбыз игелеген күреп, бәхетле яшәрбез, дигәндә, менә шундый хәл булды да куйды. Әле бит Яңа ел алдыннан шулкадәр назлы, соклангыч иргә әйләнгән иде: килә дә кочаклый, килә дә үбә, аркамнан сөя. Гел яшь чактагы кебек. Шаккаткан идем. Монысы белән аңымны җуйдырды.

Аны җирләгән елны улыбыз унберенчене бетерде. Ул хәзер заводта эшли: яраткан һөнәре бар. Ирем үлгәч, бер еллап ферма мөдире булып эшләдем дә киттем ул эштән. Инде менә бу эшемдә рәхәтләнеп эшлим. Җайлы, чиста эш. Мөнәсәбәтләр әйбәт. Әллә ни күп булмаса да, акчасы бар. Аллага шөкрана кылып кына яшисе инде. Тик бер нәрсә күңелне китә: бүгенге көнгә кадәр аннан калган бурычларны түлим. Менә шундый тормышта егерме биш ел яшәдем. Ничек түзелгән, ничек үлеп китмәгәнмен, дип уйлап куям кайчакта.

Апама да рәхмәтлемен. Гомер буе ул ашатты, ул киендерде. Алты ай урын өстендә ятып, кулларымда үлгән кайнанам, миңа шактый яманлык кылса да, үзенең пенсия акчасын кызларында тотып, минем хезмәт хакымны, бала акчасын үзенә алып, миңа бер тиен дә бирмәсә дә, фани дөньядан хәер-дога белән китеп барды...»

Менә мин юлда очрашкан бер ханымның – хәзерге заман хатын-кызының сөйләгәннәрен түкми-чәчми сезгә бәян иттем. Ни аяныч, заман үзгәрсә дә, «Татар хатыны ниләр күрми?» кыйссасы дәвам итә икән. Ә без тәрәккыят дибез...

ИР БИРМӘК — ҖАН БИРМӘК...

Алсу
ИСМӘГЫЙЛЕВА



блогер: www.syuyumbike.ru

— Әй, хәлләр әйбәт түгел әле. Минем Ленар башка хатын белән йөри икән. Инде ун елдан артык...
Күптән күрешмәгән дус кызымның хәлен белергә дип кенә шалтыраткан идем. Ә ул, исәнләшүгә, әнә нинди хәбәр әйтеп шаккаттырды. Күңеле ташыган чакка туры килдем бугай — сөйли дә сөйли, ә мин, сүз дә әйтергә җөрьәт итмичә, аны тыңлыйм.

Хәтерлисеңме, улыбыз Илгиз тугач, нык кына авырдым. Кулда кечкенә бала, өстәвенә, үзем дә хәлсез – ир кайгысы калмаган иде шул миндә. Менә шул вакыт сөекле ирем сулга борган да инде... Миннән 2 яшькә генә яшьрәк ялгыз хатын янына йөри башлаган. Илдә булмаган хәл түгел бит, мондый хәлләр турында гел ишетеп торабыз. Тик үзеңә килеп кагылгач, бөтенләй башка икән. Хыянәт ачысын кайчан да булса үзем кичерермен дип, никтер күз алдыма да китермәдем шул. Кем уйлаган?! Белгәч, шаша яздым. Бу хәлләрнең инде ун елдан артык сузылуын аңлагач, чәчләремне йолкып елардай булдым. Бернәрсә сизмәдем, шикләнмәдем бит! Иремнең кайда эшләгәнен беләсең, эш көне фәлән сәгатьтә башланып, фәлән сәгатьтә тәмамлана торган түгел: шуңадыр, соңлап кайтуларына әллә ни исем китми иде. Әле беләсеңме, иртәләрен бала аны уятмасын дип, улымны кочаклап икенче бүлмәгә чыгып утыра идем – әтисе йокласын, янәсе. Белгән булсам икән шул вакытта аның нәрсәдән арып йоклаганын...
Дустымның ярсып-ярсып сөйләвен тыңлап, алда буласы хәлләрне фаразлыйм. «Мөгаен, аерылышырлар... Болай булса, гаиләләре җимерелә инде. Карап торышка әйбәт кенә гаилә бит инде», – дип уйлыйм.

Юк, алай булмады – хәлләр бөтенләй көтелмәгән борылыш алды. Һәм шушы мизгелдән мин дустымның ни дәрәҗәдә акыллы икәненә гаҗәпләнеп, аны тыңлый башладым.

– Аерылу турында уйладым инде, уйламаган кая... Аннары туктадым. «Ашыкма әле», – дим үз-үземә. Улым әтисеннән башка нишләр? Һәм, гомумән, нигә соң әле без аерылырга тиеш? Көндәшем аерылсын! Никахлы хатын мин бит. Ир – минеке!

Шулай дип уйладым-уйладым да, көндәшемнең өенә киттем. Әйе, дөрес ишеттең, өенә бардым! Менә хәзер соңыннан сөйләү генә җиңел кебек, ә беләсеңме ничек авыр булды аның ишеген барып шакуы?! Кергәч, еламасам, ул хатын белән сугышмасам ярар иде дип шундый курыктым...

Ишек кыңгыравына ничек басканымны да хәтерләмим. Ачты ишекне. Күреп беләм мин аны, безнең мәктәптә, миннән ике сыйныф түбән укыды ул. Менә каршымда басып тора – матур гына үзе, кечкенә буйлы. Мине күргәч аптырамады да шикелле. Кертте. Ник килгәнне аңлады, әлбәттә, шуңа сүзне кыска тоттым: «Безнең бергә тора башлаганыбызга 12 ел. Мин 25 яшьтә кияүгә чыктым, әни булдым. Иремне башкалардан аерып алмадым. Ә син шушы матурлыгың, уңганлыгың белән кеше иренә калганмы? Ул бит синең янга гаиләсеннән бушаган вакытта гына килә, ә син шуңа риза булып торасың. Кеше иренә гомереңне, чибәрлегеңне, вакытыңны әрәм итәсең. Ленар безне ташламаячак, үзе әйтте. «Мин бит күңел ачарга гына йөрим аның янына», – диде. Ә син шуңа риза, әйеме? Ул сине уенчык урынына гына күрә. Кермә безнең арага, рәнҗеш алма, зинһар», – дидем дә чыгып киттем.

Күрсәң ничек авыр булганын, томан эчендәге кебек кайттым... Бусаганы атлап кергәч Ленарга: «Сәрияң янына бардым», – дим. Беләсеңме, ул аны шундый тыныч кабул итте. Кайчан да булса бу хәлләрнең бер тишелеп агасын сизеп йөргәндер инде...

Ә икенче көнне Ленар балтасы суга төшкәндәй кайтып керде. «Булдыргансың, Сәрия араны өзде», – дип бер җөмлә генә әйтте дә, ашамыйча да кереп урынга ауды. Алай икән, дим эчемнән.

Беләсеңме, якын кешеңнең хыянәте турында ишетү тормышта кинодагыдан бик нык аерыла икән. Без Ленар белән бу хакта хәтта тавыш күтәреп тә сөйләшмәдек. Ул әйтә, мин әйтәм: тып-тыныч тонда. Савыт-саба да шалтырамады. Ишекне каты итеп ябып чыгып китүче дә булмады. Мин хәтта үз-үземә шаккаттым. Әле дә аңлый алмыйм – безнең арадагы мөнәсәбәтләрнең нык-лыгы сәбәпме моңа, әллә бу шыр битарафлыкмы? Үзем яратам да кебек Ленарны. Башкага бирәсе килми бит! Ул да мине ташламыйм ди. Димәк, мөнәсәбәтләр нык безнең. Гаиләбез икебезгә дә кадерле, димәк. Шулай дип алдаган булам инде үземне, белмим... Өметне бөтенләй өзәсе килми бит. Ә бәлки чыны шулдыр. Ни генә дисәм дә, җан тынычлыгым качты, бик авыр... Карале, күңелне тынычландыра торган берәр дога белмисеңме?

Бу сөйләшүдән соң өч атна да үтмәде, дустым кабат шалтырата. «Хәзер сиңа Санта-Барбара сөйлим! – ди. – Сәрия кияүгә чыккан бит! Әлмәткә! Аны күптән инде берәү ошатып йөргән икән, тик Сәрия яратып бетермәгәндерме, өнәмәгәндерме?.. Менә шуңа ризалык биргән бит! Ияргән дә китеп барган Әлмәткә».

– Кайдан ишеттең? Әллә соң сиңа үзе әйттеме? – дим, аптырап.

– Әйе, үзе әйтте! Мин дә синең кебек шаккаттым. Шалтыратып әйтте. «Киттем, шатлан!» – диде. Әле шул вакытта бар ачуымны җыеп: «Мин күргәннәрне син дә күрсәң иде!» – дип тели яздым. Чак тыелып калдым! «Китүең әйбәт. Бәхетле бул!» – дип кенә әйттем. Аңа рәнҗүдән миңа ни файда инде?

Ленар өйдә хәзер. Югалып йөрми. Кәефе әйбәт кебек. Бер йөргән кеше үлгәнче йөри, диләр инде, анысы. Минеке нишләрдер... Хыянәт ачысын дошманыма да теләмим...

Ахыры матур төгәлләнгән менә шундый бер вакыйга сезгә. Бу хәлләрне языйм әле, дип сорагач, дустым каршы килмәде. Исемнәр, әлбәттә, үзгәртелде. Кемнәргәдер гыйбрәт, сабак булсын әле.

PRESSA.RU

МӘСКӘҮДӘН КҮТӘРЕЛЕП КИТКӘН САМОЛЕТЫБЫЗ СОФИЯ АЭРОПОРТЫНА ИСӘН-ИМИН ТӨШЕП УТЫРДЫ. ТИК СӘЯХӘТЕМНЕҢ АХЫРГЫ НОКТАСЫ БУ ТҮГЕЛ БИТ ӘЛЕ...

РӘХМӘТ, БОЛГАРИЯ!

Мин практика узачак Пловдивның үзендә аэропорт юк, шуңа күрә башкаладан башта – поездда, аннары автобуста барасы. Үзем чит илнең чит табигатен, биналарын, кешеләрен күзәтәм, үземнең башымда бер генә уй: Болгарияне ярата алырмынмы?.. Казан дәүләт медицина университетында халыкара стажировка үтү өчен махсус программа бар (медицина студентларының Татарстан ассоциациясе). Тәвәккәлләп, мин дә гариза яздым, Болгарияне сайладым. Инглиз теленнән имтихан тапшыру, бер кочак документ җыйнау – барысы да артта. Мине чит илдә бер ай дәвамында медицина практикасы узу, яңа танышулар һәм мөмкинлекләр көтә.

«Әйе-юк» димәскә...

Әле Казанда вакытта ук бик әйбәтләп үзем барачак Пловдив шәһәренең картасын өйрәндем. Дөнья хәлен белеп булмый, каршы алмасалар яки адашсам, кирәге чыгар. Шөкер, кураторым каршы алды. Яшәргә төрле илләрдән килгән студентлар белән бергә тулай торакка урнаштырдылар.

Беренче атна сагыну катыш курку белән үтеп китте. Чит илгә беренче тапкыр үзем генә баруым иде бу. Әле инглизчә генә аралашырга кирәк бит. Өстәвенә, Пловдивка практика үтәргә Россиядән башка бер студент та килмәгән. Бөтенләй белмәгән илдә берүзем! Бәхетемә, болгар егет-кызлары арасында русча белүчеләр бар булып чыкты. Болгар теле бераз рус теленә охшаган, шуңа күрә кайбер сүзләрне үзем дә аңлый идем. Ә башка чит илләрдән килгән студентларга кыенрак булды, телне дә белмиләр, әлифбасын да танымыйлар.

Бу илгә чыгып киткәнче, дусларым кисәтеп куйган иде: Россиядән икәнлегеңне берәүгә дә әйтмә, русча сөйләшмә, анда безгә карата нинди мөнәсәбәттә булуларын белмәссең... Мин практика узачак хастаханәгә килеп керүгә, кураторым, бу кыз Россиядән, дип таныштырды, үзе дә русча белә иде. Бер кешенең дә үземә кырын каравын сизмәдем. Форсат чыккан саен: «Мин Татарстаннан», – дия идем. «Рубин»ны беләләр! Күңелгә рәхәт булып китә.

Без ризалашканда башны кагабыз, ә «юк» дигәнне белдерү өчен ян-якка чайкыйбыз бит. Ә Болгариядә –





киресенчә! Анда барганда бу турыда кем белсен инде?! Шуңа күрә беренче вакытта болгарлар белән аңлаша алмый азапландык. Ниндидер сорау бирәсең, баш кагалар. Аптырыйм – «юк» дип җавап бирергә тиеш иде кебек бит. Бераздан гына төшендем: аның баш кагуы шул «юк» дигәнне аңлата да икән инде. Иялләштем мин бу гадәткә, хәтта Казанга кайткач та озак вакыт «болгарча әйе-юк» белән аралаша идем.

Суы өчен яратырга була

Пловдив – Европадагы иң өлкән шәһәрләрнең берсе. Рим, Афина, Карфаген һәм Константинопольдән дә «картрак» ул. Башта – Рим империясе, аннары – славян кабиләләре, ә 815 нче елдан Беренче Болгар ханлыгы хакимлегендә булу үз эзен калдырган: Пловдив һәм, гомумән, бүгенге Болгария – милләтләр һәм мәдәниятләр, катнашып, дус-тату яши торган ил. Бу яктан Татарстаныбызны хәтерләтте ул миңа.

Мәйданы буенча Пловдив Чаллы шәһәреннән азга гына калыша. Төшкә кадәр хастаханәдә һәрберебез үз бүлегендә практика үтсә, төштән соң бергәләп шәһәрне гиздек. Тулай торактан ерак түгел ишкәк ишү каналы бар иде. Ул ял базасы рәвешендә эшләнгән: яшеллеккә күмелгән паркы, утырып ял итәр өчен эскәмияләре, йөгерү һәм велосипедта йөрү өчен махсус юллары бар. Ә каналда спортчылар ярыша. Мин дә катамаранга утырып йөреп килергә уйлаган идем – рөхсәт итмәделәр, спортчылар өчен генә икән.

Су дигәннән, шунысын да әйтим: Болгария минераль чыганаклары саны буенча Европада Исландиядән генә калыша. Су бик чиста, йомшак, тәмле анда. Бездәге кебек күпләп хлор кушмыйлар. Организм андагы суга шулхәтле күнекте, Казанга кайткач, чиста су эчәсем килеп тилмердем. Болгариядә кешеләр озын гомерле. Монда чиста суның роле бик зур, билгеле. Икенчедән – климат. Ул артык эссе дә, коры да түгел, организм өчен бик кулай. Ә озак яшәүнең өченче сере болгарларның тыныч халык булуындадыр, мөгаен. Бездә зур шәһәрләрдә яшәүчеләр гел каядыр ашыга, җитешмәм дип курка. Анда ыгы-зыгы юк, машиналар да җилне узарга тырышып чапмый. Шулай булса да, бөтен җиргә җитешәләр.

Пловдивта ике мәчет бар: берсе шәһәрнең читендә, икенчесе үзәктә. Манарасыз, гап-гади бер корылманың мәчет икәнлеген белми үтеп китәсе дә булганмын, Тунистан килгән студент кыз гына әйтте. Янына килеп карагач, мәчет дип язылганын күрдем. Безнең манара очындагы ае әллә кайдан балкып күренеп тора торган мәчетләргә җитми инде!

Болгария халкы бик ачык булуы белән беренче көннән үк игътибарымны җәлеп итте.

Атна уртасында Пловдивта гына йөрсәк, ялларда Болгариянең башка гүзәллекләрен карарга бара идек. Иң истә калганы – Рила тавының җиде күле. Бу табигый тыюлыкны карарга җир шарының бөтен почмакларыннан киләләр. Таулар арасында җиде күл җәйрәп ята. Һәрберсенең исеме бар: Бөер (шул органга охшаган), Күз, Балыклы... Шунысы кызык: җиде күлне берьюлы күрер өчен тауның башына ук менәргә кирәк. Бер калкулыкны үтәбез – бер күл ачыла, әзрәк менгәч – икенчесе. Ниһаять, тау башына менеп җитеп, аска карагач, кояш нурларында җемелдәп яткан җиде күлне күрәсең. Ә баш очында – болытлар, үрел дә тотып кына ал...

Пловдив үзе диңгез ярында урнашмаган, шуңа күрә бер ялда Кара диңгез буена – Кояшлы яр дип аталган комлыкка бардык. Кызганыч, ул көнне яңгырлы иде, Кояшлы ярның кояшын күреп тә, коенып та булмады.

PRESSA.RU





■ Казанда – нейрохирургия бүлегендә практика узу насыйп булмаган иде. Пловдив клиникасында нинди җаваплы һөнәр сайлаганымны аңлап, илһамланып кайттым.



Европада урамда бер тузан бөртеге дә юк, диләр. Дөрес, урамнар бик чиста, менә комлыкларның төрлесе бар. Чиста җир тапканчы шактый гизәргә кирәк.

Табибны үзең сайлыйсың

Практиканы Пловдив шәһәренең УМБАЛ Свети Георги клиникасында нейрохирургия бүлегендә уздым. Иң беренче игътибарымны җәлеп иткән үзенчәлек шул булды: Болгариядә бездәге кебек өлкәннәр һәм балалар хастаханәләре дигән бүленеш юк. Мәсәлән, мин практика узган клиникада зурларны да, сабыйларны да бер үк бүлектә, ләкин төрле палаталарда кабул итәләр иде.

Кешеләр тыныч кына йөри, кичләрен урамга, паркларга чыгалар.

Бөтен дөньядагы кебек үк, Болгариядә медицина амбулатор һәм стационар төрләргә бүленә. Амбулатор медицина ярдәмен гомумпрактика табиблары күрсәтә. Мәҗбүри иминиятләштерү кертеме ясаучылар табибны үзләре сайлый, ә ел ахырында аны алыштыра ала. Авырса-авырмаса да, хастаханәгә килеп йөрмәсеннәр дип, Болгариядә әйбәт канун кертканнәр. Табибка күренгәндә, минималь хезмәт хакының бер проценты күләмендә такса түлисең. Әби-бабайлар, иртән иртүк килеп, чират алалар, талон буенча килүчеләр дә бар – ул яктан бездәгедән әллә ни аерылмый.

Гомумпрактика табибларына хезмәт хакы медицина иминиятенең Милли кассасыннан түләнә. Сиңа күренергә никадәр күбрәк кеше язылган, хезмәт хакың да шулкадәр күбрәк булачак. Бездәге коллегалары белән чагыштырганда болгар табиблары күбрәк ала, әлбәттә, тик бөтен Европа буенча исәпләгәндә, эш хаклары түбән санала.

Токмачлы ашны сагыну

Кызлар да булсын, кибеткә дә йөрмәсен, ди. Без дә, буш вакыт булуга, сәүдә үзәкләренә юнәлдек. Европа булгач, монда мода бик алга киткәндер инде, дигән идем. Ялгышканмын. Россия Болгариягә караганда бер адымга алдарак бара икән әле. Италия, Тунис кызлары да минем белән килеште.

Менә бәяләр – «тешләшә». Кием-салым бик кыйммәт Болгариядә. Ә азык-төлек, киресенчә, арзан. Бу илгә ашар өчен генә килергә кирәк икән, дип көлештек. Кечкенә кибетләр, банклар ял көннәрендә эшләми. Шуңа күрә үзебезгә кирәкле азык-төлекне атна уртасында алып куя идек.

Төрле милләт һәм мәдәниятләрнең үзара катнашуы болгар кухнясында да сизелә. Милли ризыкларыннан ит белән бәрәңге кәтлитен әйтергә була. Аларны тигез күләмдә кушып пешерәләр һәм аерым ризык итеп табынга чыгаралар. Болгариядә һава температурасы кайвакыт +40 градуска кадәр җитә. Шундый кызу көннәрдә сусауны баса торган эчемлек бик булыша: кыяр һәм тәмләткечләр кушылган әйрәнне бөтен кафеларда саталар.

Казаннан чәкчәк алып барган идем, аны бик ошаттылар. Мин үзем токмачлы ашны сагындым. Анда ашлар боламык кебек кенә бит, бездәге кебек токмач, бәрәңге, ит салып пешерелмәгән. Әнием дә шуны истә тоткандыр, Казанга кайтуыма беренче сүзе: «Кызым, мин сиңа токмачлы аш пешердем», – булды. Хәер, ашын гына түгел, һавасын, табигатен, кешеләрен дә сагынган идем Татарстанның. Кунакка барырга була, тик яшәр өчен читкә китәргә әзер түгел икән әле мин.

P. S. Ә бүген практика вакытында табышкан дусларга сагыну тулы электрон хатлар оча: Италия, Тунис, Төркия, Албания, Польша һәм, әлбәттә, Болгария. 10-15 елдан соң берәр халыкара конференциядә очрашсак, ничек күңелле булыр иде, ә!

Азалия ДӘҮЛӘТШИНА



НУРЗАДӘ

Казан дәүләт педагогика институты

Кияүдә түгел

Карьера:
Карьера: җырчы, автор-башкаручы, тамада-алып баручы

Тормыш шигаре: «Барысы да әйбәт булачак – баш ярылып, күз чыкмаган»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Хуш килдегез!..

Быел әллә ничә тапкыр кыр казлары кайтканын күрдем! Безгә, шәһәрдә яшәүчеләргә, мондый бәхет еш эләкми. Калаларны казлар күбрәк урап уза бугай... Шундый матур итеп тезелешеп очтылар! Табигатьнең бу могҗизасына башкалар да минем кебек сокланып карыймы икән?! Күктә казлар төркеме күргәндә гел уйлыйм: меңәр чакрым юл узып, туган якка ничек кайта икән бу кошлар? Адашмыйча, юлны онытмыйча. Кошларда да кеше язмышлары – туган як аларга да газиз...


Дөнья акчага гына корылмаган


Без, җырчылар, артистлар быел да шактый хәйрия концертларында чыгыш ясадык: Казанда, Балтачта, Арчада... Мин дә үземнең төркемем белән Арча һәм Саба картлар йортларында булып кайттым. Карт-карчыклар килеп арка-быздан сөя, рәхмәт әйтә. Шундый рәхәт тә, авыр да алар каршында чыгыш ясавы. Өлкәннәрне ял иттерәбез – монысы күңелгә рәхәт, әмма анда яшәүчеләрнең язмышын якыннан белгәч, кыен булып китә. Иртәгә ни көтәсен беребез дә белми. Иҗатташ дусла-рымның риясызлыгы өчен бик куанам.

Дөнья картасында – Казанның үз урыны!

Җир шарының кайсы почмагыннан килсә дә, һәр туристка Казаныбызны хәзер сөенеп күрсәтерлек! Казан – дөньякүләм билгеле шәһәрләргә тиңләшеп килә! Юлларыбыз менә дигән (алар өчен рәхмәт укымый калган кешем юк!), урамнар күзгә күренеп үзгәрә, матурая, төзекләнә... Башкалар да минем кебек Казанда яшәүләре, татар булулары белән горурланамы икән?! Алда – футбол буенча Дөнья чемпионаты, аннан – WorldSkills Competition... Бөтен галәмгә үзебез турында тагын ишеттерәсебез бар әле!

сөендерде










көендерде

сөендерде










көендерде

сөендерде







көендерде

Нигә без битараф?!

Язгы салкын көнне авылга кайтып барам. Яңгыр ява. Тукталышта бер яшь хатынны утырттым. «Сәгатьтән артык басып торам инде, берсе дә туктамый», – ди. Әнисе авырый икән, хәлен белергә барган. Үзе ярты ел элек кенә авылга кияүгә чыккан, фермада сыер сава, 10-15 мең сум акча ала икән. «Кул эшләрен яратам, әйберләр дә бәйләп саткалыйм», – ди. Җәлләтеп сөйләве түгел, сүз итеп кенә... Иренә шалтыратып алды: «Аякларым лычма су, олы юлга чыгып каршы ал әле...» Янышннан бер сәгать дәвамында узып торган машиналар турында уйладым: руль артында ир-атлар булгандыр инде...

Хатын-кызны бәяләмәделәр

Быел Тукай премиясен алучылар арасында бер хатын-кыз да булмавы кәефне төшерде. Арада бик лаек-лылар бар иде, минемчә. Танылган язучы, тарихчы, милләтпәрвәр Фәү-зия Бәйрәмова, бөтен төрки-татар дөньясына таныш җырчы Гөлзадә Сафиуллина... Татар халкын дөнья-күләм танытуга зур өлеш керткән шәхесләр. Хатын-кыз, гомумән, ир-атның күбесе булдыра алмаган эшләрне башкарып чыгарга сәләтле. Көчле дә. Егылсалар да, торып басып, өс-башларын кагып җибәрәләр дә, кабат алга чабалар.

Кичерегез, ветераннар...

Донецк өлкәсенең Славянск шәһәрендә Бөек Җиңү көнен бәйрәм итәргә урамга чыккан 91 яшьлек сугыш ветераны, Белоруссияне фашистлардан азат итүдә катнашкан Любовь Печконың өстенә йомырка аткannar; Харьковта «Георгий тасмасы» тагучыларга һөҗүм иткәннәр; Киевта «Үлемсез полк» йөрешен өзәргә маташканнар...
Бу минутларда ветераннар ниләр кичерде икән?! Минем дә бабам сугыш ветераны иде. Берничә тапкыр яраланган булган – таякка таянып йөри иде. Ул бу хурлауларны күрмәде: йөрәге чыдамас иде.

PRESSA.RU

16+

ИҢ ЧИБӘРЕ — СИҢА ЫШАНГАН ХАТЫН-КЫЗ!



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.

Фәрит МИФТАХОВ,
«Болгар» хәйрия фонды рәисе,
Бөтендөнья татар конгрессының
Казан шәһәре бүлеге җитәкчесе,
Нурлат районының «Якташлар»
җәмгыяте рәисе.
Өйләнгән; Гаилә стажы — 26 ел;
Ике кыз һәм бер малай атасы.

1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Никахтан соң ир-атның – күзе, хатын-кызның теле ачыла, диләр. Күзең йомык, сукыр чакта каршыңдагы кешенең тышкы матурлыгын, уңай якларын гына күрәсең, билгеле. Өйләнгәч: «Кара әле, бу бит минә нинди икән?!» – дип шаккатулар башлана. Шул чакта инде мөнәсәбәтләр дә үзгәрә...

Күз алдына китерегез: өстәлдә конфетлар ята. Бер төслеләре – кәгазьсез, икенчеләре ялтыравыклы матур кәгазьгә төрелгән. Кулыгыз кайсына үрелә инде? Әлбәттә, кәгазьгә төрелгәненә: эчендә ни икәнен беләсе килү көчлерәк! Хатын-кыз да яулыктан булса, ир-атлар аңа күбрәк игътибар итәр, ныграк тартылыр иде (башка беркем күрмәгән, кагылмаганга ия булу горурлык түгелмени?!) Тик без бөтенләй башка җәмгыятьтә яшибез шул...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Озак еллар бергә яшәгәч, бер-береңне кичерергә өйрәнәсең инде ул. Кайсын: «Кирәк, шулай тиеш», – дип, кайбер нәрсәләрне: «Балалар хакына», – дип...

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Әлбәттә, хыянәтне! Ир-ат мондый чакта күбрәк киләчәге – балалары турында уйлыйдыр. Иренә тугрылык сакламаган хатын-кыз ана буларак балаларына нинди үрнәк күрсәтсен?!

Икенче яктан караганда, минә шулай, өздереп: «Беркайчан гафу итмәм», – дию бигүк дөрес тә түгелдер. Этле-мәчеле яшәгән гаиләләрдә, ире яки хатыны белән нидер булып, берсе икенчесен мәңгелеккә югалткач: «Исән булсын иде! Утырып кына торса да риза булыр идем...» – дип өзгәләнүләрне гел ишетәбез.

4 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Синең турыңда бөтен нәрсәне дә белгән кеше ул, әлбәттә, дустың була инде.

5 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?

– Армиядән 1988 елның көзендә кайттым. Дөресрәге, Яңа ел алдыннан. Әни бу вакыт «Оргсинтез» бассейнында эшли иде. Беркөнне ул мине үзләренә бассейнда йөзәргә чакырды. Көнен дә хәтерлим, 17 декабрь иде ул. Без анда бер дустым белән икәү бардык. Суга кереп йөзә башлауга, дустым танышын очратты. «Узган атнада гына бер туйда бергә булган идек», – диде алар. Без танышканда Наилә Казан химия-технология институтының IV курсында укый иде. Февральдә ул Тольятти шәһәренә практикага китте. Һәм мин... әтине искә төшердем. Әтиемне бер тапкыр да күргәнем юк иде, Тольяттида яшәгәнен генә беләм. Безгә бер очрашырга кирәк иде бит инде! Кыскасы, җыендым да юлга чыктым... Андагы очрашуларның минем өчен кайсы мөһимрәк булды икән, әйтүе авыр.

Наилә белән без 1989 елның 23 сентябрендә өйләнештек. Ул вакытта армиядән кайталар да өйләнәләр иде бит. Әнине киленле итәсем, оныклар белән куандырасым килде. Мин армиядән кайтканда аңа 60 тулган иде инде, ул мине кырык яшендә генә тапкан.

Наиләгә тәкъдим ясавым кинолардагы кебек булмады инде, әлбәттә. Ихлас булса, айга алып менеп әйтсәң дә, җирдә дә бертөсле яңгырыйдыр инде ул сүз...

6 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр, шулаймы?

– Шулайдыр, бәлки... Әни бит ул синең өчен иң якыны, иң әйбәте. Ә кеше үзе өчен бу тормышта гел иң яхшысын гына сайлап алырга тырыша. Дөресрәге, үзе «иң яхшысы» дип санаганын. Минем очракта алай сайлап торулар булмады анысы. Әйткәнемчә, армиядән кайтуга таныштык та, 21 яшьтә өйләнешеп тә куйдык. (Олы

кызыма хәзер 19 яшь, ике елдан аны кияүгә бирәм, дип уйласам, бигрәк иртә тоела. Әмма әти-әнигә бала егерме тугызда да, утыз тугызда да сабый тоелачак...) Әниләр алты бала үскәннәр. Туганнар арасында ул иң олысы иде, бүгенге көндә бер энеләре генә исән. Әни бик ярдәмчел иде: туганнарына да, тирә-юньдәгеләргә дә. Авырлыкны тормышта җитәрлек күргән. Апа белән мине дә ялгызы гына аякка бастырды.

7 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Шактый катлаулы очрак бу, бигрәк тә татар гаиләсе өчен... Гасырдан-гасырга безнең гаиләләрдә тәртип башкачарак булган бит. Әмма тормыш хәзер шактый үзгәрде. Ир-атларга бик күп нәрсәләргә түзәргә, бик күп әйберләр белән килешергә туры килә. Теләсәләр дә, теләмәсәләр дә. Әмма бүген татар гаиләсендә барган үзгәрешләрнең иң куркынычы бу түгел әле...

8 Гашыйк булуын хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Чын күңелдән ярата икән, нигә әйтмәскә, белгертмәскә?! Ир кешегә дә мондый хатын-кыз белән тормыш кору хәерлерәк, дөресрәктер. Гомумән, хатын-кыз ир-атны күбрәк яратса, мондый гаилә тотрыклырак була бугай. Хатынның ирен яратуы ризык әзерләгәндә дә, балалар тәрбияләгәндә дә чагылмый калмый. Яратса, ире белән барлык авырлыкларны кичәргә дә әзер ул. Кичә дә!

Җанына якын булган ир-атны үзенә карату өчен хатын-кызның хәйләсе җитә дип уйлыйм. Аларның үзе генә белгән юллары, ысуллары бик күп бит. Кайбер ир-ат бер тапкыр йомшаклык күрсәтә дә, гомере буе шуның өчен түли аннары. Шуңа күрә, соңыннан газапланганчы, озак итеп сайлавың хәерлерәк, диләр.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Хатын-кызлар ир-атны хәзер күбрәк кесәсенә карап сайлый, диләр. Нәфес бит ул, ә аңа хуҗа булу бик авыр! Тик акчаның – бигрәк тә күп акчаның – гаиләләргә зыян гына китергән очраклары да күп шул. Бөтен нәрсә дә җитеш булгач, гаилә башлыгы еш кына читләргә күз төшерә башлый. Кесәсендә гел акча булган балалар янына кирәкмәгән дуслар җыела. (Наркотикларны кемгә тәкъдим итәргә икәнен алар яхшы белә!) Акча проблемасы булмаган гаиләдә күп вакыт мажор балалар үсә: кулыннан бер эш килмәгән, тормышка яраксыз булган. Аннан тагын бер нәрсә: акча бүген бар, ә иртәгә исә ул булмаска да мөмкин. Кулында зур акчалар тотып караган кешегә юклыкка ияләшү күпкә авыррак. Ирнең акчасына гына кызыгып аңа кияүгә чыккан хатын-кызга – бигрәк тә.

10 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта.

– Берәүгә чибәр тоелган хатын-кыз икенче ир-атка бөтенләй ошамаска да мөмкин. Чибәрлекнең стандарты юк аның. Аннан, яши-яши, чибәрлек төшенчәсенә карата мөнәсәбәт тә үзгәрә икән. Хатын-кызның көче – иманлылыкта булырга тиеш. Синең белән гомер кичкән, сиңа үзенә ышангандай ышанган, һәр адымыңда сиңа булышкан хатын-кыз – чибәрләрнең дә чибәре!

11 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен, үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Аңламаган дип... Таныш-белешләремнән ишетеп беләм, өйдә кайсы җиһазның кайда торасын аларда күбрәк хатыннары хәл итә. «Еш кына әле шкафның, әле өстәлнең, әле диванның урынын алыштырып мәш киләләр», – дип зарланган чаклары да була. Ә бездә... киресенчә. Өй эчен үзгәртергә күбрәк мин яратам бугай. Наилә: «Нәрсәгә ул җиһазларны бер урыннан икенче урынга күчерергә?» – дип канәгатьсезлек белдерә әле.

12 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный...

– Минем андый чакларда бәхәсләшеп торасым килми. «Ярый, син әйткәнчә булсын», – дим. Хатын-кыз күп мәсьәләдә барыбер үзенчә эшләргә тырыша. Шуңа күрә моның дөрес түгел икәнен белсәң дә, килешәсең... Килешмәгән чаклар да бар инде анысы. Наилә баланы ераграк мәктәпкә урнаштырырга теләде, ул «элитный» дип саналган өчен генә. Баланы көн саен озату-каршы алу күпкә мәшәкатьлерәк икәне аңлашыла югыйсә. Бөкеләрдә утыру, анда киткән вакыт... Юл аша гына урнашкан мәктәпкә йөри кызыбыз. Үземнең хаклы икәнемне бу очракта исбатларга туры килде!

13 Шундый очракны күзаллыйк әле: арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...


– Өйдә һәрвакыт ашарга пешкән анысы. Аннан олы кыз да үсеп җитте – кирәк булса, ул да тиз генә нидер әзерләп бирә. Кайтырга чыккач, юлда гел шалтыратып ала торган гадәтем бар. Кичке аш әзер булмаса, өйдә нидер килеп чыкса, каядыр кереп ашап та чыга алам. Ә үзем әзерләргә... юк, миңа андый мөмкинлек бирмиләр.

14 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

Минем өйдәгеләр өйрәнгән инде: алар тиз җыена. Озак көтәргә яратмаганымны беләләр...

15 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Ничек ошамасын?! Бүләк ич ул! Миңа бүләк алганда кызлар да хәзер әниләренә сайларга булыша. Быел 23 февральгә ике урынлы самолетта очарга сертификат бүләк иттеләр менә. Нәрсә белән кызыксынганны, нәрсә кирәген чамалый алар. «Очып карарга иде бер!» дигән хыялым чыннан да бар иде!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

Мастер-классны яшь җырчы Рамил ЗАКИРОВ үткәрә. Ул – Чаллы егете. Узган ел гына Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлаган. Укытучысы – Венера Ганиева. Аңынчы әле ул Америкада эшләп кайтырга, үзенең бизнесын ачарга өлгергән. Америкада яшәгәндә үк аның Айнур Шәрипов белән яздырган «Күк төсле күзләр» җыры популярлык казана. Океан артыннан иҗатка сусап кайта Рамил.
Бүген үзенең иҗат төркеме белән концертлар куя, мәңгегә истә калырлык итеп туйлар оештыра, җырлар яздыра. Америкада яшәүче дусты Рәшит Галимов ярдәме белән яңарак кына «Тик син генә» җырына клип төшергәннәр. Кыскасы, иҗат дәрте белән янып йөргән көннәре. Җырдан тыш, тагын бер яраткан шөгыле бар Рамилнең – җырлый-җырлый ашарга пешерергә ярата. Чираттагы санибызда «Сөембикә» укучыларына итальяннарның иң популяр ризыгы булган (пиццадан кала, билгеле) ризотто пешереп күрсәтә.





РИЗОТТО

Кирәк

- 1 кг тавык ите;
- 200 г дөге (ризотто өчен арборио, басмати, виалоне нано, карнароли сортлары яхшы. Бик тырышканда гади дөгедән дә яхшы ризотто әзерләргә була);
- 2 баш суган;
- 3-4 тырнак сарымсак;
- 2 кишер;
- 100 г атланмай;
- 100 г каты сыр.







Эш барышы

■ Тавык итен сөякләреннән аралап, шакмаклап турыйбыз. Сөякләреннән шулпа кайнатырга куябыз. Кайнап чыккач, турамыйча гына бер баш суган белән кишер салабыз, тәменчә тоз өстибез. Шулпа әзер булгач, сөзеп, янә талгын утка утыртабыз. Шулпаның гел кайнар булуы кирәк.

■ Калын төпле табада атланмайның яртысын эретеп, суганны кыздырабыз. Суган яртылаш кызгач (көйдерми кыздыру мөһим), шакмаклап туралган кишер өстибез. Кишер йомшаргач, туралган тавык итен өстибез.

■ Дөгене юып, ит өстенә салабыз һәм болгата-болгата ит белән бергә кыздырабыз. Озак кыздырырга ки-







рәкми, 3-4 минут җитә. Дөге күмелер-күмелмәс кенә кайнар шулпа агызабыз, 3-4 тырнак сарымсак батырабыз. Ризотто ашчының үз янында булуын, шулпа өстәп торуын сорый.

■ Дөге тәмам әзер булганчы, кайнар шулпа өсти барып, болгата-болгата пешерәбез. Ризотто пылау кебек таралып та тормаска, шул ук вакытта дөге боткасына да әверелмәскә тиеш.

■ Итальяннар үзләре дөгенең бераз тереррәк булганын ярата. Аль-денто, диләр андыйны. Дөге әзер булгач, уттан алып, калган атланмайны өстибез, уылган сыр сибәбез. Барысын бергә сак кына болгатабыз.

■ Ризотто кайнар килеш кенә ашала торган ризык. Табынга аны сай тәлинкәгә салып, яшел аштәмләткечләр белән бизәп чыгаралар.

КОРТЛЫ ТӨШ



Мондый төшне Зәй районының Имәнлебаш авылында гына ясыйлар. Кортлы төш аларда кайчандыр Сабантуйларның иң зур сые саналган. Дөрес, элеккегеләр аңа киндер орлыгы куша торган булганнар. Ә Нурлыбәнат апа ИМАМИЕВА кортлы төшне көнбагыш кушып ясый.

Кирәк

- 0,5 кг көнбагыш (2-3 тапкыр юганнан соң, кыздырып, 3-4 тапкыр иттарткыч аша чыгарабыз);
- 10 йомырка (суыткычта өшетеп, угыч аша уабыз);
- 2 аш кашыгы май, ат мае;
- тоз, кашык очында гына чәй содасы;
- он;
- 250 г шикәр комы;
- 3 аш кашыгы бал.







Эш барышы

■ Йомырка, май, тоз, чәй содасы, он кушып, йомшак кына итеп камыр басабыз. Бүлеп-бүлеп алып, куна тактасында аны кул белән генә җәябез. Аннары 1 см тасмаларга теләбез. Һәр тасманы кулда гына тәгәрәтеп, әвәлибез. Аннары әйләндерә-әйләндерә, вак шарчыкларга кисәбез.

■ Сүрән утка кыздырырга куелган үсемлек маена чама белән эретелгән ат мае кушабыз. Май эреп бетәрбетмәс, төшне салабыз. Кул белән кагылмыйбыз, пычак белән генә этеп төшерәбез. Кабарып менмичә торып, майга салган төшне бутамыйбыз.

■ Шикәр комына бал һәм аз гына су салып, сүрән утта бер кат кайнатып алабыз. Аннары көнбагыш онын кушабыз. Бал катканчы төшне салып бутыйбыз. Төшләрдән шар формасындагы түгәрәкләр ясап, тәлинкәгә тезәбез. Бал ябышмасын өчен, кулны салкын суда манчып алыгыз.



Мастер-классның тулы варианты – сайтыбызда.

PRESSA.RU

БӘЛӘКӘЙ КЫЗЛАРГА



Наилә – хисапчы. Бәйләү белән кызы тугач кына мавыга башлаган. «Кибетләрдә кыз балалар өчен берсеннән-берсе матуррак киемнәргә карап, үзем дә бәйләргә өйрәндем. Кызымнан күреп, башка әниләр дә кызыга, безгә дә бәйләп бир әле дип әйтәләр иде. Шулай итеп, бәйләү минем кәсебемә әйләнеп китте», – ди Наилә ханым. Берәүдә дә булмаган кием бәйләп кияргә телисез икән, аңа гына мөрәҗәгать итегез.
Бүгенге мастер-класста исә ул кечкенә кызлар өчен җәйге сумка бәйләргә өйрәтә. Сумкага иш итеп баш киеме дә бәйли аласыз.





Мастер-классны Наилә МЕДВЕДЕВА үткәрә



Кирәк

- 5 төсле бәйләм җебе: rose 50 г / 150 м (без ике төсле яшел, ике төсле шәмәхә, ачык көрән төсләр кулландык. Сез үзегез яраткан төсләрдән бәйли аласыз);
- 2,5 һәм 1,5 санлы ыргаклар;
- бәйләм җепләре белән яраша торган сәйләннәр (диаметры 4 мм);
- матур сәдәфләр;
- үтә күренмәле нечкә кыл;
- сумканың эчлеген тегү өчен ныкча тукыма;








Сумканың алгы һәм арткы ягы

Сумканың капкачы

Сумканың бавы









Эш барышы

■ 0 нче рәт: ачык көрән җептән 4 буш күздән торган чылбыр үреп, боҗрага тоташтырабыз.

■ 1 нче рәт: 3 буш күздән 1 күтәртү баганасы бәйлибез (күтәртү баганасы һәр рәт башында бәйләнә). 1 чалулы 11 багана бәйләп алабыз. Рәттә күзләр саны 12 булырга тиеш. Һәр рәт саен күзләр санын 12 гә арттыра барабыз.

■ 2 нче рәт: 3 буш күздән 1 күтәртү баганасы, аннары һәр күздән чалулы икешәр багана бәйлибез. Бәйләм осталары телендә мондый бәйләм үрнәге классик түгәрәк дип атала. 2 нче рәттә күзләр саны 24 булырга тиеш.

■ 3 нче рәт: ачык шәмәхә төсендәге җепкә күчеп, 3 буш күздән торган күтәртү баганасы бәйлибез дә үрнәк буенча бәйләүне дәвам итәбез.

■ 4 нче рәттә сыек яшел төскә күчеп, чалулы баганалар белән бәйлибез.

■ 5 нче рәт куе яшел төстән чалусыз багана белән бәйләнә.

■ 6 нчы рәт чалулы багана белән ачык шәмәхә төстән бәйләнә.

■ 7 нче рәт чалулы багана белән куе шәмәхә төстән бәйләнә.

■ 8 нче рәт куе яшел төсле җептән чалусыз багана белән бәйләнә.

■ 9 нчы рәт ачык көрән төстән чалулы багана белән бәйләнә.

■ 10 нчы рәт сыек яшел төстән чалусыз багана белән бәйләнә.

■ 11 нче рәт шулай ук сыек яшел төстән рельефлы багана белән бәйләнә. Игътибар: бу рәттә уртадагы 22 күз чалулы багана белән бәйләнә. (Сумканың авызы булачак урын.)

■ 12-13 нче рәтләр куе яшел төстән рельефлы багана белән бәйләп тәмамлана. Теге 22 күз бәйләмдә катнашмый.

■ Сумканың алгы ягы да, арткы ягы да бертөсле бәйләнә. Алгы якның 9 нчы рәтенә үтә күренмәле кыл белән сәйләннәр тегеп чыгабыз. Аларны бәйләгәндә үк беркетергә дә була.

Сумканың янын бәйләү

Ачык шәмәхә төстән 106 күзле чылбыр үреп, 3 рәт ярымбагана (полустолбик) белән бәйлибез. Урта сызык буйлап яшел төстәге сәйләннәр тезеп чыгабыз.

PRESSA.RU



Сумканың капкачын бәйләү

■ 0 нче рәт: ачык шәмәхә төсле җептән 6 күз җыеп, боҗрага тоташтырабыз.

■ 1 нче рәт: шул ук җептән 3 күтәртү баганасы һәм 11 чалулы багана бәйлибез.

■ 2 нче рәт тә шул ук җеп һәм чалулы багана белән бәйләнә.

■ 3 нче рәт: ачык көрән җепкә күчеп, иң элек 3 күтәртү баганасы, аннары 1 буш күз, 1 чалулы баганаһы чиратлаштырып бәйлибез.

■ 4 нче рәт: куе шәмәхә төскә күчеп, һәр тишек өстенә чалулы икешәр багана бәйләп чыгабыз.

■ 5 нче рәт: шул ук төс белән рельефлы баганалар бәйләнә.

■ 6 нчы рәт: ачык шәмәхә төсле җеп белән чалулы багана бәйлибез.

■ 7 нче рәт: сыек яшел төсле җептән берәр буш күз, чалулы ике багана, бер буш күз, ике багана чиратлаштырып бәйләнә.

■ 8 нче рәт: куе яшел төс белән чалусыз баганалар бәйләп чыгабыз.

■ 9 нчы рәт: ачык көрән төсле җептән чалулы баганалар бәйлибез.

■ 10 нчы рәт: ачык шәмәхә төс белән җилпәзә бизәк бәйләп, бәйләмне төгәллибез. Шушы рәтне бәйләгәндә уртага элмәк бәйләп калдырырга да онытмыйбыз.

Сәдәфне каптырыр өчен ул. Зурлыгы да сәдәф зурлыгы кадәр. Ул болай бәйләнә: 8 күздән (10 яки 11 күздән торырга мөмкин, сәдәфегез нинди бит!) торган чылбыр үреп, бәйләм читенә тоташтырабыз. Чылбыр тирәли чалусыз баганалар бәйләнә.

■ Сумканың бавы шәмәхә төстәге җептән бәйләнә. Озынлыгы – баланың буена бәйле. Тыгызрак булсын өчен аны 1,5 лы ыргак белән бәйләсәң яхшырак.

■ Бәйләп бетергәч, һәр өлешне кайнар пар бөркеп тигезлибез. Үтүкне бәйләмгә тидермәгез, җепләрне үтүкләсәң, рәвешен югалта.

Бизәкләр ясау

■ Бәйләм җебен ике катлап, озынрак итеп алабыз. Бер башын төенләп, 10 см булганчы сәйләннәр тезәбез. Җепнең калган өлешеннән чылбыр үрәбез. Мондый бизәк икәү кирәк.

■ Өченчегә чук ясыйбыз: ачык яшел төсле җепне калын гына итеп уң кулның дүрт бармагына урыйбыз. Аннары бармакларны алып, уртасыннан җеп белән нygытып бәйлибез. Чукның өске ягыннан 1 см төшеп, аркылы җеп чорныйбыз, таралып китмәсен өчен яхшылап бәйлибез. Кайчы белән чукны тигезлибез.

Эчлекне тегү

■ Ныкча тукымадан сумканың эчлеге тегелә. Ул ике түгәрәктән һәм тар озын турыпочмаклыктан гыйбарәт. Түгәрәкләрнең зурлыгы сумканың диаметры (безнең сумканың диаметры 16 см) + 1 см тегү өлешенә тәңгәл. Турыпочмаклык исә 44 см озынлыгында, 4 см киңлегендә киселә. Аларны машина җөе белән тегеп тоташтырабыз.

Сумканы җыю

■ Алгы як белән ян өлешне чалусыз багана белән бәйләп тоташтырабыз. Җепнең ачык шәмәхә төслесен кулланабыз. Аннары арткы якны да шулай ук тоташтырабыз. Капкачны арткы өлешкә үтә күренмәле кыл белән тегеп куябыз.

■ Бауның ике очын сумканың ике читенә тегәбез. Бер кырыйга бизәкләрне беркетәбез.

■ Сумка эченә әзер эчлекне кидереп, авызын кулдан гына, күренми торган җөй белән тегәбез. Элмәк турысына сәдәф беркетелә.

Бер җептән икенче төсле җепкә күчкән урын бәйләмдә беленмәсен өчен бер сер өйрәтик әле: рәттәге соңгы күзне бәйләгәндә баганаңың иң соңгы элмәген күчәсе җеп белән бәйләп алабыз.


Кучкар. Кеше сүзенә игътибар итмәскә тырышыгыз. Бу айда иң мөһиме – үз көчеңә ышану. Ә ул сезгә бик тә кирәк булачак. Эш белән бәйле кыенлыклар, четерекле мәсьәләләр килеп чыгу ихтималы бар. Йолдызбагарлар ашыкмаска киңәш итә. Нәрсәнең нәрсә икәнен вакыт үзе күрсәтәчәк.


Үгезбозау. Артык зур үзгәрешләр көтәргә кирәкми. Ниндидер бер яңа нәрсәгә өйрәнү мөмкинлеге булыр, ул тормышны яңача күрергә булышыр. Эштә үзегезне күрсәтү өчен яхшы гына форсат чыгар.


Игезәкләр. Дәрәҗәгез, абруегыз күтәрелеп китәр. Моңа кадәр сезне санламый йөрүчеләр дә сүзегезгә колак салыр. Көнләшүчеләр дә юк түгел. Ниятләрегезне, кызыклы идеяләрегезне башкалар белән бүлешмәгез.


Кысла. Бу айда күп нәрсә үзегез хакында нинди фикер тудыра алуыгызга бәйле. Хәйран яхшы перспективалар булырга тора, мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмагыз. Ялгыз Кыслаларга гаилә кору өчен әйбәт вакыт.


Арыслан. Ай «Алга!» шигаре белән узачак. Ниятләгән эшләрегездән ваз кичәргә теләсәгез дә, чигенмәгез – уңыш сезнең якта. Авырлыкларның барысы да узгынчы гына. Үзегез яхшы белгән кешенең киңәшенә колак салыгыз.


Сөмбелә. Тавыш-гаугаларны өнәмәсәгез дә, бу айда күп нәрсәгә каршы торырга туры киләчәк. Иң мөһиме: үзегезгә карата дошманлык хисе тудырмау. Игътибар җәлеп иттерү, җитди мәсьәләләрне хәл итү өчен яхшы вакыт түгел.


Бизмән. Бернинди кыенлыкларга карамый, үз дигәнегезгә ирешәчәксез. Кыюлыгыгызга үзегез үк аптырарсыз. Эшегездән, тормышыгыздан канәгатьсезлек туарга мөмкин. Хезмәт хакын арттыру мәсьәләсендә шәп форсат килеп чыгар.


Чаян. Четерекле хәлләрдән җиңел котылуның юлы – балаларча ихлас булу. Уңышка ирешим дисәгез, җитезлек күрсәтегез. Җитезлек эш-гамәлдә генә түгел, карар кабул иткәндә дә кирәк. Ял итү өчен июнь ае кулай ай түгел.


Укчы. Сезнең барысы да яхшы – дөрес карарлар кабул итәрсез, дөрес гамәлләр кылырсыз, кирәкле кешеләр белән танышырсыз. Тирә-юньдәгеләр сезне мактаган булып, үз максатларында файдаланырга омтылыр, аң булыгыз!


Кәҗәмөгез. Беркем күрә алмаган җирдән файда күрерсез. Тәвәккәллек зур ярдәмче. Төрле килешүләрне айның беренче яртысында төзергә тырышыгыз. Алдакчылар кармагына кабуыгыз бар, сак булыгыз.


Сукояр. Сезне ниндидер кысага куып кертүе авыр. Үз сүзегезне сүз иткәнче, моның кемгәдер ошамавын да уйлагыз. Бу – эшкә генә түгел, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә дә кагыла. Яңа идеяләрне тормышка ашыру өчен яхшы вакыт.


Балыклар. Катлаулы ай. Ачуны китерә торган мизгелләр дә булыр. Нәрсә уйлаганыгызны әйткәнче, унга кадәр санагыз. Бу айда гаиләгез белән күбрәк булырга тырышыгыз. Бүген эшлисе эшне иртәгә калдырасыз икән, соң булачак.

Май *да кабынган йолдызлар*

Татарстан



Флера Хәмитова (2.05.1936) – **Татарстанның атказанган артисты.**

Казанда туа. 1956 елда Казан педагогика училищесын, ә 1961 елда Мәскәүнең Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлый. Шул ук елны Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына кабул ителә. 1968 елда аны театр училищесына сәхнә теле укытырга чакыралар. Театрда эшләү белән бергә училищеда да сигез ел укыта. Ләкин зур рольләр уйный башлагач, аннан китәргә туры килә. Укытучы булу хыялы һаман да сүнми – 1985 елда сәхнәне калдырып, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә сәхнә теле укыта башлый. Тамашачылар хәтерендә Хәмдия – «Чаткылар» (Т. Гыйззәт), Мәйсәрә – «Зәңгәр шәл», Сәрвәр – «Сүнгән йолдызлар» (К. Тинчурин), Саҗидә – «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т. Миңнуллин) кебек рольләре белән кереп калган.

Россия



Наталья Андрейченко (3.05.1956) – Россиянең атказанган артисты.

Мәскәүдә туа. ВГИКны тәмамлый. Икенче курста укыганда ук «От зари до зари» фильмында уйный. Танылу китергән роле исә – «Мэри Поппинс, до свидания!» фильмындагы Мэри Поппинс (1983). «Военно-полевой роман», «Сибириада» фильмнарында уйнаган рольләре дә уңышлы. 1981 елда композитор Максим Дунаевскийга кияүгә чыга. 1991 елда икенче ире – режиссер Максимилиан Шелл янына Америкага күченеп китә. Голливудта берничә фильмда уйный. 2005 елда Россиягә әйләнеп кайта.

Чит илләр




Шер (Шерилин Саркисян) (20.05.1946) – поп җырчы, җырлар авторы, актриса.

Калифорния штатында туа. Әтисе – әрмән, әнисе – индеецлардан. Кечкенәдән җырчы булырга хыяллана. 16 яшендә мәктәпне ташлап, Лос-Анджелеска актерлык сәнгатенә өйрәнергә китә. Җырчы булып китүенә музыкаль продюсер, соңрак исә ире Сонни Боно «гаепле». 1965 елда «Сонни һәм Шер» дуэтының беренче альбомы дөнья күрә. 1969 елда Шер «Честити» фильмында уйный. Кинога төшкәннән соң ук туган кызына да Честити дип исем куша. 1982 елда Шер Нью-Йоркка күчә. Майкл Николс аны «Силквуд» фильмында уйнарга чакыра. Оскар, Грэмми, Эмми, «Алтын глобус» премияләренең барысына да ия булган сирәк актрисаларның берсе.

PRESSA.RU





«КАМИЛЛЕКТӘН КУРЫКМАГЫЗ!»

Айрат Хәмидуллин Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын тәмамлаганнан бирле – 30 ел дәвамында Казан сынлы сәнгать училищесында укыта. Укытучы, рәссам булуы өстенә 25-30 ел дәвамында каратэ белән дә шөгыльләнә Айрат Габдулла улы. Шуңа күрә рәссам иҗатына «Самурайлар» каян килеп керде икән дигән сорау үзеннән-үзе юкка чыга. «Самурай»лар һәрвакыт үлем турында уйлый. Бу хакта уйланган кеше күбрәк эшли. Алар матур яшәп, матур итеп үлү турында хыялллана», – ди рәссам. Һәм студентларын да япон риваятьләрендәге кебек матур итеп яшәргә өнди. Моңа кадәр үтелгән юлын да япончалатып «до» – юл дип атый ул (дзюдо, тхэквандо дигәннәре дә шул ук «юл» белән аваздаш икән ләбаса – «йомшак юл» «камиллек юлы»).

Ә иҗат белән түшәлгән гомер юлы мәгънәле дә, картиналарындагы кебек җете дә аның. Ел башында «Хәзинә» милли сәнгать галереясында булып узган юбилей күргәзмәсендә 107 эшен тамашачы хозурына тәкъдим итә рәссам. Бу аның барлык эшләренең дүрттән бере генә әле. Шунысын да искәртергә кирәк: болар училищеда, Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтының Казан филиалында укытудан бушаган арада гына язылган картиналар. Пост-импрессионизм тарафдары буларак танылу алган рәссам киләчәктә дә үз йөзен югалтмауны мөһим дип саный.

– Мин башка стильгә күчмәмдер. Иҗатым тирәнәя генә барачак. Рәссамның йөзе ул тормыш позициясенә дә бәйле. Тормышта компромисс ясыйсың икән – ул иҗатта да чагыла. «Әйе» дигәнмен икән – «әйе», «юк» икән – «юк». Моның өчен әлгә дә әле миңа, – ди ул.


Рәссамның үз кыйбласы булуы бәхәссез. Бүген кайберәүләр депутатларның, йә булмаса, мәшһүр артистларның портретларын эшләп юанганда, Айрат әфәнде, кем булуына карамастан, тора салып матур хатын-кызны сурәтләү ягында. Җиде ят сатып алырлык итеп... Инде портретларга тукталганбыз икән, үзеннән-үзе күчергеч проблемасы килеп чыга. Билгеле портрет бер сеанста гына язылмый. Өчәр сәгатьлек 7-8 сеанс таләп ителә моның өчен. «Валентин Серов, әйтик, «Шәфталу тоткан кыз»ын 100–120 сеанста язган... Мин эшләгән портретлар бары да күчергечтән ясалган. Хәтердән дә, фотодан да беркайчан да язганым юк», – ди әңгәмәдәшем.


– Бөтенесен дә булдырам, бу миңа бик җиңел бирелә дигән иҗатчы, үзе физик яктан тере булса да, рәссам буларак үлгән дигән сүз, – ди ул. Аңлашыла. Димәк, үсү өчен иң мөһим стимул – үз-үзеңнән канәгать булмау. Юбилей күргәзмәсеннән дә ул мин әле камил түгел дигән нәтиҗә ясаган. Мөгаен, үз-үзенә Сальвадор Дали сүзләрен дә еш кабатлый торгандыр рәссам: «Камиллектән курыкмагыз! Сез аңа беркайчан да ирешә алмаячаксыз!»

Тагын бер нәрсәгә иманы камил останың: яхшылык һәрвакыт явызлыка каршы көрәшә. Яхшылык, ким дигәндә, ике тапкырга күбрәк булырга тиеш. «Өчләтелгән» автопортретында да үзе үк фәрештә, үзе үк шайтан кыяфәтенә кереп, шуны тәкрарлый рәссам.

Расиха ФӘИЗОВА





АЙРАТ ХӘМИДУЛЛИН

PRESSA.RU

Язылһәм телевизор от!

1 Языл
30.06.2016 кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә 3 басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*



2 Җибәр
язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 От
Телевизор, фотоаппарат һ.б. бүләкләр отарга ашык!









Акцияне үткәрү вакыты:18.04.2016 - 20.09.2016
Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте
Белешмәләр өчен телефон: (843) 222-09-84 өстәмә номер - 1261

16+
Реклама

ИГЪТИБАР! «Сөембикә» журналының индексы үзгәрде «Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204. Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002